ГАБДЕЛБӘР ФӘЙЗРАХМАНОВ

СЕБЕРДӘ ҺӘМ ҮЗӘК АЗИЯДӘ БОРЫНГЫ ТӨРКИ ДӘҮЛӘТЛӘР



«МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ



Каһанлык йогынтысын
биләмәләр
Тибет империясе
(7 йөз башы)
Тан империясе
1:50 000 000
АВАРЛАР
Болгар диңгезе
БОЛГАРЛАР
АЛАННАР
ХӘЗӘРЛӘР
ВИЗАНТИЯ
Хәзәр диңгезе
Итил
Жаек
УГЫРЛАР
КЫПЧАКЛАР
Иртеш
Умар
КИМӘКЛӘР
ТӨРКИ КАҺ
УГЫЗЛАР
Харәзем диңгезе
ХАРӘЗЕМ
КАРЛУКЛАР
ТӨРГЕШЛӘР
КӨНБАТЫШ ТӨРКИ КАҺАНЛЫГЫ
680 елларга кадәр
ТЕЛЕК (УЙГЫРЛАР)
Тараз
Чач
Суяб
Бишбал
Бохара
Сәмәрканд
СОГЫД
Аксу
Куча
Кашгар
Яркәнд
ТИБЕТ ИМ
60°
80°
50
40


ТӨРКИ КАҺАНЛЫГЫ (6–7 йөзләр)
булган
Гаочан
Мәгълүм шәһәрләр
киДәннәр
Халыклар
100°
120°
140°
40
Байкүл
Амур
КУРЫКАННАР
ШИВӘЙЛӘР
БАЕРКУЛАР
ГЫЗЛАР
Н Л Ы Г Ы
КИДӘННӘР
БОХАЙ
700 елдан
КӨНЧЫГЫШ ТӨРКИ КАҺАНЛЫГЫ
630 елларга кадәр
ЛАР
Ляоян
СИЛЛА
660 елдан
Ямато дингезе
ЯМАТО
Нара
Сары дингез
ТАН ИМПЕРИЯСЕ
Дуньхуан
РИЯСЕ

БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ

ГАБДЕЛБӘР ФӘЙЗРАХМАНОВ

СЕБЕРДӘ ҺӘМ ҮЗӘК АЗИЯДӘ БОРЫНГЫ ТӨРКИ ДӘҮЛӘТЛӘР

КАЗАН • «МӘГАРИФ» НӘШРИЯТЫ • 2005

УДК 94(571/575)"652"
ББК 63.3(2)2/43
Ф91

Татарстан Фәннәр академиясенең Ш. Мәрҗани исемендәге Тарих институты гыйльми советы карары нигезендә басыла.

Рецензентлары:
тарих фәннәре докторы *Д. М. Исхаков*,
тарих фәннәре докторы *С. Х. Алишев*

Китап Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы «Татарстан Республикасы халыклары телләре турында» Татарстан Республикасы Законын гамәлгә ашыру комитеты ярдәмендә нәшер ителде.

Фәйзрахманов Г. Л.

Ф91 Себердә һәм Үзәк Азиядә борынгы төрки дәүләтләр/ Габделбәр Фәйзрахманов.— Казан: Мәгариф, 2005.— 191 б.
ISBN 5-7761-1404-7

Әлеге хезмәттә төрки дәүләтләрнең бик борынгы заманнардан башлап XIII гасырга кадәрге тарихы бәян ителә. Автор борынгы төркиләр тарихын зур киңлектә тикшерә — китапта аларның географик урнашуы, сәяси тормышы, көнкүреше, мәдәнияте, диннәре һәм күрше дәүләтләр, кабиләләр белән үзара мөнәсәбәтләре тасвирлана. Ышанычлы тарихи чыганаклар нигезендә борынгы төрки дәүләтләрнең төзелүе, үсүе һәм көчәюе, һәлакәте, бу һәлакәтнең сәбәпләре һәм нәтиҗәләре яктыртыла.

ISBN 5-7761-1404-7

© «Мәгариф» нәшрияты, 2005
© Бизәү. «Мәгариф» нәшрияты, 2005

ЭЧТӘЛЕК

Автордан 4
Кереш 5

***I бүлек.* Көньяк Себернең археологик мәдәниятләре** 28

***II бүлек.* Сөннәр** 42
Бөек дала 42
Үзәк Азиянең борынгы халкы 43
Сөннәр 44
Сөннәрнең күршеләре 51
Сөнну дәүләте 52
Кытай белән мөнәсәбәтләр 56
Кытай диверсиясе 59
Сөнну җәмгыятенең кризисы. Бүленү 62
Сөнну мәмләкәтенең һәлакәте 65
Сөннүнең хуҗалыгы һәм рухи мәдәнияте 71
Сөннүнең иҗтимагый һәм дәүләт төзелеше 75
Һәлакәттән соң сөннәрнең язмышы. Көньяк сөннәр,
Юебань һәм һуннар 79

***III бүлек.* Бөек Төрки каһанлыгы** 90
Борынгы төркиләр 90
Беренче Төрки каһанлыгы 95
Икенче Төрки каһанлыгы 102
Хәзәр каһанлыгы һәм Азов буендагы Бөек Болгар дәүләте 107
Борынгы төркиләрнең дәүләт һәм иҗтимагый төзелеше 111
Бөек Төрки каһанлыгының халкы 116
Борынгы төркиләрнең хуҗалыгы 118
Борынгы төркиләрнең дине 124
Мәдәният 125

***IV бүлек.* Уйгыр каһанлыгы** 138

***V бүлек.* Кимәк каһанлыгы һәм борынгы төркиләр язмышы** 149
Кимәк каһанлыгы 149
Кимәк каһанлыгы халкы 152
Кимәк каһанлыгының хуҗалыгы һәм мәдәнияте 161
Кимәк дәүләтенең һәлакәте 163
Кимәк дәүләтенең һәлакәтеннән соң борынгы төркиләрнең язмышы 167

***VI бүлек.* Енисей кыргызлары дәүләте** 174
Минуса казанлыгының борынгы халкы 174
Енисей кыргызлары дәүләте 176
Монголларга каршы көрәш 180
Енисей кыргызлары дәүләтенең иҗтимагый төзелеше 180
Кыргызларның хуҗалыгы 182
Рухи мәдәният 184
Йомгак 189

АВТОРДАН

Узган гасырның 80 нче еллары ахырында, илебездә тоталитар тәртипләр какшап, демократия җилләре исә башлагач, халкыбыз дәүләт җитәкчеләре алдына катгый таләпләр куйды. Бу таләпләр шактый күп булып, шулар арасында өчесе үтә әһәмиятле иде: дәүләтчелегебезне кире кайтару, татар телен дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү һәм халкыбызның тарихын дөрес итеп язу.

Бу таләпләрне тормышка ашыру өчен, демократик тәртиптә Татарстанның яңа Югары Советы сайланды, ул Татарстанның дәүләт суверенитеты турында Декларация кабул итте, татар телен рус теле белән беррәттән дәүләт теле дәрәҗәсенә күтәрү законлаштырылды. Татарстанда Фәннәр академиясе төзелде, аның составында Тарих институты оештырылды. Тарихчы галимнәргә халкыбызның ышанычлы чыганакларга нигезләнгән дөрес тарихын язу бурычы куелды.

Татар халкы тарихын язу өчен, башта халкыбызның төрле этнографик төркемнәре тарихын язарга кирәк иде. Шушы максатны тормышка ашыру өчен, мин Себер татарлары тарихын өйрәнергә керештем. Бу темага электән җыелган бераз тарихи материалым да бар иде. Эшли башлауга шул ачыкланды: Себер татарлары тарихын Идел-Урал буе, Әстерхан татарлары тарихыннан, борынгы чор буенча гомуми төркиләр тарихыннан аерып тикшерергә дә, язарга да мөмкин түгел, чөнки ата-бабаларның тамырлары бер. Барысы да борынгы төркиләр тарихына барып тоташа.

Мин борынгы төркиләр тарихы буенча чыганакларга, төрле ил галимнәре хезмәтләренә таянып эшкә керештем. Нәтиҗәдә мөстәкыйль, шул ук вакытта бер-берсенә нык бәйле ике монографиялек материал һәм фәнни фикер тупланды. Алар рус телендә «Древние тюрки в Сибири и Центральной Азии» (2000) һәм «История сибирских татар с древнейших времен до начала XX века» (2002) дигән исем астында Казанда басылып чыктылар.

Әлеге, ягъни сезнең кулга килеп кергән китапны чыгаруга исә татар тарихын халкыбызга үз туган телебездә ирештерү теләге этәргеч булды. Бу китап рус телендә чыккан монографиядән бераз аерыла. Әлеге хезмәткә яңа материал, яңа фикерләр өстәлде.

Китап халык өчен, ил өчен языла.

Халкыбыз һәрвакытта үзенең тарихи тамырлары белән кызыксынып яшәде. Бу китап бабаларыбызның яшәү өчен көрәше, алар төзегән дәүләтләрнең данлы үткәне һәм фаҗигале язмышы белән таныштырыр.

КЕРЕШ

Милли аңның үсүе, дәүләтчелек идеясенең торгызылуы сәбәпле, халкыбызда үзенең тарихы һәм тарихи тамырлары белән кызыксыну көчәйде. Билгеле булганча, татарлар — дөньяның иң таралып, сибелеп утырган халыкларының берсе. Халкыбызның шактый өлеше үзенең тарихи ватанында — Татарстанда, Башкортстанда, Югары, Урта һәм Түбән Идел буенда, Уралның төрле өлкәләрендә, Көнбатыш Себердә яши. «Бәхет эзләп», башка халыклар арасына, хәтта ерак чит илләргә барып урнашкан татарлар да аз түгел. Илдә тоталитар режим какшап, аралашу мөмкинлекләре тугач, татарлар төрле җирләрдән тарихи ватаннарын күрергә Казанга ашкына башлады. Монда бик кызык күренеш күзгә ташлана: татарлар үз ата-бабалары чыккан өлкәләрне генә түгел, Татарстанны да: «Тарихи ватаныбыз, әби-баба туфрагы»,— дип сагынып кайта. Аларны бирегә җан да, кан да тарта. Тарихи ватанны сагыну хисе аларда шулкадәр көчле ки, Америкадан, Төркиядән, Австралиядән, Финляндиядән һәм башка илләрдән кайткан алыптай ирләр, могтәбәр ханымнар, Татарстан буенча йөргәндә, автобусларны, җиңел машиналарны туктатып: «Ата-баба туфрагы, туган җир»,— дип, яшел болыннарга, иген басуларына иелеп, яшьле күзләрен сөртә-сөртә дога укый, үзләре белән бер уч туфрак ала.

Узган гасырның 80 нче еллары ахырында, ягъни татар милли азатлык хәрәкәте яңарып киткән көннәрдә, халкыбызның дөрес тарихын язу бурычы калыкты.

Патша Россиясе шартларында рәсми тарих фәне татар халкы һәм аның ата-бабалары булган борынгы төркиләр тарихын дошман кавемнәр тарихы итеп күрсәтте. XIX гасырның соңгы чирегендә — XX гасыр башында татар зыялылары арасыннан чыккан үз тарихчыларыбыз татар халкы һәм борынгы төркиләр турында хезмәтләр яза башлый. Шиһабеддин Мәрҗани, Ризаэддин Фәхреддин, Әхмәтзәки Вәлиди, Гайнетдин Әхмәров, Хәсәнгата Габәши, Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин, Җамал Вәлиди һ. б. күренекле тарихчылар татарларның этник тамырлары бик борынгы гасырлардан килүен, аларның милли дәүләтчелек тарихы борынгы төрки дәүләтләрдән башлануын билгеләп үттеләр. Ләкин шовинизм дәүләт идеологиясе булып торган Россия шартларында тарихыбызны ничек булган шулай язу мөмкин түгел иде.

Дәүләтнең цензура кайчысы китаплардан татар турында дөрес язылган юлларны кисеп торды. Татар галимнәренә архивлардан, бай китапханәләрдән файдалану мөмкинлеге дә чикләнгән иде.

Совет хакимияте башта тарих фәне дилбегәсен бераз йомшарткан кебек булса да, татар һәм борынгы төркиләр тарихы Коммунистлар партиясе билгеләгән сәяси кысалар чикләрендә генә өйрәнелде һәм язылды. Тарихыбызны документаль чыганакларга һәм мәшһүр галимнәр хезмәтләрендәге мәгълүматларга, фикерләргә нигезләп язган өчен, Һади Атласи, Газиз Гобәйдуллин, Галимҗан Ибраһимов, Михаил Худяков һәм башка галимнәр 37 нче елларда НКВД төрмәләрендә җәзалап үтерелде.

Татар халкының ерак үткәндәге тарихында да, Россия дәүләте эчендәге тормышында да данлы да, фаҗигале, гыйбрәтле дә сәхифәләр күп иде. Авыр колониаль изү шартларында яшәсә дә, татар халкы, Россияне баету өчен, куәтен күтәрү өчен, көч-гайрәтен кызганмады, рус һәм башка халыклар белән бергәләп, Россияне дошманнардан саклауда каһарманлык үрнәкләре күрсәтте. Бу — халкыбызның 1812 елгы рус-француз сугышы, 1904 елда булган Порт-Артур янында булган сугыш турындагы җыр-бәетләрендә дә чагыла. 1941—1945 елларда немец фашистларына каршы барган сугышта татар ирләре генә түгел, хатын-кызлары да тиңдәшсез каһарманлык белән халкыбызның данын югары күтәрде. Ләкин дәүләт җитәкчеләренә татарның даны түгел, хезмәте, батырларча сугышуы гына кирәк иде. ВКП(б) Үзәк Комитетының 1944 елның 9 августында кабул ителгән Татарстан партия оешмасында идеология эше турындагы карары татар халкының, аның галимнәренең, язучыларының телен бик тиз кисте. Тарихыбызның, үткән тормышыбызның күп өлкәләре турында фәнни хезмәтләр, әдәби әсәрләр язу, спектакльләр кую туктатылды. Борынгы төркиләр, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Себер ханлыклары тарихын дөрес итеп язу тыелды. Тарихчыларыбызның бишьеллык, еллык иҗат планнары Мәскәүдә раслана иде. Совет рәсми тарих фәне X гасырда оешкан Идел Болгары дәүләтен татар халкы бабаларының беренче дәүләте итеп күрсәтергә тырышты.

Хәзерге төрки халыкларның, шул исәптән татар халкының да борынгы бабаларының б.э.к. үк үз дәүләтләре булуы кире кагылмаслык тарихи фактлар һәм документлар белән раслана. Алар төзегән куәтле илләр күп төрле төрки кабиләләрне берләштергән, һәм алар халыкара танылуга ирешкән. Хәзерге төрки халыкларның бабалары, бу дәүләтләрдә яшәп, үзләренең җисми һәм рухи мәдәниятләрен үстерә, бөтендөнья тәрәккыятенә үз өлешләрен кертә. Борынгы төрки дәүләтләр һәм бу дәүләтләрдә яшәгән бабаларыбыз тарихы һәм рухи мирасы бүгенге төрки халыкларның уртак хәзинәсен тәшкил итә.

Борынгы төрки дәүләтләр төрлечә аталып йөрде: Сөнну яки Бөек Сөн каһанлыгы, Бөек Төрки каһанлыгы, Кыргыз каһанлыгы, Уйгыр каһанлыгы, Кимәк каһанлыгы, Хәзәр каһанлыгы, Бөек Болгар дәүләте һ.б. Ул дәүләтләрне ныграк оешкан, әгәр Л. Н. Гумилев сүзләре белән әйтсәк, пассионар төрки кабиләләр төзи, аларның һәрберсендә күп төрле төрки кабиләләр яши. Кайбер очракларда, дәүләт юкка чыкканда, аны төзегән этник төркем дә юкка чыга. Мәсәлән, Бөек Төрки каһанлыгы таркалганнан соң, аны төзегән түркүтләр тарихи аренадан югала. Кимәк каһанлыгы һәлакәтеннән соң, тарихи аренадан кимәкләр китә. Аларга алмашка башка кабиләләр һәм халыклар килә һәм үз дәүләтләрен төзи. Шул рәвешчә, этногенетик процесслар һәм төрки телле яңа этнослар, кабиләләр барлыкка килү дәвам итә.

Югарыда күрсәтелгән вазгыятьне исәпкә алып, бу хезмәтне язганда шундый максатлар куелды:

— иң әһәмиятле археологик һәм язма чыганакларны, төрле чор галимнәренең хезмәтләрен өйрәнү нигезендә, борынгы төрки кабиләләрнең ыруглык җәмгыятеннән башлап үз дәүләтләрен төзүгә кадәр булган катлаулы үсеш юлын яктырту һәм борынгы төрки дәүләтләрнең көчәю һәм җимерелү сәбәпләрен өйрәнү;

— борынгы төркиләрнең дөнья тәрәккыятен үстерүгә керткән мирасын яктырту;

— төрки кабиләләрнең борынгы төрки дәүләтләр җимерелгәннән соңгы тарихи язмышын ачыклау.

Авторның иң әһәмиятле бурычы татар һәм кардәш төрки халыкларның этник тамырларын фәнни тикшерүдән гыйбарәт.

Бу хезмәт территориаль яктан Бөек Сөн каһанлыгы һәм аннан соң төзелгән төрки дәүләтләрдә яшәгән кабиләләр зонасын: Ордосны, Монголияне, Байкал буйларын, Тываны, Минуса казанлыгын, Шәркый Төркестанны, Урта Азияне, Җидесуны, Казакъстанны һәм Көнчыгыш Европаның кайбер районнарын кочаклый.

Төркиләр сәяси берләшмәсенә кергән кабиләләрдә җиңелгән һәм үтерелгән дошманны символик сурәтләүче сыннар — балбаллар кую йоласы булган. Шунлыктан, этник территория проблемасын чишүдә башкалар белән беррәттән, борынгы төрки сыннар — балбаллар әһәмиятле чыганак булып тора. Балбаллар таралу ареалы төрки кабиләләр яшәгән территорияне билгеләргә ярдәм итә.

Территорияне билгеләгәндә, күмү йоласы да мөһим күрсәткеч санала. Мәсәлән, Бөек Төрки каһанлыгына кергән кабиләләр өчен күмү йоласының шундый хронологик типлары һәм вариантлары үзенчәлекле: а) VII гасырның икенче чирегенә кадәр — мәетне яндырып, көлен күмү; б) VII—VIII гасырларда мәетне ат белән бергә күмү: мәетнең башы —

көнчыгышка, атныкы көнбатышка юнәлтелгән була; в) VIII—IX гасырларда мәетнең башын төньякка, төньяк-көнбатышка юнәлтеп, атсыз күмү (Сросткин тибындагы күмү). Енисей кыргызларының күмү йоласы аеруча үзенчәлекле. Аларда, VIII—IX гасырларда мәетне яндырып, көлен бер елдан соң сай кабергә күмү йоласы сакланган[1].

Бу хезмәтнең хронологик чикләре иң борынгы заманнардан алып XIII гасырга кадәр булган чорны эченә ала. Җитәрлек дәрәҗәдә өйрәнелмәү һәм тикшерелә торган территориядә матди тарихи материал аз булу сәбәпле, неолит чоры автор тарафыннан кыскача гына яктыртылды. Бу җирләрдә бик борынгы заманнардан төрки кабиләләр яши, ләкин аларның «төрки» дигән гомуми исеме булмый. Бу кабиләләрне берләштерүче башка исем булганмы? Чыганакларда моңа җавап юк. Б.э.к. үк төрки телле динлиннар дәүләте — Динлин Го һәм сөннәр дәүләте — Бөек Сөн каһанлыгы яши. VI гасыр урталарыннан башлап, бер-бер артлы борынгы төрки дәүләтләр төзелә, алар арасында Енисей кыргызлары дәүләте иң озын гомерлесе була. Тарихи әдәбиятта ул Кыргыз каһанлыгы дип атала. Борынгы кыргыз дәүләте Бөек Төрки каһанлыгы белән бер үк вакытта барлыкка килә һәм аерым өзеклекләр белән XIII гасыр башындагы монгол яуларына кадәр яши.

Куәтле төрки дәүләтләр төзелү һәм аларның яшәү чоры эре этник берләшмәләр калыплашу чоры булып тора. Бу этносларның күпчелеге хәзерге төрки халыкларның ата-бабалары сафына кушыла.

Өйрәнелә торган чор үзенең характеры белән тарихи тәрәккыят дәвере була. Ул вакытта кабиләләрнең күченүе арта, этногенетик процесслар тизләшә, аларның дәүләтләре барлыкка килә һәм куәтләнә, әһәмиятле сәүдә юллары өчен көрәш кискенләшә, дәүләтләр һәм кабиләләр арасында халыкара элемтәләр, хуҗалык һәм мәдәни бәйләнешләр үсә.

Күп галимнәр, бигрәк тә һинд-европа карашлылар, Үзәк Азия далалары һәм Алтай — төркиләрнең беренче ватаны, нәкъ менә шуннан төркиләр төньякка һәм көнбатышка таба тарала, дигән фикерне алга сөрә. Бу фикер үзенә күрә бер аксиома булып китә.

Борынгы юнан тарихчылары б.э.к. IX—IV гасырларда Көнбатыш Себер һәм Көнчыгыш Европа далаларын үз эченә алган гаять зур мәйданнарда скифлар яки скиф берләшмәләре кергән кабиләләр яшәве турында яза. Б.э.к. III гасырда аларга алмашка сарматлар килә. Һинд-европа карашлы тел галимнәре скифлар һәм сарматларны, җитәрлек дәлилләре булмаса да, фарсы (иран) телле булган дип раслыйлар. Фәндә бу карашны европоцентризм дип атыйлар. Бу позициядә торучылар, фәнни дәлилләп тормыйча, б.э.к. 6—2 меңьеллыкларда Идел белән Енисей арасында европеоид типтагы һинд-европа кабиләләре яшәгән,

алар һинд-фарсы төркеменә кергән телләрдә сөйләшкән дип баралар. Бу территориягә алар, башка карашлы галимнәрнең фикерләрен санга сукмыйча, балт-славян, герман телләрендә сөйләшкән кабиләләрне китереп «утырталар». Алар карашынча, Енисей һәм Алтайның көнбатышында безнең эраның I гасырына кадәр төрки кабиләләр булмаган, Көнчыгыш Европа далаларында балт-славян, герман кабиләләре генә автохтон яшәгән. Һинд-европа позициясендә торган галимнәр карашынча, төрки халыклар, Себердә һәм Европада автохтон яшәмичә, безнең эра башыннан гына күченә башлаган килмешәкләр булып чыга.

Тел галимнәренең бу фикерен тарихчылар бернинди тәнкыйтьсез кабул итеп ала. Әмма Геродоттан башлап, без башка карашларны да очратабыз. Тарихи әдәбиятта скифлар һәм сарматлар төрки телле булган яки скиф һәм сармат берләшмәләре төрле телле кабиләләр җыелмасыннан торган дип белдерүче хезмәтләр дә аз түгел[2]. Рус галимнәреннән филолог һәм тарихчы Н. С. Трубецкой, географ һәм геополитик П. Н. Савицкий, табигать белгече һәм тарихчы бөек галим Г. В. Вернадский, этнолог һәм тарихчы Л. Н. Гумилев европоцентризм карашларына каршы чыкты. Алар кешелек тарихында бердәнбер үзәк (европоцентризм) урынына күп үзәклеклек (полицентризм) карашы тәкъдим итте. «Европа полицентризмы андый үзәкләр күп дип фаразлый. Европа — дөнья үзәге, әмма Палестина да — дөнья үзәге. Иберия һәм Кытай — шулай ук»,— дип язды Л. Н. Гумилев[3]. Антик авторларның мәгълүматларына нигезләп, аерым фәнни хезмәтләрнең авторлары б.э.к. IX—IV гасырларда Көнбатыш Себердә, Үзәк Азиядә, Казакъстанда һәм Көнчыгыш Европада яшәгән скиф-савромат берләшмәсе һәм шул ук регионнарда б.э.к. III гасырдан безнең эраның III гасырына кадәр көн күргән сармат берләшмәләре полиэтник булган һәм аларга төрки кабиләләр дә кергән дип фикер йөртә[4].

А. Х. Халиков Көнбатыш Себер далаларында сөннәр килгәнче үк төрки кабиләләр яшәгән дип раслый. Б.э.к. 2—1 меңьеллыклар эчендә, ягъни моннан өч мең еллар элек, бирегә карасук кабиләләре һәм аларга якын башка этник төркемнәр килә. Бу кабиләләр Балхаш күле тирәсендәге бик бай бакыр казылмаларына хуҗа булганнар, аннан бакыр һәм бакырдан эшләнгән әйберләр бөтен Себер буйлап таралган, шуның белән бергә угор теленә «җиз», ә кайбер диалектларга «йез» сүзе үтеп керә дип саный А. Х. Халиков.

Геродот б.э.к. V гасырда Гиппей тауларыннан, ягъни Уралдан, көньяктарак «скифча киенүче, ләкин үзгә телдә сөйләшүче» аргиппей халкын күрсәтә. А. Х. Халиков аргиппейлардан көнчыгыштарак башка прототөрек (беренчел төрек) кабиләләре: иседоннар (Геродот язуы буенча) һәм үсүннәр (Көнчыгыш чыганаклары буенча), алардан элегрәк

«алтын җыючы» аримпаслар, яки гриф кабиләләре яшәгән дип фараз итә. Болар, мөгаен, угыз-кыпчак кабиләләренең бабалары булгандыр[5].

Тарих фәнендә башка карашлар да урын алган. Кайбер белгечләр Идел буеның һәм Көньяк Уралның дала һәм урман-далалары төркиләрнең беренче ватаны булган дип саный. Аларның җисми мәдәнияте б.э.к. 4 меңьеллыкның ахырында барлыкка килгән, Идел-Уралдан төркиләр 500—600 ел эчендә көнчыгышка — Байкал аръягына һәм Маньчжуриягә кадәр, көнбатышка — Дунайга һәм Карпатка кадәр, көньякка Кече Азиягә кадәр таралган. Алар фаразлаганча, бу җирләрдә, безнең эраның II—XI гасырларында Көньяк Себердән һәм Үзәк Азиядән сөннәр, бәҗәнәкләр, угызлар, кыпчаклар һ. б. төрки телле кабиләләр килгәнче дә, бик борынгы заманнардан алып борынгы җирле төрки кабиләләр яшәгән[6]. Бу проблеманы Олжас Сулейменов лингвистик юл белән ачыкламакчы була. Төрки лексик материалны Евразиянең башка телләре лексикасы белән чагыштырып, төркиләр Саян-Алтай регионына, монгол далаларына, ихтимал, безнең эраның беренче гасырларында килгәндер, аларның күп гасырлык дәүләтчелек тәҗрибәсе була, дип нәтиҗә ясый ул. Алар көнбатыштан гасырлар буена Урта Азия һәм Алтай аша килә, ди ул. Төркиләр, һинд-европалылар, булачак америндлар б.э.к. 3 меңьеллыкта Борынгы дөньяның бер үк ареалларында — Мисырда, Алгы һәм Кече Азиядә яшәделәр, дип яза[7]. Тюрколог Зәки Вәлиди төркиләрне Европада һәм Азиядә яшәгән иң борынгы халыкларның берсе дип саный һәм төркиләрнең эзләре Кече Азиядә һәм Мисырда б.э.к. 2000 ел элек, Шумерда, Эламда 2600 ел элек очрый дип исәпли. Төркиләрнең эзләре Балкан ярымутравында, Көнбатыш Европада, шулай ук Америка индеецларының телендә сакланган[8]. Тарихчы галим Г. Б. Таймас: «Европаның көньяк-көнчыгышы — борынгы төрки йорт»,— дип яза[9]. М. З. Зәкиев үз хезмәтләрендә борынгы заманда төркиләрнең Европа һәм Азиянең берничә регионында көн күрүләре турындагы фикерне үткәрә[10].

Көньяк Себернең борынгы төркиләре белән кызыксыну беренче башлап XVIII гасырда Кытайда эшләүче француз миссионер-иезуитларында туа. Кытай тарихын өйрәнә торгач, алар, бу илнең тарихын кытайлар белән тыгыз мөнәсәбәттә яшәгән борынгы күчмәннәрдән аерып карау мөмкин түгел, дигән фикергә килә. Француз галимнәре өйрәнә башлаган беренче халык сөннәр була. Сөннәр тарихын өйрәнүче француз профессоры Дегинь, Кытай һәм Европа чыганакларындагы мәгълүматларны чагыштырып, сөннәр Европа һуннарының бабалары булган, дигән фикергә килә. Әбелгази хезмәтен җентекләп тикшереп, Дегинь аның да сөннәрне һәм һуннарны төрки телле халык дип исәпләвен күрсәтә. Шунысын да әйтергә кирәк: Дегинь борынгы монголлар белән борынгы төркиләр арасында зур аерма

күрмәгән, аның бу фикеренең ялгышлыгын кытай чыганаклары күрсәтә[11].

Икенче бер француз галиме шәрыкчы Л. Каен үзенең фәнни хезмәтен Урта Азиянең иң борынгы заманнардан алып Аксак Тимер хакимлегенә кадәр булган тарихына багышлый. Ул сөннәрнең төрки чыгышлы булуына нык ышана, һуннарны сөннәр варислары итеп таный. Бу галим халыкларны лингвистик түгел, ә сәяси классификацияләү тарафдары була, һуннарны сөннәр варисы дип саный, шул ук вакытта һуннар арасында башка кабиләләр дә булган, дигән фикер белдерә. Ләкин ул һуннарны сәяси классификацияләү юлын алып ялгыша.

Клапрот һәм Ремюза сөннәрнең төрки чыгышлы булуын күрсәтә, һуннарны алар финнар исәбенә кертә. К. Иностранцев шәрыкчы галимнәрнең француз мәктәбе проблемаларын җентекләп тикшерә (автор ул фикерләрне кабатлап торуны кирәк тапмады)[12].

Россиядә борынгы төркиләр проблемасын өйрәнү XIX гасырның 20 нче елларында башлана һм гасыр ахырына таба көчәя. Бу Дания шәрыкчысы В. Томсенның Орхон-Енисей язмаларын уку ысулын табуы һәм аларның В. В. Радлов тарафыннан укылуы белән бәйле була.

Шул ук елларда төркиләрнең Россия шәрыкчы галиме В. В. Бартольд эшләгән тарихи концепциясе тарала. Әлеге концепция аның фәнни хезмәтләрендә чагылыш таба[13].

Себердәге һәм Үзәк Азиядәге ташка төшерелгән моңарчы «күз күрмәгән» язмалар турындагы беренче хәбәрләр XVII йөз ахыры — XVIII йөз башында пәйда була. 1692 елда Амстердам бургомистры Николай Витзен: «Верхотурьедан ерак булмаган кыяда берничә сурәт һәм билгесез хәрефле язмалар табылды»,— дип хәбәр итә[14]. 1696—1697 елларда Семен Ремезов Талас елгасының югары агымында урнашкан Дмитриевка авылы янында билгесез язулы таш таба. 1730 елда билгесез язулар турында 1711—1712 елларда Себердә яшәгән Филипп Иоганн Страленберг хәбәр итә. Швециядә шул язулар хакында хезмәт бастырып чыгара[15]. 1719 елда Себергә шартнамә буенча Даниил Готлиб Мессершмидт җибәрелә. Ул бу илнең географиясен, табигый байлыкларын, этнографиясен, тарихи һәйкәлләрен һәм борынгы тарихын өйрәнергә тиеш була. Д. Г. Мессершмидт үзенең Себергә баруы турындагы хисапнамәсендә шундый ук язуларны күрсәтә. Скандинавиянең рун язуларына охшаш булганга, бу Себер язулары рун язулары дип атала башлый. Себер язуларына карата бу «рун» дигән исем дөньяга Страленберг хезмәте чыкканнан соң берегеп кала.

Д. Г. Мессершмидт бу язуларны кельт-герман чыгышлы дип фараз итә. П. С. Паллас аларны, гот кабиләләренә нисбәтле, ди. Г. И. Спасский, алар монголлардан яки калмыклардан калган, дип яза. Хәйран үткен бәхәсләр башланып китә. Себер рун язуын славян яки фин

чыгышлы дигән теорияне «расларга» маташучылар да була. Француз шәрыкчысы Ж. П. Абель-Ремюза, 1820 елда беренче булып, бу язмалар төркиләрнеке һәм, мөгаен, алар кыргызлардан калгандыр, дигән фараз белдерә[16]. Тора-бара Г. И. Спасский үз гипотезасының хаклыгына шикләнә һәм Себер язуының аерым билгеләренең Себер татарлары тамгалары белән охшашлыгына игътибар итә башлый. Бу гипотеза популярлашып китә һәм бүгенгәчә әһәмиятен югалтмый.

Әмма төрки язуның килеп чыгышы турында бәхәс дәвам итә. В.Томсен аны, арамей язуының бер тармагы аша Финикия язуыннан кергән, дигән фикер белдерә. В. В. Радлов төрки язуының арамей язуы үрнәкләре белән генетик элемтәсе булуы мөмкин дип исәпли. Бу теорияне аннан соң күп галимнәр яклый. Ләкин төрки рун язуының килеп чыгышы проблемасы тулысынча хәл ителгән дип әйтеп булмый. А. С. Аманжолов, үзе җыйган күп санлы материалларга таянып, төрки алфавит б.э.к. 1 меңьеллыкта барлыкка килгән, дип нәтиҗә ясый[17].

Европага рун язуын, мөгаен, һуннар алып килгәндер. Соңга табарак та Көньяк Себернең төрле урыннарында язулы ташлар табыла. Ике йөз елга якын бу язуны укырга омтылышлар уңышсыз була. 1889 елда җәмәгать эшлеклесе һәм галим Н. М. Ядринцев Төньяк Монголиядәге Орхон елгасы башында өч таш багана таба. Берсенең тик кисәкләре генә сакланган. Аларда кытай, төрки рун һәм согд текстлары табыла. Кошо-Цайдам дигән урындагы төрки рун һәм кытай текстлары булган ике таш багана яхшырак сакланган. 1891 елда Н. М. Ядринцев Онгин язмасын таба — 1897 елда Е. Н. Клеменц Тола елгасы буенда Тоньюкук һәйкәлен таба. Болар бөтен дөньяга мәшһүр Орхон һәйкәлләре була[18]. Ядринцев экспедициясе нәтиҗәләре аның хисап язмасында тасвирланган[19]. Шуларга охшаш язулы ташлар Енисей елгасы буенда да табыла. Таш кыяларга, кабер ташларына, истәлек плитәләргә, аерым эшләнмәләргә һәм акчаларга төшерелгән Орхон-Енисей язуы һәйкәлләре күп санда Минуса казанлыгында, Тывада, Көнчыгыш Казакъстанда, Төньяк һәм Көнбатыш Монголиядә, Кубаньда һәм Донда табыла.

1893 елның 15 декабрендә Дания Корольлегенең Фәннәр һәм тел академиясе утырышында В.Томсен Орхон елгасы буенда табылган рун язуларын уку буенча үз тәҗрибәсен тәкъдим итә. Тиздән В. Томсенның уку ысулы буенча В. В. Радлов Себер язуларын тәрҗемә итә башлый[20]. 1894 елда Кошо-Цайдамдагы Күлтәгин һәм Могилян һәйкәлләрендәге язмаларның рус шәрыкчысы — галим В. В. Бартольд тарафыннан ясалган беренче тәрҗемәләре басыла. Шул вакыттан Орхон-Енисей язмаларын фәнни тикшерү эше башлана. Орхон һәйкәлләре VIII гасырда Билге каһан һәм аның ир туганы Күлтәгин хөрмәтенә куелган була. Рун язулы текстларны өйрәнүдә В. Томсенның эшчәнлеге аерым урын

алып тора. Бу тарихи ядкярләрне тикшерүгә В. В. Радлов, Г. Е. Грумм-Гржимайло, В. В. Бартольд кыйммәтле өлеш кертә.

Иң зур һәйкәлләр Күлтәгингә һәм Могилян каһанга куелган, алар берсеннән икенчесе бер километр ераклыкта, Кошо-Цайдамда урнашкан. Таш баганалардагы язулар төрки халыкларның үткәнен тасвирлый, алар Кытай елъязмаларының хәбәрләре белән раслана. Аннан соң төрки халыкларның күтәрелүе турында бәян ителә, күмелгән шәхеснең игелекле гамәлләре турында языла[21].

Рун текстлы һәйкәлләрнең күбесе тикшерелгән, һәм алар борынгы төркиләр тарихы чагылыш тапкан чыганакларның нигезен тәшкил итә. Ташъязмаларның елъязмалардан өстенлеге шиксез — аларны күчереп язып та, фальсификацияләп тә булмый.

С. Г. Кляшторный һәм В. А. Ромодин билгеләп үткәнчә, В. В. Бартольд XIX гасырның 20 нче елларына кадәр үзен кызыксындырган кайбер проблемалар, аерым алганда Орхон язмаларының тарихи әһәмияте турында хезмәтләр яза, әмма аның төркиләр турында 20 нче еллардагы тикшеренүләре үзенең хронологиясе һәм проблемасының киңлеге белән аерылып тора[22].

Әгәр борынгы төркиләрне өйрәнүче күпчелек галимнәр бу проблемага этнографик һәм лингвистик яктан килгән булса, В. Григорьев аны сәяси яктан тикшерә. Рус хөкүмәтенең төркиләргә мөнәсәбәте турында ул оригиналь фикер әйтә: Кытай күчмәннәрне ламаизм көче белән буйсындыра алды, ә Россия — корал көче белән[23].

Борынгы төркиләр тарихының аерым аспектлары XX гасырның 10 нчы — 20 нче елларында татар тарихчылары Р. С. Фәхреддинев, Г. С. Гобәйдуллин, Г. А. Баттал тарафыннан яктыртылды. Р. С. Фәхреддинев болгарлар һуннар кебек үк төрки булганнар дип фараз итә. Ул фин-угорларның бер өлешенең болгарлар тарафыннан ассимиляцияләнү мөмкинлеген кире какмый[24]. Г. А. Баттал хәзәр, болгар һәм XI гасырда Көнчыгыш Европага килгән кыпчак-команнар мәдәнияте һәм теленең кардәшлеген күрсәтә[25]. Г. С. Гобәйдуллин, Көнчыгыш Европа далаларының көньягында бик борынгы заманнардан төрки кабиләләр тормыш алып барды, дип яза. Безнең эраның I гасырында төркиләр Идел буе далаларында яши, урманнарда фин-угор кабиләләре көн күрә. 374 елда Көнчыгыш Европага килеп чыккан һуннарны ул безнең эраның 93 елында Кытай тарафыннан һәлакәткә дучар ителгән Азия сөннәренең варислары дип карый. Һуннар Каспий, Идел һәм Азов буйларындагы далаларда яшәгән төркиләр арасына килеп чыга һәм аларны буйсындыра. Хәзәр каһанлыгын һәм Кубрат ханның Болгар дәүләтен ул Аттила җитәкләгән Һун дәүләтенең дәвам итүе дип таный[26].

Тюрколог Әхмәтзәки Вәлиди 1915 елда басылган «Төрек-татар тарихы» исемле фәнни әсәренең баштагы ике бүлеген борынгы төркиләргә багышлый. Ул Н. Я. Бичурин һәм Г. Е. Грумм-Гржимайло тарафыннан тәрҗемә ителгән Кытай чыганакларыннан, шулай ук Вамбери, В. В. Бартольд, Н. А. Аристов, К. Иностранцев, В. В. Радлов, Н. М. Ядринцев һ.б. тюркологлар хезмәтләреннән файдалана. 1917 елда Ә. Вәлиди татар мәктәпләре өчен дәреслек сыйфатында «Кыскача төрек-татар тарихы» исеме астында бу әсәрнең бераз кыскартылган вариантын бастыра[27].

Тарихчы Һади Атласи «Себер тарихы» исемле әсәрендә борынгы төркиләр проблемаларын да яктырта. Ул юнан тарихчылары тарафыннан тасвирланган Скифия — төркиләр иле, аны фарсылар Туран дип атаган, ә Урал аръягында яшәгән скифлар — төркиләр булган дип яза[28].

В. В. Бартольдның борынгы һәм урта гасырлар тарихы буенча тикшеренүләрен А. Н. Бернштам, С. П. Толстов һәм С. В. Киселев дәвам итте. А. Н. Бернштам, борынгы төрки рун язмаларга таянып, Бөек Төрки каһанлыгының социаль төзелешен тикшерде. С. В. Киселев һәм С. П. Толстов бигрәк тә борынгы төрки дәүләтләрнең социаль-икътисади проблемаларын өйрәнүне дәвам иттеләр. Бу галимнәр борынгы төрки җәмгыятьнең характерына һәм борынгы төрки дәүләтләрнең тарихына бөтенләй яңа бәя бирде, аларның тарихи үсешен колбиләүчелек һәм хәрби-демократия строеның иртә феодаль мөнәсәбәтләр системасына әверелүе белән бәйләде[29].

А. Ю. Якубовский хезмәтләре Урта Азия төркиләренең этногенезына һәм борынгы уйгырлар тарихына багышланган[30].

Борынгы төрки кабиләләрнең килеп чыгышы, этник тарихы, этногенезы һәм Евразиянең төрки дәүләтләре төзелүе тарихы проблемалары М. А. Артамонов, С. И. Вайнштейн, Д. Д. Васильев, А. С. Васютин, Б. Е. Кумеков, Д. Клосон, П. М. Мелиоранский, Л. П. Потапов, М. А. Сеидов, С. Е. Малов, С. А. Плетнева һ. б. галимнәр хезмәтләрендә яктыртыла[31].

С. Г. Агаджанов, П. В. Голубовский һәм В. А. Гордлевский угызлар, төрекмәннәр, кыпчаклар, сәлҗүкләр, бәҗәнәкләр турында тарихи чыганакларга нигезләнгән әһәмиятле хезмәтләр язды. М. А. Артамонов скифларның килеп чыгышы һәм хәзәрләр тарихы турындагы хезмәтләре белән тарих фәненә кереп калды[32].

Борынгы төркиләр тарихының төрле аспектларын тикшерүгә С. Г. Кляшторныйның шактый сандагы хезмәтләре багышланган[33]. Борынгы төркиләр тарихын өйрәнү һәм язу дәвам итә. Чөнки бу тарих гаять зур мәйданнарны һәм күп гасырларга сузылган озын чорны үз эченә ала. И. П. Засецкая Көнчыгыш Европада һуннар чорында

кучмәннәр мәдәнияте турында, Л. Б. Гмыря Дагстанның Каспий буенда яшәгән һуннар һәм башка халыкларның тарихын, көнкүрешен, мәдәниятен тикшерүгә багышланган хезмәтләр яздылар[34]. Шулай ук бу юллар авторының Себердә һәм Үзәк Азиядә яшәгән борынгы төркиләр тарихын тасвирлаган хезмәте басылды, һәм Себер татарлары тарихын яктырткан китабында бер бүлек борынгы төркиләргә багышланган[35]. С. Х. Алишевның «Борынгы төрки дөнья» исемле китабы басылды[36]. Җиде том итеп уйланылган «Татарлар тарихы» исемле хезмәтнең беренче томы басылып чыгу тарих фәнендә әһәмиятле вакыйга булды. 34,5 табаклы бу томда борынгы Евразия далалары халкының тарихы тасвирлана. Атаклы тюрколог С. Г. Кляшторный җитәкчелегендәге авторлар коллективы татар халкы этногенезына нисбәтле төрки кабиләләр, халыклар тарихын бәян итә[37].

Борынгы төркиләр турында Л. Н. Гумилев күп санлы хезмәтләр язды, ул бу әсәрләрендә кучмәннәр проблемасына, аерым алганда борынгы төркиләр проблемасына яңача якын килде. Аның бу проблемага багышланган хезмәтләрен санап чыгу берничә битне алган булыр иде, шуңа күрә аларның иң әһәмиятлеләрен генә искә алып китәбез[38].

Җитмешенче еллар ахырында телче галимнәрнең төрки телләр турында хезмәтләре дөнья күрде. Адилә Айда (Төркия) һәм Ә. Кәримуллин этрускларның һәм Америка индеецларының кайбер кабиләләре телләренең төрки телләр белән кардәшлеге турында фикер әйттеләр[39].

Бу хезмәтне язганда, борынгы төркиләрнең турыдан-туры үзләре калдырган язма чыганаклары, шулай ук күрше илләрнең һәм башка мәмләкәтләрнең төрки телле кабиләләр белән очрашкан вәкилләре тарафыннан язылган икенчел язма чыганаклар да файдаланылды. Шулай ук археологик, этнографик һәм фольклор материаллары кулланылды.

Югарыда әйтелгәнчә, Монголиянең, Минуса казанлыгының, Шәркый Төркестанның һ. б. региуннарның төрле урыннарында табылган борынгы төрки телдә язылган чыганаклар борынгы төркиләрнең ышанычлы төп язма чыганакларыннан санала. Россиядә бу чыганаклар ике йөз елдан артык тупланып килә.

Борынгы төркиләр тарихы буенча төрки рун язмаларына караганда күпкә борынгырак язма чыганаклар да бар. Болар — Кытай елъязмалары һәм тарихи хроникалары. Алар бик әһәмиятле чыганаклар булып тора, чөнки Кытай бик борынгы заманнардан Көньяк Себердә яшәүче халыклар белән элемтәдә булган. Кытайда елъязмалар төзү (ганг-шу) хөкүмәт тарафыннан һәм аның күзәтүе астында алып барылган, ул үзенең чиновникларына илдәге һәм чит илләрдәге вакыйгаларны язып барырга кушкан. Аннан соң бу язмалар Дәүләт Тарих җәмгыятенә

тапшырылган, соңгысы алар буенча елъязмалар төзегән, анда вакыйгалар хронологик тәртиптә язып барылган.

Тарихны билгеле бер эзлеклелектә яза башлау (шу) кытайларда б.э.к. соңгы йөз елда күзәтелә, һәм ул Тарих җәмгыятенең рәисе, Кытай тарихының атасы Сыма Цянь исеме белән бәйле. Сыма Цянь Хань империясенең рәсми тарихчысы (историографы) Сыма Тянь улы була. Б.э.к. 108 елда ул әтисе вазифасын варис буларак ала һәм бик тырышып эшли. Б.э.к. 90 елда ул зур хезмәт тәмамлый, бу әсәр киләчәк династия тарихларына үрнәк булып кала. «Ши-цзи» исемле бу хезмәт 130 бүлектән тора, анда Кытай тарихы бик борынгы заманнардан башлап б.э.к. 89 елгача тасвирлана. Бәяләп бетергесез бу әсәрен Сыма Цянь безгә кадәр сакланмаган тарихи чыганаклардан файдаланып язган. Борынгы Кытайда тарихны династияләп язу гадәте була. Бу тарих династия яшәүдән туктагач кына игълан ителгән. Сыма Цянь да вакыйгаларны династияләр буенча сурәтләгән. Автор чит халыкларга үз әсәренең алты бүлеген багышлый. Өч бүлектә сөннәр, Тибет һәм көнбатыш кабиләләре тарихын тасвирлый. Сыма Цяньга кадәр «Шань-шу» «Го-юй» һәм «Чунь-цю» исемле Кытай хроникаларында аерым өзек-өзек хәбәрләр була, әле бу әсәрләрдә «сөн» сүзе юк, аларны «төньяк варварлары» яки «көнбатыш варварлары» дип атаганнар[40].

Сыма Цяньның «Тарихи язмалар»ы — сөннәр тарихын эзлекле яктыртучы иң беренче тарихи әсәр. Анда сөн җәмгыятенең төзелеше турында төп мәгълүматлар тупланган, һәм бу хезмәт, аның сәяси төзелешен, идарә системасын өйрәнү өчен, зур кыйммәткә ия. Сыма Цянь сөннәр турында бик борынгы заманнан алып үзе яшәгән чорга кадәрге мәгълүматларны эзлекле хикәяләүгә сала. Ул, сөннәрнең борынгы бабалары «жун» исемле кабиләләр булган, дигән фикергә килә. Сөн җәмгыятенең үсү тарихын Сыма Цянь ике чорга бүлеп карый. Беренчесе сөннәрнең риваятьләргә кереп калган ыруг башлыгы Шунь-вэйдан башлана, ул сөннәр белән Ся династиясе чорында (б.э.к. 2219—1819) Төмән шаньюйга кадәр идарә иткән (? — б.э.к. 209). «Шань-шу», «Го-юй» һәм «Чунь-цю» елъязмаларында сөннәр турындагы хәбәрләр эпизодик рәвештә бик өзек-өзек бирелгән, аларда озын хронологик бушлыклар бар, аерым очракларда ул бушлыклар 300 елга һәм озаккарак сузыла. Шуңа күрә Сыма Цяньга сөннәрнең бу чор буенча өзлексез тарихын язу мөмкин булмаган.

Икенче чорның тарихы Модэ шаньюй идарәсеннән башлана. Сөн җәмгыятенең, бигрәк тә Модэ идарәсеннән башлап сәяси системасы ачык яктыртылган[41].

Кытайда тарих язу фәне Сыма Цяньнан соң да үскән. Ул Кытайда мактаулы шөгыль була, чөнки тарихи хәтер милләтнең намусы саналган, иң гайрәтле императорның да репутациясе тарих язучы кулында булган.

Сыма Цянь эшен дәвам итүчеләрдән Бань Гу (32—92) 85 елда «Элгәре Хань династиясе тарихы» (Хань-шу) һәм Фань Е (398—445) «Соңгы Хань династиясе тарихы» (Хоухань-шу) исемле тарихи әсәрләр яза. Тарихчы Фан Сюаньлиньның әсәре сөн тарихының иң соңгы этабына багышлана. Фан Сюаньлинь үзенең язмаларын Сыма Цянь, Бань Гу һәм Фань Е тарафыннан язылган вакыйгалар белән бәйли. Шулай итеп, югарыда исемнәре аталган Кытай тарихчыларының әсәрләре сөннәр тарихының барлык чорларын да яктырткан эзлекле тарихи язма булып тора[42]. 2 меңьеллыкның башында тарихчы Сыма Гуан (1009—1086) «Цзи чжи тун цзянь» исеме астында Кытайның прагматик тарихын яза, ул V—X гасырларны эченә ала. Кытайның барлык соңгы тарихчылары да, элеккеләре кебек, Үзәк Азия, Урта Азия һәм Көньяк Себер халыклары турында күп хәбәрләр җиткерә[43].

Кытай тарих фәне үз хөкүмәтенең заказын үти һәм тенденциоз була. Кытайның ролен, әһәмиятен һәм уңышларын күпертеп күрсәтү Кытай тарихчыларының бурычы булып торган. Киресенчә, җиңелүләр, уңышсызлыклар турындагы хәбәрләр кечерәйтелгән. Һәрвакытта диярлек гаскәрләр саны, үзенеке булсын, дошманныкы булсын, күпертелгән, гадәттә, түгәрәк саннар белән күрсәтелгән: 10 мең, 100 мең.

Кытай тарихчылары күчмә халыкларның эчке тормышы турындагы хәбәрләрне Кытай разведкасы мәгълүматларыннан алган. Шымчыларны хәрби мәсьәләләр кызыксындырган, ә халыкларның хуҗалыгы, мәдәнияте һәм әхлагы турында алар сирәк язганнар. Шуңа күрә Кытай тарихчылары язмаларында бу проблемалар аз тасвирланган.

Кытай тарихчыларына хронологик төгәллек, фантастиканың, уйлап чыгаруларның булмавы хас. Әмма кайбер вакыйгалар бик нык үзгәртелгән, шуңа күрә бигрәк тә сөннәрне һәм кытай булмаган башка халыкларны тасвирлауга тәнкыйть күзе белән карау мөһим[44]. Кытай чыганакларында төрки телле динлиннар дәүләте — Динлин Го турында өзек-өзек мәгълүматлар бар.

Кытай тарихи язмаларын Европа телләренә XVII гасырда тәрҗемә итә башлыйлар (Дегинь, А. Ремюза, Клапрот, С. Жульен һ. б.). Алар белән без рус галимнәренең тәрҗемәсе яки тәфсире аша файдаланабыз. Болар арасында беренчеләрдән Н. Я. Бичурин (Иакинф) була. Ул 1777 елда чуваш гаиләсендә туа. 1807 елдан башлап, 14 ел буе Кытайда православие миссиясе башлыгы була. 1828—1851 елларда күп санлы хезмәтләр яза. Аның төп әсәрләре Урта һәм Үзәк Азия төркиләре, Кытай тарихы мәдәнияте философиясенә багышлана. Эрудициясе, язылган материалның күләме буенча ул Көнбатыш Европа тикшерүче галимнәреннән күпкә өстен тора. Рус теленә Кытай чыганакларының шактый өзекләрен тәрҗемә итә. Кытай тарихи хроникасының ул ясаган тәрҗемәләре хәзергә кадәр иң ышанычлы

чыганаклардан санала. Әмма кытай теленең бик яхшы белгече булган Н. Я. Бичуринга тарихи талант җитенкерәмәгән. Аның фикере буенча, Урта һәм Үзәк Азиядә борынгы заманнардан алып хәзерге көнгә кадәр бер үк халыклар яшәгән. Күчмәннәр турында кытай телендә язылган хәбәрләрне ул механик юл белән, аларга тәнкыйди мөнәсәбәтсез, дөреслеген тикшермичә тәрҗемә иткән. Сөннәрне һәм ту-кюларны Н. Я. Бичурин монголлардан саный, аларны «дулга» дип атый. Кытай чыганаклары нигезендә ул көнчыгыш төркиләрнең 535 елдан алып 745 елга кадәр һәм көнбатыш төркиләрнең 666 елдан алып 766 елга кадәр булган тарихын яза. 1828 елда «Монголия турында язмалар» исемле хезмәтен бастырып чыгара. 23 елдан соң аның «Борынгы заманнарда Урта Азиядә яшәгән халыклар турында хәбәрләр җыелмасы» исемле бик тә әһәмиятле хезмәте чыга. Н. Я. Бичурин «сөн-һун» проблемасына тәнкыйть күзлегеннән карамый. Аныңча, сөннәр безнең эраның 15 елында Кытай императоры Ван Миннан «сөн» дигән үз исемнәрен «һун»га алмаштыру турында тәкъдим алалар. Кытай телендә «сөн» — усал кол, «һун» — мәгънәле кол. Һуннар, император тәкъдименә риза булып, 15 елда, имеш, «һун» исемен ала[45].

Географ, Урта һәм Үзәк Азияне өйрәнүче галим Г. Е. Грумм-Гржимайло Кытай чыганакларын өйрәнүгә яңача якын килә. Ул 1884—1914 елларда Урта һәм Үзәк Азия буенча берничә зур сәяхәт ясый. Кытай язма тарихи чыганакларын өйрәнү нәтиҗәсендә, «Көнбатыш Монголия һәм Урянхай крае» исемле уникаль фәнни хезмәт яза, ул Азия тарихын өйрәнүче барлык тарихчыларның өстәл китабына әверелә[46].

Әлеге китапны язганда, шулай ук Н. В. Кюнерның Көньяк Себер, Үзәк Азия һәм Ерак Көнчыгыш халыкларының тарихы буенча Кытай тарихи язмаларын өйрәнүгә багышланган хезмәте дә чыганак буларак файдаланылды[47].

Фәнни җәмәгатьчелектә В. С. Таскинның сөннәр, дунху төркеме халыклары, Кытай күчмәннәре турындагы хезмәте дөресрәк һәм төгәлрәк дип табылды. В. С. Таскин тарафыннан җыелган һәм тәрҗемә ителгән Кытай чыганаклары материаллары Сөннү тарихын, аның күршеләр белән мөнәсәбәтен, шулай ук сөн җәмгыятенең эчке структурасын һәм сәяси төзелешен күзалларга мөмкинлек бирә. В. С. Таскинның тәрҗемәләре Сыма Цяньның, Бань Гуның, Фань Еның, Сюаньлиньның хезмәтләрен үз эченә ала[48]. Сөннәр һәм башка төркиләр тарихын өйрәнгәндә, совет тарихчылары Н. Я. Бичурин хезмәтләреннән файдаланды. В. С. Таскин Н. Я. Бичурин тәрҗемәләрендә фактик ялгышлар барлыгын билгеләп үтә. Аның әйтүенчә, Л. Н. Гумилев һәм С. И. Руденко, бу тәрҗемәләрне файдаланып, сөннәрнең сәяси тормышын өйрәнүдә ялгышлар җибәрәләр. В.С.Таскин бу ялгышларны билгеләп үтә[49].

Скифлар, Урал аръягында яшәгән аргиппейлар турында хәбәрләрне юнан (грек) тарихчысы Геродот хезмәтендә табарга була (б.э.к. V гасыр)[50].

Византия тарихчылары хезмәтләрендә әһәмиятле мәгълүматлар саклана. Алар нигездә көнбатыш төркиләргә һәм Европа һуннарына кагыла. Беренче Төрки каһанлыгы каһаны Силзивул (яки Дизавул) 568 елда Константинополь шәһәренә Маниах җитәкчелегендә илчелек җибәрә. Моңа җавап итеп Византия императоры Юстин II Көнбатыш Төрки каһанлыгына Земарх Киликиецны җибәрә, ул Маниах белән бергә Дизавул янына килеп җитә. Дизавул белән шартнамә төзеп, Земарх Константинопольгә кайта, әмма үзе генә түгел, аның белән бергә Константинопольгә Төрки каһанлыгы илчесе Тагма да килә. 576 елда, император Тиверий Кесарь хакимлеге чорында, византиялеләр төркиләргә яңадан делегация җибәрә. Бу юлы Византиядән илче булып Валентин килә, аны элек Византиядә яшәгән төркиләр озатып бара. Чыганаклар күрсәтүе буенча, аларны элек төркиләрдә илче булып торган Анавгист алып килә. Аннан соң Көнбатыш Төрки каһанлыгында илчеләр булып Иордан һәм Павел Киликиец торганнар. Валентин килгәндә, «төрки кенәзләренең» берсе Турксанф була. Валентин Турксанфның туганы Тарду янында да була.

Византия тарихчысы Менандрның 558 елдан 582 елга кадәрге чорны фрагментар рәвештә тасвирлаучы «Тарих» исемле әсәрендә Византия илчеләренең Көнбатыш Төрки каһанлыгына баруы белән бәйле вакыйгалар сурәтләнә. Әсәрдә каһанлыкка бару юлы, бу юл буйларында яшәгән халыклар, төрек каһаннарының сарае, аларның байлыгы, әхлагы һәм төрекләрнең йола-гадәтләре сурәтләнгән[51].

Тарихчы Феофан Византияле 565—581 еллардагы вакыйгалар турында 10 китаптан торган әсәр язып калдырган. Әсәрнең безгә килеп җиткән өлешләрендә, ул чорда Каспий буенда яшәгән савирлар (сабирлар) турында һәм төркиләрнең эфталитлар белән үзара мөнәсәбәтләре турында хәбәрләр бар[52]. Һуннар һәм эфталитлар турында хәбәрләр Византия тарихчысы Прокопий Кесарийскийның «Тарих» исемле әсәрендә дә бар[53].

Шулай ук Византия тарихчысы Дионисий Перигиетның «Кешеләр яши торган җирне сурәтләү» исемле хезмәтендә һуннарның Каспий буе далаларыннан алып Уралга кадәр җәелгән җирләрдә килеп чыгуы турында иң беренче булып искә алына. Византия тарихчысы Аммиан Марцеллин «Гамәлләр» («Тарих») исемле 31 китаптан торган хезмәт яза. Безнең көннәргә кадәр 14 нчедән башлап 31 нчегә кадәр булган китаплар килеп җиткән. Бу әсәрдә 353—378 еллардагы вакыйгалар тасвирлана, анда һуннар, аларның социаль төзелеше, хәрби эшләре һәм шөгыльләре турында кыйммәтле хәбәрләр бар[54]. Кавказ Албаниясе

тарихчысы Мовсес Каланкатуаци VII гасыр башында яшәгән төркиләр турында хәбәрләр бирә[55].

Борынгы төркиләр турында гарәп һәм фарсы чыганаклары нигездә В. В. Бартольд хезмәтләре буенча файдаланылды[56].

IX гасырның 80 нче елларында Багдад хәлифәлегенең почта һәм хәбәрләр хезмәте башлыгы Ибн Хордадбех «Китаб әл-мәлик әл-мәсәлик» («Юллар һәм дәүләтләр китабы») исемле китап яза, анда кәрван юллары тасвирлана, аерым урыннар арасындагы ераклык күрсәтелә, төркиләр, шул исәптән кыпчаклар һәм кимәкләр турында мәгълүматлар тупланган[57].

IX гасырның икенче яртысында гарәп Әл-Мутавал кимәкләр һәм кыпчаклар җирләре аша тугыз-угызларга бара. Аның юл тасвирламасы, төркиләр турында хәбәрләре соңрак башка авторлар тарафыннан файдаланыла[58].

Багдадта туган Әл-Җаһиз «Манакиб әл-Әтрак» («Төркиләрнең өстенлекләре») исемле китабында Урта Азиянең төньягы, Казакъстандагы төрки кабиләләрнең хәрби сыйфатлары, гадәтләре, әхлагы турында энциклопедик белемнәр калдыра[59].

X гасыр гарәп тарихчысы һәм географ Әбу әл-Хәсән Али ибн әл-Хөсәен әл-Масуди «Әхбәр әз-заман» исемле 30 томлык энциклопедия яза. Безгә аның өзекләре генә һәм «Китабат-тәнбих вә-л-ишраф» исемле әсәре килеп җитә. Әл-Масуди төркиләр турында кыйммәтле тарихи-географик мәгълүмат китерә[60].

Әл-Мөкаддәси (947—1000) «Әхсән әт-тәкасим фи мәгърифәт әл-акалим» («Климатларны аңлау өчен иң яхшы бүленеш») исемле әсәрендә төркиләр турында кыйммәтле географик мәгълүмат калдыра. Автор үзеннән элгәре географлар мирасына тәнкыйди яктан караган[61].

Урта Азиянең X гасырда яшәгән атаклы галиме Әл-Бируни 105 исемдә хезмәт язып калдыра. Безнең көннәргә аның төрки кабиләләрнең урнашуы, аларның гадәт-йолалары турында булган 20 гә якын әсәре килеп җиткән[62].

Әл-Гардизи «Зәйнәл әл-әхбәр» («Хәбәрләрне бизәү») исемле хезмәтендә төркиләр турында гаҗәеп үзенчәлекле мәгълүматлар китерә[63].

Күренекле тел галиме Мәхмүд Кашгарый «Диване лөгатет-төрк» хезмәтендә, лингвистик хәбәрләрдән башка, төрки кабиләләрнең үзара мөнәсәбәтләре, хуҗалыгы турында да яза[64].

«Худуд әл-алам мин мәшрик илә-л-мәгъриб» («Көнчыгыштан көнбатышка дөньяның чикләре») исемле аноним географик трактат шулай ук борынгы төркиләр турында алыштыргысыз чыганак булып тора. Ул 982 еллар тирәсендә фарсы телендә язылган. Төркиләр турында күп мәгълүмат туплаган бөтен бер бүлек Кимәк каһанлыгына

һәм кимәкләрнең иҗтимагый төзелешенә багышлана. Бу әсәрне беренче булып В. В. Бартольд җентекләп өйрәнә [65].

Безнең китапта Ф. Г. Дебец, Л. А. Евтюхова, Л. Р. Кызласов, С. В. Киселев, А. В. Давыдова һәм Л. Б. Гмыря, Б. Н. Граков, М. П. Грязнов, П. А. Дмитриев, А. Х. Маргулан, С. И. Руденко хезмәтләрендә күрсәтелгән археологик чыганаклар файдаланылды[66]. Татар халкының һәм аның ата-бабаларының борынгы тарихы буенча А.Х.Халиков хезмәтләре дә шулай ук лаеклы урын алып торалар[67].

Галимнәрнең шактый хезмәтләре борынгы төрки фольклорына багышланган. Бу өлкәдә эшләгән В. М. Жирмунский, Малчы-Мерген, Ф. Е. Корш, В. В. Стеблева хезмәтләре дә файдаланылды[68].

Борынгы төркиләр турындагы сүз күчмә тормышны тасвирлаудан башлана, чөнки Бөек даланың барлык халыклары да тарихи үсешнең бу стадиясен үтә. Безнең тикшерүнең беренче объекты булып сөннәр тора, аларның беренчел бабалары бик борынгы заманда Хуанхэ елгасы урта агымының төньягында — Ордос өлкәсендә яшәгән. Алардан төньяктарак һәм көнбатыштарак башка төрки кабиләләр яши.

Кытайның даими агрессиясе нәтиҗәсендә һәм яхшырак көтүлекләр эзләп, Үзәк Азия күчмәннәре төньякка таба хәрәкәт итә һәм Тянь-Шаньның Ыссык күл буендагы таулы җирләренә, Алтай, Саян тауларына, Байкал буйларына килә. Монголияне үзләштереп, Хангайны үтәләр. Орхон буйлап узып, Онон-Керулен түбәләренә хуҗа булалар. Бик борынгы заманнардан төркиләр Минуса казанлыгының хуҗалары була, аннан алар урманлы зонага үтә, Обь, Иртеш, Ишим, Тубыл һәм аларның кушылдыклары тирәсендәге тигезлекләрне һәм яр буе зоналарын били[69]. Күчмәннең күчеп йөрүе аның терлеге һәм үзенең табигый туклану ысулы белән бәйле. Үлән табарга уңайлы урыннарда күчмән хәрәкәтен әкренәйтә һәм терлекләрен бер урында озаграк асрый. Күченүдән утраклыкка күнегү фазалары шулай башлана. Әкренләп, халыкның һәм терлекләрнең саны үсүгә бәйле рәвештә, көтүлекләрне һәм кышлау урыннарын ыруг һәм кабиләләр арасында бүлү процессы бара. Әмма күчмә терлекчелектән утраклыкка күчү процессы озак, кайвакытта гасырлар буе дәвам итә.

Ләкин күченү процессына табигый факторлар гына тәэсир итми, аңа кабиләләр һәм халыклар арасындагы үзара мөнәсәбәтләр дә йогынты ясый. Халыкның һәм терлекнең саны үсүе белән көтүлекләргә мохтаҗлык арта һәм аларны кайвакыт яулап алырга туры килә. Шул нигездә кабиләләр арасында дошманлык һәм сугышлар килеп чыга. Көчле кабиләләр берләшеп, дәүләтләр барлыкка килә.

Без бу хезмәттә сөннәр, борынгы төркиләр һәм алар төзегән дәүләтләр — Бөек Сөн каһанлыгы, Бөек Төрки каһанлыгы, Уйгыр

каһанлыгы, Кыргыз каһанлыгы һәм Кимәк каһанлыгы тарихы белән танышырбыз. Китапта шулай ук хәзәрләр, болгарлар һәм Европа һуннары турында да кайбер мәгълүматлар бар.

Хәзерге төрки халыкларның тарихы борынгы төрки дәүләтләр тарихына барып тоташа. Төрки дәүләтчелекнең тууы, үсеше шул мәмләкәтләрдә барган. Төрки дәүләтчелек эстафетасы соңыннан урта гасыр чорындагы төрки дәүләтләрдә дәвам иткән.

---

[1] *Грач Д. Д.* Хронологические и этнокультурные границы древнетюркского времени // Тюркологический сборник.— М., 1966.— С. 190.

[2] *Карамзин Н. М.* История государства Российского. Т. I.— СПб., 1818.— С. 5—12; *Семенов-Зусев С. А.* Скифская проблема в отечественной истории. Опыт историографии скифов. Ч. I.— Харьков, 1947.— С. 11.

[3] *Гумилев Л. Н.* Ритмы Евразии. Эпохи и цивилизации.— М.: «Экопрос», 1993.— С. 8, 27.

[4] *Seferoglu Şhukru Kaya, Muderisoglu Adnon.* Turk Devletleri Tarihi. (Etnologik bir deneme) // Azerbeeican Kultur Dernegi Yayilari.— Ankara, 1986.— № 21.— S. 11—28.

[5] *Халиков А. Х.* Татарский народ и его предки.— Казань, 1984.— С. 54.

[6] *Лайпанов К. П., Мизиев И. М.* О происхождении тюркских народов.— Черкесск, 1993.— С. 115.

[7] *Сулейменов Олжас.* Тюрки в доистории: О происхождении тюркских языков и письменности.— Алматы: Атамура, 2002.— С. 83—84.

[8] *Zeki Velidi Togan.* Umumi Turk Tarihina girish. 3 baski.— Istanbul, 1981.— S. 10—17.

[9] *Battal Taymas.* Kazan Turkleri.— Istanbul, 1925.— S. 17—18.

[10] *Зәкиев М. З.* Төрки-татар этногенезы.— Казан-Мәскәү, 1998.— 90—95 б.; *Закиев М. З.* Татары. Проблемы истории и языка.— Казань, 1995.— С. 10—11.

[11] *Иностранцев К.* Хунну и гунны // Труды тюркологического семинара. Вып. I.— Л., 1936.— С. 12.

[12] *Иностранцев К.* Күрсәтелгән хезмәт, 14 б.

[13] *Бартольд В. В.* Новые исследования об орхонских памятниках // Журнал Министерства народного просвешения, 1889. Вып. 9—10; *Бартольд В. В.* Отчет о поездке в Среднюю Азию с научной целью.— СПб., 1897; *Бартольд В. В.* В. Т. Томсен и история Средней Азии.— Л., 1926.

[14] *Witzen N.* Noord and Oost Tartarye.— Amsterdam, 1692.

[15] *Катанов Н. Ф.* Швед Филипп-Иоганн Страленберг и его труды по России и Сибири (начала XVII в.) // Известия Общества археологии, истории и этнографии. Т.XIX.— Казань, 1903.— С. 3—9.

[16] *Васильев Д. Д.* Графический фонд памятников тюркской рунической письменности Азиатского ареала.— М., 1983.— С. 5—6.

[17] *Васильев Д. Д.* Күрсәтелгән хезмәт, 9 б.

[18] *Кляшторный С. Г.* Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии.— М., 1964.— С. 6.

[19] *Ядринцев Н. М.* Отчет о поездке в Монголию и вершины Орхона// Известия Восточно-Сибирского отделения Русского географического общества. Т. XX. Вып. 4.— С. 1—13.

[20] *Radloff W.* Die altturcischen Inschriften in der Mongolei. III.— St. Pbg., 1895; *Thomsen W.* Inscriptions de' Orkhon. MSFO.— Helsingfors, 1896.— S. 141.

[21] *Radloff W. W.* Die alturkischen Inschriften in der Mongolei. I— II Lief.— St. Pbg., 1894.— S. 76.

[22] *Бартольд В. В.* Сочинения. Т. II. Ч. 2.— М., 1963—1964; *Бартольд В. В.* Сочинения. Т.V.— М., 1968.

[23] *Григорьев В.* Об отношениях между кочевыми народами и оседлыми государствами // Журнал Министерства народного просвещения, 1875.

[24] *Фәхреддинев Р. С.* Болгар вә Казан төрекләре.— Казан, 1993.— 23 б.

[25] *Баттал Г. А.* Казан төркиләре.— Казан, 1996.— 28 б.

[26] *Гобәйдуллин Г. С.* Татар тарихы.— Казан, 1923.— 13—17 б.

[27] *Вәлиди Ә. Ә.* Төрек-татар тарихы.— Казан, 1915; Кыскача төрек-татар тарихы.— Казан, 1917.

[28] *Атласи Һ. М.* Себер тарихы.— Казан, 1911.— 23 б.

[29] *Бернштам А.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI—VIII в.— М.; Л., 1946; Восточно-Тюркский каганат и кыргызы.— М.; Л., 1946; *Толстов С. П.* По следам древнехорезмийской цивилизации.— М.; Л., 1948; *Киселев С. В.* Древняя история Южной Сибири.— М., 1951.

[30] *Якубовский А. Ю.* К вопросу об этногенезе узбекского народа.— Ташкент, 1941; Вопросы этногенеза туркмен в VII—X в. // Советская этнография. —1947.— № 3.

[31] *Артамонов М. А.* История хазар.— Л., 1951; *Вайнштейн С. И.* Некоторые вопросы истории древнетюркской культуры (в связи с археологическими исследованиями в Туве) // Советская этнография.—1966.— № 34; Восточно-Тюркский каганат и кыргызы.— М.; Л., 1946; *Васильев Д. Д.* Графический фонд памятников тюркской рунической письменности Азиатского ареала (опыт систематизации).— М., 1983; *Кумеков Б. Е.* Государство кимаков IX—XI веков по арабским источникам.— Алма-Ата, 1972; *Васютин А. С.* Культовые памятники древних тюрок Алтая

(VII—X в. н.э.) // Автореф. дис... канд. ист. наук.— Кемерово, 1983.— С. 23—30; *Мелиоранский П. М.* Памятник в честь Кюль-тегина.— СПб., 1899; *Потапов Л. П.* Ранние формы феодальных отношений у кочевников // Записки Хакасского НИИ языка, истории и литературы. Вып.1.— Абакан, 1952.; *Сеидов М. А.* Заметки о гуннской мифологии (VII в.) // Советская тюркология.— 1970.— № 2; *Малов С. Е.* Енисейская письменность тюрков. Тексты и переводы.— М.; Л., 1952; Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии.— М.; Л., 1959; *Плетнева С. А.* Хазары.— М., 1976; Половцы.— М., 1990.

[32] *Агаджанов С. Г.* Очерки огузов и туркмен Средней Азии IX—XIII в.— Ашхабад, 1969; *Голубовский П.* Печенеги, торки и половцы до нашествия татар.— Казань, 1884; *Гордлевский В. А.* Государство сельджукидов в Малой Азии.— М.; Л., 1950.

[33] *Кляшторный С. Г.* Древнетюркские рунические памятники.— М., 1964; Кипчаки в рунических памятниках // Turcologica. К 80-летию акад. А. Н. Кононова.— Л., 1986; Формирование тюркской государственности: от племенного союза до Первого Тюркского каганата // Панорама-форум.— Казань, 1997.— № 1.— С. 118—124; Кто были половцы // Алтаика. II.— М., 1998; Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии.— М., 1964; Древнетюркская письменность и культура Центральной Азии (по материалам полевых исследований в Монголии. 1968—1969 гг.) // Тюркологический сборник (ТС).— М., 1972, 1973; Мифологические сюжеты в древнетюркских памятниках // ТС.— М., 1977, 1981; Формирование тюркской государственности: от племенного союза до Первого Тюркского каганата// Панорама-форум.— 1997.— № 1; *Кляшторный С. Г., Султанов Т. И.* Государства и народы Евразийских степей. Древность и средневековье.— СПб., 2000.

[34] *Засецкая И. П.* Культура кочевников Южнорусских степей в гуннскую эпоху (конец IV—Vв.).— СПб., 1994; *Гмыря Л. Б.* Страна гуннов у Каспийских ворот.— Махачкала, 1995.

[35] *Файзрахманов Г. Л.* Древние тюрки в Сибири и Центральной Азии.— Казань, 2000; История сибирских татар с древнейших времен до начала XX века.— Казань, 2002.

[36] *Алишев С. Х.* Древний тюркский мир.— Казань, 2000.

[37] История татар с древнейших времен в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности.— Казань, 2002.

[38] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993; Хунны в Китае. Три века борьбы Китая со степными народами III—VI в.— СПб., 1994; Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991; Древние тюрки.— М., 1993; Ритмы Евразии.— М., 1993; В поисках вымышленного царства.— М., 1992; Древняя Русь и Великая степь.— М., 1992.

[39] *Adile Ayda.* Etruskler'le Isketler arasinda Benzerlikler // VIII Turk Tarih kongresi I.— Ankara, 1979; Adile Ayda. Etruskler (Tursakalar) Turk ideler.—

Ankara, 1992; *Каримуллин А. Г.* О возможном родстве отдельных индейских языков с тюркскими // Вопросы тюркского языкознания.— Казань, 1976; *Каримуллин А. Г.* Прототюрки и индейцы Америки: По следам одной гипотезы.— М., 1995.

[40] *Кроль Ю. А.* Сыма Цянь — историк.— М., 1970; *Сыма Цянь.* Исторические записки. Т. I—II.— М., 1972—1975.

[41] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 2.— М., 1973.— С. 4.

[42] Материалы по истории кочевых народов в Китае III—V в. Вып. 1.— М., 1989.— С. 13.

[43] *Огородников В. И.* Очерк истории Сибири до начала XIX столетия. Ч.I. Введение. История дорусской Сибири.— Иркутск, 1920.— С. 27; Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 2.— М., 1973.— С. 4.

[44] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 50—51.

[45] *Бичурин Н. Я.* Записки о Монголии. Т. I—II.— СПб., 1828; Собрание сведений о народах обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I—III.— СПб., 1851: переиздание Т. I—III.— М.; Л., 1950—1953.

[46] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край.— М.; Л., 1926.

[47] *Кюнер Н. В.* Китайские известия о народах Южной Сибири, Центральной Азии и Дальнего Востока.— М., 1961.

[48] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 1—2.— М., 1968, 1973; *Кюнер Н. В.* Материалы по истории древних кочевых народов группы дунху (по китайским источникам).— М., 1984; Материалы по истории кочевых народов Китая III—V в. Вып. 1.— М., 1989.

[49] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам).— М., 1973.— С. 4, 8, 14.

[50] *Геродот.* История.— Киев, 1908.

[51] Византийские историки / Пер. С. Дестуниса.— СПб., 1861.— С. 416—417.

[52] Выписки из истории Феофана/Пер. С. Дестуниса // Византийские историки.— СПб., 1860.

[53] *Прокопий Кесарийский.* История войн с персами, вандалами и готфами / Пер. с греч. С. Дестуниса // Записки историко-философского факультета. Ч. I.— СПб. ун-та., 1876.

[54] *Аммиан Марцеллин.* История. Кн. 1—3 / Пер. Ю. Кулаковского и А. Сонни.— СПб., 1906—1908; История. Кн. 23 / Пер. В. В. Латышева // Вестник древней истории.— 1949.— № 3.

[55] *Мовсес Каланкатуаци.* История страны Алуанк / Пер. Ш. В. Смбатяна.— Ереван, 1984.

[56] *Бартольд В. В.* Сочинения в 9-ти томах. Т. I. Туркестан в эпоху монгольского нашествия.— М., 1963; Работы по истории и филологии тюркских и монгольских народов по истории Центральной Азии и Дальнего Востока. T.V.— М., 1967.

[57] *Булгаков П. Г.* Книга путей и государств Ибн Хордадбеха (к изучению и дешифровке редакций) // Палестинский сборник. Вып. 3 (66).— 1958.

[58] *Крачковский И. Ю.* Арабская географическая литература // Избр. соч. T.IV.— М.; Л., 1957.

[59] *Мандельштам А. М.* Характеристика тюрок IX в. в «Послании Фатху бин Хакану ал-Джахиза» // Труды Института истории, археологии и этнографии АН Каз. ССР. Т. I. Археология.— 1956.

[60] *Масуди.* Из «Книги сообщений и знаний» / Пер. Н. А. Караулова. Сведения арабской географии IX—X вв. о Кавказе, Армении и Азербайджане // Сборник материалов для описания местностей и племен Кавказа. Вып. XXXVIII.— Тифлис, 1908.

[61] *Крачковский И. Ю.* Арабская географическая литература. Избранные сочинения. T.IV.— М.; Л., 1957.— С. 210—218.

[62] Бируни — великий ученый средневековья.— Ташкент, 1956.

[63] *Бартольд В. В.* Отчет о поездке в Среднюю Азию с научной целью. 1893—1894 // Записки императорской АН. Cep.VIII.— СПб., 1897.

[64] *Малов С. Е.* Памятники древнетюркской письменности.— М.; Л., 1951; М. Кашгари. Турки сузлер дивани. На узб. яз.— Ташкент, 1963.

[65] *Бартольд В. В.* Худуд ал-алам. Рукопись Туманского с введением и указателем.— Л., 1930.

[66] *Дебец Г. Ф.* Палеоантропология СССР.— М.; Л., 1948; *Евтюхова Л. А.* Развалины дома в «земле Хягас» // Краткие сообщения Института истории материальной культуры. Т. XII.; *Евтюхова Л. А., Левашова В. П.* Раскопки китайского дома близ Абакана // Краткие сообщения Института истории материальной культуры. Т. XII.; *Кызласов Л. Р.* Таштыкская эпоха в истории Хакасо-Минусинской котловины.— М., 1960; *Кызласов Л. Р.* История Тувы в средние века.— М., 1969; *Кызласов Л. Р.* История Южной Сибири в средние века.— М., 1984; *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Изд. Краснояр. ун-та, 1992; *Киселев С. В.* Древняя история Южной Сибири.— М., 1951; *Давыдова А. В.* Иволгинский комплекс — памятник Хунну в Забайкалье.— Л., 1985; *Гмыря Л. Б.* Страна гуннов у Каспийских ворот. Прикаспийский Дагестан в эпоху Великого переселения народов.— Махачкала, 1995; *Граков Б. Н.* Работы в районе проектируемых южноуральских гидростанций. Археологические работы на новостройках. Вып. II.— Л., 1935; *Грязнов М. П.* Древние культуры Алтая//Материалы по изучению Сибири. Вып. 2.— Новосибирск, 1930; *Грязнов М. П.* Раскопки на Алтае//Сообщения Гос. Эрмитажа. Вып. 1.— Л., 1941;

Маргулан А. Х. Археологические разведки в долине реки Сарысу// Вестник АН Каз. ССР.— 1947, № 7. *Руденко С. И.* Культура населения Алтая в скифское время.— М., Л., 1953.

67 *Халиков А. Х.* Татарский народ и его предки.— Казань, 1989; Истоки формирования тюркоязычных народов Среднего Поволжья и Приуралья // Вопросы этногенеза народов Среднего Поволжья.— Казань, 1976; Монголы, татары, Золотая Орда и Булгария.— Казань, 1994; Древняя история Среднего Поволжья.— М.: Наука, 1969; Татар халкының килеп чыгышы.— Казан, 1974.

68 *Жирмунский В. М.* Сказание об Алпамыше и богатырская сказка.— М., 1960; *Малчы-Мерген.* Алтайский героический эпос.— Ойротское обл. нац. изд., 1947; *Корш Ф. Е.* Древний народный стих турецких племен.— СПб., 1909; *Стеблева В. В.* Поэзия тюрков VI—XIII в.— М., 1965.

69 *Ядринцев Н. М.* Сибирские инородцы, их быт и современное положение.— СПб., 1891.— С. 246.

I бүлек

КӨНЬЯК СЕБЕРНЕҢ АРХЕОЛОГИК МӘДӘНИЯТЛӘРЕ

Көньяк Себердә Хакасиядәге Сая торулыгы борынгы кеше яшәгән урыннардан санала. Археологлар әлеге торулыкка инде 34 мең ел булуын расладлы. Анда төньяк боланы, сайгак, тау тәкәсе, бизон, мөгезборын, мамонт, тау кәҗәсе, шулай ук мехлы җәнлекләрнең сөякләре табылды. Бу якларда яшәүчеләр күмәк аучылыктан тыш балыкчылык белән шөгыльләнгән.

Енисей, Катунь, Чулым, Абакан, Томь, Омь елгалары буенда таш гасыры кешеләренең соңрак, ягъни моннан 10—15 мең ел элек яшәгән урыннары да табыла. Алар мамонтлар, мөгезборыннар, төньяк боланнары, атлар, сайгаклар, бизоннар аулаган. Аучылар гөмбәз сыман түбәле җир өйләрдә утрак тормыш белән яшәгән. Антропологлар алар монголоид типтагы кешеләр булган дип раслый[1].

Кешеләр шулай ук чум тибындагы торакларда да яшәгән. Ауланган хайван сөякләре арасында ат һәм сарык сөякләре дә табылган, бу аларның йорт терлекчелеге белән шөгыльләнүен күрсәтә. Шулай итеп, Көньяк Себердә терлекчелек неолит чорында ук, б.э.к. 4 меңьеллык ахырында барлыкка килә. Шул ук вакытта җитештерүчән икътисад чоры башлана.

Революциягә кадәр Себердә археологик тикшеренүләр тик өлкәне өйрәнүче һәвәскәрләр тарафыннан гына башкарыла. Хәзергә кадәр Алтай-Саянның неолит һәйкәлләре әле аз өйрәнелгән булып кала. Ангара елгасы буйлап тайга өлкәсе, Байкал буйлары, Лена ярлары яхшырак тикшерелгән. Бу урыннарда археолог А. П. Окладниковның экспедицияләре тарафыннан күп материал җыелган. Неолит чоры ядкярләреннән, беренче чиратта, таштан ясалган сыннарны билгеләп үтәргә кирәк[2]. Урта Енисей һәм Минуса казанлыгының кешеләр яшәгән катламы бик саран материал бирә. С. В. Киселев борынгы терлек асрау ысулы үсемлек катламының терлекләр белән тапталуына китергән, шунлыктан мәдәният катламын саклаучы комнарны җил тузгыткан дип саный. Байкал

тирәсендә, Ангара буенда, Минуса краенда, Бараба даласында табылган материаллар бу тирәләрдә бертөрлерәк кешеләр яшәгән дигән нәтиҗә чыгарырга мөмкинлек бирә. Табылган материал эш коралларының (саплы пычаклар, сөңге очлары) камилләшә баруын күрсәтә. Ярым түгәрәк йөзле таш балталар килеп чыга, сөяк коралларның кимүе күзгә ташлана.

Неолит чорының азык калдыклары кешеләрнең инде мамонт түгел, ә ат, болан, үгез, кыр кәҗәсе, куян һәм кыр тавыклары аулавын раслый. Җәнлекләрнең аулап бетерелүе сәбәпле, ау мәйданнары анда яшәүчеләрнең ихтыяҗларын тәэмин итә алмый. Шул сәбәпле тукталу урыннары калдырыла, халыкның хәрәкәтчәнлеге арта, бераз вакыттан бу урынга башка кешеләр килә. Бу урыннарда терлекчелек эзләре даими рәвештә ук-җәя куллану, металл эшкәртү, балчыктан савыт-саба ясауның артуы күренә башлый. Неолит чоры табышларының аз булуына карамастан, алар Алтайда әлеге эпоханың шактый катлаулы булуын күрсәтә. Аңа, бер яктан, Төньяк Себер мәдәнияте сыйфатлары хас булса, икенче яктан, Көньяк-Көнбатыш (Шәркый Төркестан), Урта Азия бәйләнешләрен күрсәтүче үзенчәлекләр йогынты ясаган. Бу бәйләнешләр Алтайда соңрак та күзәтелә. А. П. Окладников бирәдә ук-җәя, балык тоту җәтмәсен, ташны үткенләү һәм шомарту осталыгын белүче вак матриархаль коммуналар яшәве бәхәссез дип исәпли. Киң Алтайның төрле урыннарында җирле үзенчәлекләр дә булган, болар Минуса казанлыгында һәм тау итәге далаларында күзәтелә[3].

Археологлар соңгы неолит чорында Тазма мәдәнияте яшәвен белде. Бу мәдәният үзенең таш сыннары белән характерлы. Гыйбадәт кыла торган «изге» урыннар аллаларның һәм ияләрнең потлары (скульптуралары), Тазма мәдәнияте кешеләренең космогоник карашлары белән бәйле. Бу мәдәният кешеләренең дини күзаллаулары, мөгаен, борынгы төркиләрнең Тәңре дине башлангычы булгандыр. Тазма мәдәнияте — үзенең эчтәлеге буенча җирле аборигеннарның



Тагар чоры ир кешесе (1), сөн кешесе (2), сак кабиләсе кешесе (3), яссы ташлы кабердәге кеше (4).
М. М. Герасимов реконструкциясе

һәм килгән кабиләләрнең катнаш мәдәнияте ул. Тау кыяларына үгез җигелгән бик борынгы дүрт тәгәрмәчле арба сурәте ясалган[4].

Б.э.к. 2 меңьеллыкта Көньяк Себердә яшәүче кабиләләр неолиттан бронза гасырына күчә. Алар бер-берсе белән үзара мөнәсәбәттә торучы, бер дәвердә яшәүче төрле мәдәниятләрнең берничә учагын төзи. Археологлар тикшеренүе күрсәткәнчә, археологик мәдәниятләр берсе артыннан икенчесе эволюцион алмашынып килми, ә янәшә яши[5].

Минуса казанлыгында һәм Алтайда, яңа таш гасыры мәдәниятләреннән соң беренче булып җирле Афанасьев чоры ядкярләре тора. Ул б.э.к. 3 меңьеллык уртасыннан 2 меңьеллык башына кадәр дәвам итә. Бу мәдәният ядкярләре булып, беренче чиратта, каберлекләр тора. Аларның саны 80 нән артык. Табылдыкларның беразы дюналардагы торакларны җил тузгыткан урыннарда урнашкан. Беренче каберлекләр Афанасий тавындагы Батеней авылында табыла, шуннан бу мәдәнияткә «Афанасьев мәдәнияте» дигән исем бирелә.

Бу мәдәният барлыкка килүнең башында ук Идел буена кадәр, бәлки Кара диңгезгә кадәр территориядә яшәгән кабиләләр белән элемтәләр бик ачык күренә. Афанасьев мәдәниятен тикшергәндә, Көньяк-Көнбатыш белән — Урта Азиянең бу мәдәнияттән алдарак яшәгән Анау һәм Суз чорындагы яңа таш гасыры ядкярләре белән бәйләнеш тә сизелә. Афанасьев мәдәнияте чорында Минуса казанлыгында һәм Алтайда йорт терлекләре: ат, сыер, сарык асрый башлыйлар. Мөгаен, йорт терлекчелеге әлегә төп яшәү чыганагына әверелмәгән, терлекләр саны да күп булмаган, шуңа күрә әле күчеп йөрү зарурлыгы да тумаган. Бик гади игенчелек кенә булган, аның белән нигездә хатын-кызлар шөгыльләнгән. Йорт терлекчелеге яшәгәч, билгеле, тире эшкәртү, йон эрләү кебек эшләр дә булган. Агачтан буралар күтәрү, савыт-саба ясау һәм бакыр рудасы чыгару һәм эшкәртү, бакырдан хезмәт кораллары җитештерү таралган. Археологлар Урта Енисейда һәм Алтайда Афанасьев чорын иҗтимагый мөнәсәбәтләр өлкәсендә матриархаттан патриархатка күчү чоры дип характерлый. Кабилә кешеләре арасында бернинди дә милек тигезсезлеге күзәтелми. Сугыш коралларының хезмәт коралларыннан аерылуы Афанасьев ыруглары тормышында сугышларның еш булуын күрсәтә[6].

Афанасьев мәдәнияте кабиләләре Көньяк Себердә 2 меңьеллыкта — бронза мәдәнияте үсү һәм тимер дәвере башында да яшәүләрен дәвам итә. Әмма 2 меңьеллык уртасында Урта Енисейга Көнбатыштан европеоид кабиләләрнең яңа төркемнәре килә.

Археологлар бу килүчеләрне Андрон физик тибы, аерым Андрон мәдәниятен тудыручылар дип атыйлар (б.э.к. XVI—XIV гасырлар). Ул Минуса казанлыгында табыла, Алтайда һәм Тывада билгеле түгел. Бу бронза чорының чәчәк атуы һәм тимер дәверенең үсеш вакыты була. Бу чорда сугыш кораллары эшләү хезмәт кораллары җитештерүдән аерыла. Андрон мәдәниятенең уникаль күренеше булып бронза дәверенең Бөек нефрит юлы төзелү санала. Бу — борынгы чорның иң озын юлларыннан берсе. Ул, Байкал буеннан башланып, Обь, Томь, Омь, Иртеш елгаларын, Урал тауларын үтеп, Камага кадәр һәм Иделдә Ока тамагына кадәр җитә, Себерне Көнчыгыш Европа белән тоташтыра. Бу юл Себер нефритыннан бизәнү әйберләре шомартып ясау белән билгеле[7].

Андрон мәдәнияте вәкилләре традицион аучылык, балык тоту, терлекчелек һәм китмәнле игенчелек белән шөгыльләнә. Игенчелек бу чорда зур әһәмияткә ия була башлый. С. В. Киселев шул дәвердә Тубыл тугайларында игенчелек булуны фаразлый[8].

Бронза дәверенең ахырында Көньяк Себердә Андрон мәдәниятенә синхрон рәвештә дип әйтерлек Карасук мәдәнияте яши (б.э.к. XIII—VIII гасырлар). Аның ядкярләре көнбатыштан да, көнчыгыштан да килгән катнаш халык тарафыннан калдырылган. Аларның антропологик тибы монголоид раса кушылган европеоид кыяфәтле дип билгеләнгән. Кешеләр даими тору урыннарында, каркас тибындагы йортларда яшәгән. Хуҗалыклары комплекслы була, мөгезле эре терлек, ат һәм сарык асрыйлар. Карасук чорында бронза металлургиясе югары үсешкә ирешә. Кырын салынган таш плитәләр белән әйләндерелгән зур зиратлар Карасук мәдәниятенең характерлы күренеше булып тора.

Антрополог Г. Ф. Дебец Андрон һәм Карасук чоры баш сөякләренә игътибар итә. Карасук кешеләренең йөзе озынрак һәм таррак, шунда ук киң йөзле, кыска башлылар да очрый. Бу күренешне ул Төньяк кытайлары тибындагы монголоид элементларның катнашуы һәм элгәреге Афанасьев мәдәнияте чоры типларының саклануы белән аңлата. Бу халыкның кушылуына китерә. Б.э.к. XVIII—XVII гасырларда динлиннарны Кытайдан кысрыклап чыгаралар. Байкалдан алып Обька кадәр булган территориягә динлиннарның көнчыгыш группасы күчеп килә[9].

Көньяк Себергә Карасук мәдәниятенең дәвамчысы булып утрак игенчелекле Тагар мәдәнияте килә, ул нигездә Минуса казанлыгында тарала. Б.э.к. меңьеллыкның башыннан VII гасырга кадәр ул Карасук мәдәнияте белән янәшә яши. Соңыннан Тагар мәдәнияте, Карасук мәдәниятен кысрыклап чыгарып, б.э.к. II гасырга кадәр дәвам итә. Археологлар кыяларның берсендә Тагар чорындагы

рәсемдә бурап ясалган өч йорт сурәте табалар, дүртенчесе балчык өйгә охшаш, алар барысы да салам белән ябылган. Янәшәдә тирмә рәсеме ясалган. Тагар чоры торулыгында тирмә булу күчмә тормыш булуны күрсәтә. Аңа кадәр Көньяк Себердә күчмә тормыш билгеле булмаган.

Тагар каберләрендә гаилә билгеләре күзәтелә. Курган төркемнәре Тагар кабиләләренең аерым ыругларыныкы булган. Тагар эпохасының беренче чорында мәет башы белән көнбатышка каратып куелган, башына трепанация ясалган (баш сөяге киселеп, мие алынган), мускуллары сөягеннән аерылган. Һәр кабернең аерым үзенчәлекләре бар, бу ыругларның саклануын күрсәтә. Бу чорда әле борынгы община җәмгыяте сакланган.

Тагар эпохасы каберлекләрендә скульптур сурәтләр — хәнҗәр, пычак саплары, көзге кысалары һ.б. бизәкләре бик күп. Археологлар, Тагар сурәтләрен тикшергәндә, Карасук традицияләренең саклануына игътибар итә[10]. Тагар сурәтләре җәнлек төшерү стилендә ясалган. Алар скиф сурәтләренә охшаган, ләкин үз үзенчәлекләре дә бар — Тагар мәдәнияте чоры җәнлек сурәте чынбарлыкка якын тора. Һичшиксез, Тагар кабиләләре белән скифлар арасында үзара тәэсир итешү булган. Шуңа күрә кайсының стиле борынгырак булуын ачыклау әлегә мөмкин түгел.

Тагар чорында игенчелек ныклы урын тоткан. Каберләрдә күп ураклар табыла. Минуса казанлыгының күп регионнарында Тагар сугару системасы калдыклары сакланган. Кайбер сугару системаларында су 15—20 км ераклыктагы иген кырларына аккан. Мондый системалар төзүне, әлбәттә, күп кеше көче белән генә башкарып булган[11].

Тагар мәдәнияте ядкярләре Алтайда да киң таралган. Алар Тывада да очрый. Тагар чорының ахырына таба Енисейда һәм Алтайда яңадан Афанасьев-Андрон заманына якын антропологик тип очрый. Ләкин Алтайда V—IV гасырларда монголоид төркемнәр үтеп керү күзәтелә[12].

Әмма Алтайның Минуса казанлыгында Тагар мәдәнияте хакимлек иткән чордагы ядкярләре, Тагар мәдәниятенә якын формалар белән бергә, архаик чор Скиф мәдәниятенә охшаш үзенчәлекләргә ия. Алтайдагы б.э.к. VII—VI гасыр курганнарының әһәмиятле үзенчәлеге — ат белән күмү. Бу йола мең еллар буена саклана. Минуса казанлыгының һәм Алтайның элгәре Тагар эпохасы ядкярләренә хас уртаклык тимердән эшләнгән әйберләрнең булмавыннан гыйбарәт, соңыннан исә алар киң күләмдә тарала.

Археологлар Алтайның Тагар чорындагы ядкярләрен «Майэмир ядкярләре» дип атый, чөнки бу мәдәниятнең башлангыч билгеләре

А. В. Адрианов тарафыннан Нарым елгасы буендагы Майэмир даласында һәм Бухтарма елгасының югары агымында табыла[13]. Бу урыннарда таштан өелгән курганнар белән беррәттән, тау кыясының зур кисәкләреннән салынып, туфрак белән капланган курганнар да табыла. Палеоантропологлар Енисейдагы Тагар һәм Алтайдагы Майэмир чорында элекке Афанасьев-Андрон заманы ядкярләренә якын типлар табылуны күрсәтә. Аннан Алтайга б.э.к. V—IV гасырларда аермачык монголоид типтагы этник төркемнәр килә[14].

Енисейдагы Тагар һәм Алтайдагы Майэмир эпохасы Афанасьев чорында башланган гомуми мәдәни-тарихи үсешнең көчәю чоры була. Андрон эпохасы Евразия далалары көнчыгышы һәм көнбатышының тагын да якынаюы белән аерылып тора[15].

Кешелек тарихы — катлаулы күренеш. Аерым кабиләләр һәм халыклар тарихында аларның җисми һәм рухи мәдәнияте традицион рәвештә, дистә, йөз еллар буе бертөрле тизлектә үсә. Ләкин аерым чорларда кабилә яки халыкның тарихында моңарчы билгеле булмаган яңа тенденцияләр барлыкка килә. Мондый күренешләрне археологлар б.э.к. IV гасырда сөн атлы гаскәре кораллануында таба, бу чорда сөннәрдә хәрби реформа була. Җиңел коралланган сөн атлы гаскәре авыр кораллыга әверелә. Кытайда да, сөннәрнең башка күршеләрендә дә мондый кораллар булмый. Бу үзгәрешләрнең сәбәбе нәрсәдә соң? Җавап гади, ләкин нигезле. Үзгәрешләрнең төп этәргече булып кабилә һәм халыклар элемтәсенең һәм бер-берeңә йогынты ясауның катлаулы системасы тора. Кайвакытта бу элемтәләр көтмәгәндә, хәтта ерак территорияләр белән аерылган кабиләләр арасында да була.

Археолог С. П. Толстов Харәземнең югары цивилизациясен — борынгы Көнчыгыш колбиләүчелек мәдәниятенең үзенчәлекле формасын ача. Александр Македонскийның яулап алу сугышлары вакытында да Харәзем үз мөстәкыйльлеген саклап кала. Арал—Каспий кабиләләре — грек чыганаклары буенча массагетлар, Кытай чыганаклары буенча юэчжилар бу чорда күтәрелеш кичерә. Археологик чыганакларга караганда, аларның матди һәм рухи мәдәнияте скифларныкына охшаш була. Җәмгыять төзелешендә дә охшашлыклар күп. Аларның өстен катлавы скифларныкы кебек бик зур байлыкларга ия була. Б.э.к. 530 елда массагетлар, фарсыларны тар-мар итеп, аларның патшасы Кирны үтерә. Массагетлар юнан-македон яулап алучыларына каршы күтәрелгән Урта Азия кабиләләре арасында беренче сафларда була. Александр Македонский гаскәрләренә каршы көрәш массагетларга көч өсти һәм зур үзгәрешләргә китерә. Алар армияләренә реформа ясыйлар һәм

көнчыгышта хакимлек итүче көчкә әвереләләр. Массагетлар сарматлардан атлы гаскәрне авыр кораллландыру үрнәген ала. Сарматлар үз атлы гаскәренең көчен Евразия далаларының көнбатышында күрсәтә[16].

Борынгы заманда авыр коралланган атлы гаскәр тик Ассирия армиясенең бер өлешендә генә була. Үзләренең атлы гаскәрләре аркасында массагет-юэчжилар б.э.к. III гасырда Үзәк Азиянең күчмә кабиләләре өстеннән хакимлек итә. Аларның күченеп йөрү урыннары хәтта Кытайның Ганьсу провинциясендә дә була. Массагетлардан еракта — көнчыгышта яшәүче сөннәр дә аларга ясак түләп тора. Тик Модэ шаньюй (патша) вакытында гына сөннәр массагетларга көчле һөҗүм ясыйлар. Б.э.к. 165 елда Сөннүнең Лаошань шаньюйы, массагетларны тар-мар итеп, Урта Азиягә чигенергә мәҗбүр итә. Шул заманнарда массагетларның хәрби техникасы сөннәргә күчкән булуы бик ихтимал. Сөннәргә мондый техника бик кирәк була.

Борынгы кабиләләр, бер-берсеннән ерак араларда көн күрсәләр дә, изоляциядә яшәмәгән. Борынгы кабиләләрнең тарихи-мәдәни үсеше зур бердәмлек белән аерылып торган. Көнбатыш скифлары, Идел һәм Көньяк Урал буе савроматлары, Урта Азиянең массгетсак дөньясы, Саян-Алтайның динлиннары, Тагар һәм Майэмир кабиләләре, Монголия Байкал буе һәм Ордос халкы бертөрле сугыш коралы һәм ат дирбияләре белән файдалана, сәнгатьтә бер үк сурәтләргә һәм фикерләүгә омтыла. Шул ук вакытта җирле үзенчәлекләр дә саклана, ләкин бу үзенчәлекләр шул заман мәдәниятенең бөтенлеген бозмаган. Бөек дала Евразиянең көнбатышын һәм көнчыгышын җисми мәдәният бердәмлеге, рухи мәдәният элементлары белән тоташтырган[17].

Чжоу дәверендә Кытай көчсез һәм күпләгән вак дәүләтләргә бүлгәләнгән булган, анда колбиләүчелек чәчәк аткан, ә Цинь династиясе урнашкач, Кытай берләшә, Сөннү өчен куркыныч көчкә әверелә.

Югарыда әйтелгәнчә, Алтайның Майэмир мәдәнияте Минуса казанлыгының Тагар мәдәнияте белән бер чорга туры килә. Археологик яктан ул шулай ук Тагар мәдәниятенә якын. Традицион табылдыклар белән бергә Алтайның Майэмир каберләрендә классик скиф һәм элгәреге эллин эпохасыныкына охшаш әйберләр табыла. Тагар һәм Майэмир мәдәнияте каберлекләрендә Скиф мәдәниятенең ачык чагылышы Минуса казанлыгы һәм Алтайның борынгы халкының скифлар белән бәйләнешен төгәл күрсәтә. Археологик тикшеренүләр Саян-Алтайның борынгы кабиләләренең тагы даерактарак яшәгән кабиләләр белән хуҗалык һәм мәдәни багланыш-

ларының шаһиты булып тора, ләкин алар скифлар белән булган кебек көчле түгел. Бу бәйләнешләр күп галимнәрнең Көньяк Себернең борынгы халкы белән скифларның якын туганлыгы яки скиф берлегенең полиэтник булуы, анда борынгы төркләрнең дә катнашуы турындагы фикерен раслый түгелме соң? С. В. Киселев: «Скифия белән Көньяк Себерне, аерым алганда, Алтайны мәдәниятләренең якынлыгы берләштерә, бу мәдәниятләрнең аерым элементлары Көньяк Себернең, Көньяк Уралның һәм Идел—Дон далаларының мәдәни яктан тугандаш кабиләләре аша үтеп кергән булуы мөмкин»,— дип исәпли[18]. Һич шик юк, әгәр галимнәр яман аты чыккан фарсы-европа теориясеннән чыгып эш итмәсә, киләчәк тикшеренүләр бу проблемага ачыклык кертер.

Таулы Алтайның соңгы Майэмир мәдәнияте каберләре Тагарныкыннан мәет янында бер яки ике ат табылу белән аерылып тора. Алтай тирәсендәге дала каберләрендә балчык савытлар күп табыла, бу утрак тормышны күрсәтә. Атсыз күмелгән курганнар да очрый[19].

Майэмир чорыннан соң Алтайда күп үзгәрешләр була. Аларның күбесе Үзәк Азиядә сөннәрнең өстенлек итүе белән бәйле. Алар Алтай халкы тормышының күп якларына кагыла, моны сакланып калган ядкярләрнең шактый үзенчәлекле булуы күрсәтә. Бу хәл археологларга Алтайда яңа археологик мәдәният табарга мөмкинлек бирә. Алтай Республикасының Зур Улаган елгасы буендагы Пазырык дигән урында табылу сәбәпле, аны «Пазырык мәдәнияте» дип атыйлар. Бу курганнарны 1929 елда М. П. Грязнов һәм С. И. Руденко таба, бу археология фәнендә үзенә күрә бер сенсация була. Монда курганнарның зур төркеме урнашкан. Курганнар ыруг яки кабилә башлыкларының каберләре булып тора. Аларның күбесе б.э.к. V—IV гасырларда корылган. Пазырык курганнары тирәнлеге дүрт метрга кадәр җиткән, мәйданы 50 кв. метрга якын туры почмаклы чокырлардан гыйбарәт, алар эчендә биеклеге ике метрга кадәр булган күмү камералары табыла. Алар карагай агачыннан ике катлап буралап эшләнгән. Түшәме карагайдан ясалган, аның өстенә каен тузы һәм агач ботаклары җәелгән. Алар өстенә балчыктан өем ясалган һәм иң өскә калын таш катламы түшәлгән. Бураның ике кат стенасы арасына өч яктан таш тутырылган.

Пазырык дигән урынның шактый биектә булуы, климат үзенчәлекләре һәм курганнарның конструкциясе нәтиҗәсендә, төзегәннән соң ук алар астында мәңгелек туң барлыкка килгән. Бу исә туң кабергә салынган бар нәрсәнең, шул исәптән карагайдан ясалган тагарак сыман саркофаглардагы бәлзәмләнгән мәетләрнең, кабер

чокырыннан төньяктарак, күмү камерасының тышына куелган ат гәүдәләренең искитәрлек яхшы саклануына китергән. Бик борынгы тукымалардан, киездән һәм күннән эшләнгән әйберләр дә яхшы сакланган. Бу табылдыклар күмелгән кешеләрнең физик кыяфәте, мәдәнияте турында ачык мәгълүмат бирә. Курганнарда үзенчәлекле җәнлек стилендә эшләнгән сәнгать әсәрләре, ат дирбияләре табыла. Анда табылган йон келәм, үтә нәфис Кече Азия тукымалары һәм чигелгән ефәк тукыма Алтайның борынгы халкының киң хуҗалык һәм мәдәни элемтәләре булуын раслый[20].

Пазырык курганы астындагы мәңгелек туң катламы 10 ат гәүдәсен бөтен килеш саклый. Профессор В. О. Витт, атларны җентекләп тикшереп, аларның хәзерге монгол атларына түгел, ә ахал-текин төрекмән атларына охшавын әйтте. Бу атлар Кытайда да билгеле булган[21].

Атларның колакларындагы тамга аларның күмелгән кешенең башта ук үз милке булмавын, ә төрле вакытта сатып алынганлыкларын күрсәтә. Атларның ашказанын тикшерү аларга солы ашатылуын күрсәтә. Димәк, Алтайның хәтта ераграк урнашкан таулы төбәкләрендә дә игенчелек белән шөгыльләнгәннәр.

Җиңел арба. Агач. Б.э.к. V—IV гасырлар. Алтай. 5 нче Пазырык курганы. С. И. Руденко казылмасы, 1949 ел. (36, 37, 39 нчы битләрдәге рәсемнәрнең зурайтылган төсле вариантлары 2 нче форзацта бирелде).

Пазырык мәдәнияте ядкярләренең төрлелеге күмү йоласының төрле булуын, социаль тигезсезлекне күрсәтә. Иң гади каберләр зур булмаган таш өеме белән билгеләнгән яки кабер тирәли боҗра сыман итеп таш тезелгән. Аннан соң, урта зурлыктагы таш курганнар һәм кыя кисәкләреннән корылып, балчык белән капланган бик зур курганнар китә. Аларның диаметры 100 метрга, биеклеге 45 метрга җитә. Алар эчке төзелешләре һәм куелган әйберләре белән дә бер-берсеннән нык аерыла. Алтайның Пазырык чорының хәтта гади каберләрендә һәм Төньяк Монголиянең соң каберләрендә беркадәр охшашлык бар, шул ук вакытта Майэмир чорыннан да элеккерәк каберләргә охшаганнары да очрый.

Шулай итеп, Пазырык чорында Алтайда ядкярләрнең ике төрлесе

аерыла: дала төркеме һәм таулы Алтай төркеме. Дала төркеме курганнары утрак халыкныкы, ләкин тауларда да әле күчмә тормыш бик җәелмәгән. Күмү камераларын буралап эшләү аларның агач йорт конструкциясе белән таныш булуын күрсәтә, агач өй белән бер вакытта тирмә дә киң тарала.

Ядкярләрнең ике төркеме дә — даланыкы да, тауныкы да — Алтайда Пазырык чорында кабиләләрнең иҗтимагый төзелешендә шактый үзгәрешләр булуны күрсәтә. Кабилә эчендә көчле дифференциация ачык чагыла. Алтай кабиләләренең хуҗалык нигезен терлекчелек, китмәнле игенчелек тәшкил иткән. Тимер ныклап таралган, ул инде Майэмир чорының азагында ук була.

Алтайның Пазырык чоры каберләре алтынның күп булуы белән аерылып тора. Ул иң ярлы каберләрдә дә күренә, ә зур курганнарда шактый күп була. Борынгы заманнардан башлап, каберләрдәге алтын таланган, ә талауларның иң зурысы XVII—XVIII гасырларда руслар тарафыннан башкарылган.

Алтайда бу чорда алтынның күп булуы, анда алтынның күп табылуы һәм македониялеләрнең Урта Азияне басып алуы сәбәпле, аны Урта һәм Кече Азиягә чыгаруның кимүе белән аңлатыла[22].

Милек тигезсезлегенең үсүендә һәм җирле аксөякләрнең көчәюендә сөннәрнең йогынтысы зур роль уйный. Аның көче Алтай мәдәниятенең иң тирән катламнарына үтеп керүдә күренә. Алтай кабиләләре сөннәр белән бик тыгыз аралаша, ә кайбер чорларда аларга буйсына һәм ясак түли.

Сөннәргә кадәр милек тигезсезлеге башкача була. Каберләрнең күптөрлелеге аристократиянең әле үсеп кенә килүе, гади кешеләр арасында байларның күплеге, ә алтынның һәрберсендә тигез булуы турында сөйли.

Сөн чорында баеп киткән Пазырык кешеләре сөннәргә охшарга тырышкан. Моңа тәңгәл күренешне Бараба

5 нче Пазырык курганында табылган киез келәмнең бер кисәге. Алтай, б.э.к V—IV гасырлар.

даласында һәм Төмән шәһәре торган җирдә дә күрергә була. Күмү ритуалы буенча алар Алтайдагыдан аерыла, анда ат юк, әмма күренеп торган дифференциация була. Кечкенә каберләр фонында диаметры 35 метр, биеклеге 3 метрга җиткән бай курганнар да бар.

Ике шундый курган Барабада Усть-Тартас янында урнашкан. Гади курганнар Төмән янындагы Мыс авылында, Ялутор янында (Томилово авылы), Курган (Вагиново авылы), шулай ук Чиләбе, Кустанай һәм Троицк тирәсендә очрый. Алар Идел буеның һәм Көньяк Уралның сармат ядкярләренә охшаган[23].

Бу хәл Көнбатыш Себернең бу өлешендә дифференциация көчәюне күзалларга мөмкинлек бирә. Көньяк Уралда — Оренбург тирәсендәге сармат ядкярләре моңа мисал булып тора. Төмән янындагы бай курганнарны Алтай һәм Барабадагы Усть-Тартастагы зур курганнар белән чагыштырып була. С.В.Киселев фикере буенча, алар бай һәм куәтле кабилә аксөякләре барлыкка килү процессын гәүдәләндерә. Сөн-сармат чорында (б.э.к. III—I гасырларда), Монголиядән Минуса казанлыгы, Көнбатыш Себер һәм Урта Азияне дә кертеп, Көньяк Уралга кадәр иҗтимагый үзгәрешләрнең, җисми мәдәниятнең һәм сәнгать әсәрләренең охшаш булуы күзәтелә. Бер-берсеннән ерак аралар белән аерылган кабиләләрнең тирән элемтәләре саклана. Зур Улаган авылыннан 2 км ераклыкта урнашкан зур Пазырык курганы моңа мисал булып тора. Таулы Алтайның Монголия һәм Тыва белән чиктәш, изоляцияләнгән бу районның курган табылдыклары җирле халыкның сөннәр, скиф-сармат дөньясы белән генә түгел, ә борынгы көнчыгыш цивилизациясенең тагы да ерак районнары белән бәйләнешенең ачык картиналарын күрсәтә. Пазырык табылдыкларында Урта Азия үрнәкләре, беренче нәүбәттә, Амударья хәзинәләре белән охшашлык зур. Урта Азия аркылы Алтайга борынгы Көнчыгыш (Елгаара өлкә, Иран, Шумер-Вавилон) мәдәниятенең казанышлары үтеп керә. Болар могҗизаи гыйфрит һәм ерткычлар, аларның үлән ашап туенучы хайваннар белән көрәше картиналары. Бу мәдәният кайбер җирле үзенчәлекләре белән Монголия, Минуса казанлыгы, Көнбатыш Себер, Урта Азия, Көньяк Урал һәм Идел буе кабиләләре мәдәниятенә аваздаш була. Бу тулысынча аңлашыла, чөнки шул районнарның җисми һәм рухи мәдәнияте белән борынгы Скиф-Себер мәдәниятенә гаҗәеп охшашлык хас. Пазырык чоры мәдәнияте ядкярләрен өйрәнү бу чорда Алтай кабиләләре тарихында яңа иҗтимагый көч — кабилә аксөякләренең көчәюендә сикереш булуны күрсәтә. Әлеге катлау баеый һәм аерымлана, йогынтылы иҗтимагый көчкә әверелә. Бу дәүләт төзү юлында әһәмиятле адым була. Сөн



Агач күләгәсендә ял итүче җайдак. Бил каешы бизәге. Алтын (зурлыгы 15 x 21 см). Б.э.к. V—IV гасырлар

җәмгыяте үзенең үсеше буенча Минуса казанлыгы һәм Алтай кабиләләреннән алда тора. Шуңа күрә Алтайда дәүләт Пазырык чорыннан берничә гасыр соңрак төзелә. Кытай чыганаклары б.э.к. IV гасырда Сөн дәүләте яшәвен ышанычлы итеп яза. Кытай чыганакларында шулай ук б.э.к. IV—III гасырларда «Динлиннар дәүләте» («Динлин Го») төзелү дә теркәлгән. Ләкин тиздән бу дәүләт сөннәргә бәйле булып кала.

Көньяк Себернең археологик мәдәниятләренә кыскача күзәтү б.э.к. I меңьеллык уртасында Үзәк Азия кабиләләре хуҗалыгы һәм мәдәниятенең шактый алга китешен күрсәтә. Тарихи ядкярләр барлык кабиләләрнең дә диярлек күчмә терлекчелеккә күчүен дәлилли. Минуса казанлыгы һәм Алтайның кышлау урыннарында китмәнле игенчелек үсә. Бронзадан хезмәт һәм сугыш кораллары, һәм башка әйберләр ясау камилләшә, әкренләп, бронза урынын тимер ала башлый.

Бөек дала кабиләләренең тарихи үсешендә аларның хуҗалык һәм мәдәни элемтәләре зур роль уйный. Бу бик зур региондагы барлык кабиләләрнең мәдәниятендә скиф һәм сармат эзләре ачык күренә. Ләкин Бөек даланың көнчыгыш өлешендә төрле өлкәләрнең үсеше тигез булмый, аларның үзенчәлекләре саклана, бу иҗтимагый үсешнең тигезсезлегенә китерә. Кайбер кабиләләрдә иртәрәк, кайберләрендә соңрак ата кеше баш булган гаилә барлыкка килә, ыруг башлыклары байый һәм көчәя. Динлиннар һәм сөннәр үз дәүләтләрен төзи. Безнең эраның 1 меңьеллыгы уртасында Алтайда куәтле төрки дәүләт — Бөек Төрки каһанлыгы төзелә. Шулай итеп, VI гасыр уртасыннан төрки империяләр чоры башлана. Ул XII гасыр башына кадәр дәвам итә. Бу дәүләтләр арасында Кыргыз каһанлыгы

гына аерылып тора, ул, монгол яулары тарафыннан җимерелгәнче, XIII гасырның 20 нче елларына кадәр яши. Көньяк Себернең археологик мәдәниятләрен күзәтү төркиләр этногенезының Көньяк Себердә һәм Үзәк Азиядә башлануын күрсәтә. Безнең кулда булган ышанычлы тарихи чыганаклар шундый нәтиҗәгә китерә. Хинган тауларыннан алып Алтайга кадәр сузылган бу территория борынгы төркиләр ватаны була, һәм бу гаять зур регион күрше-тирә цивилизацияләр белән бәйләнештә яши. Чөнки төркиләрнең миграция хәрәкәтләре Бөек дала буенча сузылган.

---

[1] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Красноярск, 1992.— С. 5—7.

[2] *Окладников А. П.* Каменные рыбы // Советская археология.— 1936.— № 1.— С. 215—245.

[3] *Киселев С. В.* Древняя история Южной Сибири.— М., 1951.— С. 20—22.

[4] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Красноярск, 1992.— С. 9.

[5] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 71—72.

[6] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 60 б.

[7] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Красноярск, 1992.— С. 12.

[8] *Граков Б. Н.* Работы в районе проектируемых южноуральских гидростанций. Археологические работы на новостройках. Вып. II.— Л.,1935.— С. 93.

[9] *Грязнов М. П.* Минусинские каменные бабы // Советская археология. XII.— 1950.— С. 157.; *Дебец Г. Ф.* Антропологические типы Минусинского края на стадии родового строя (к вопросу о миграции в доклассовом обществе) // Антропологический журнал.— 1932.— № 2.— С. 26—48.

[10] *Адрианов А. В.* Выборки из дневников курганных раскопок.— Минусинск, 1902—1924.— С. 65.

[11] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 258 б.

[12] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 299—301 б.

[13] *Грязнов М. П.* Древние культуры Алтая. Материалы по изучению Сибири. Вып.2.— Новосибирск, 1930.— С. 6—7.

[14] *Дебец Г. Ф.* Палеоантропология СССР.— М.; Л., 1948.— С. 137.

[15] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 303 б.

[16] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М.; Л., 1926.— С. 9; *Толстов С. В.* Основные вопросы древней истории Средней Азии // Вестник древней истории.—1938.— № 1.— С. 185.

[17] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 303 б.

[18] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 384 б.

[19] *Евтюхова Л. А., Киселев С. В.* Отчет о работах Саяно-Алтайской археологической экспедиции в 1935 г. // Труды Гос. исторического музея. Вып. XVI.— М., 1941.— С. 88—89.

[20] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах населявших Среднюю Азию в древние времена. Т. III.— М.; Л., 1953.— С. 22.

[21] *Руденко С. И.* Культура населения горного Алтая в скифское время.— М.; Л, 1953.

[22] *Грязнов М. П.* Раскопки на Алтае // Сообщения Гос. Эрмитажа. Вып. I.— Л., 1941.— С. 17.

[23] *Дмитриев П. А.* Мысовская стоянка с курганами // Труды Института археологии искусствоведения. Российская ассоциация научно-иссл. интов. Вып. IV.— М., 1976.— С. 187—190.

II бүлек

СӨННӘР

Бөек дала

Борынгы төркиләрнең тарихы Бөек дала белән бәйләнгән. Евразиянең Уссуридан алып Дунайга һәм Карпатка кадәр сузылган гаять зур мәйданнары әнә шулай атала. Себер тайгасы һәм Көнчыгыш Европаның катнаш урманнары аның төньяк чиге булып тора, көньяктан ул Хуанхэ елгасы, Үзәк Азия яссытаулыкларындагы чүлләр, Иран оазислары, Каспий диңгезе һәм Кавказ таулары белән чикләнә. Борынгы заманнарда бу даланы греклар «Скифия» дип, фарсылар «Туран», кытайлар «Бэй-ху» (төньяк варварлар даласы) дип атаган. Бөек дала географик яктан икегә бүленә: көнчыгыш өлеше «Эчке» яки «Үзәк Азия» дип атала, ул Монголияне, Джунгарияне (Төньяк-Көнбатыш Кытайдагы өлкә), Шәркый Төркестанны үз эченә ала. Н. Я. Бичурин һәм Г. Е. Грумм-Гржимайло аны «Урта Азия» дип атый. Себердән аны Саян, Хамар-Дабан һәм Яблоневый тау сыртлары аера, Тибеттан — Куньлунь һәм Наньшань тау тезмәләре, Кытайдан — Бөек Кытай стенасы, ә көнбатыш өлешеннән Таулы Алтай, Тарбагатай (Көнчыгыш Казакъстанда Кытай белән чиктәш, Алакүл белән Зайсан күлләре арасындагы тау сырты), Саур (Казакъстан-Кытай чигендәге тау системалары) һәм Көнбатыш Тянь-Шань аера. Бөек даланың көнбатыш өлешенә хәзерге Казакъстан, Җидесу, Урта Азия һәм Дунайның түбән агымына кадәр булган җирләр керә. Борынгы замандагы Бөек дала аз халыклы, коры, кискен континенталь климатлы җир була[1].

Бөек даладан көньяктарак, Хуанхэ елгасының аръягында уңдырышлы туфраклы, җылы һәм дымлы Кытай иле урнашкан. Кытайлар үз илләрен «Урта патшалык» (Чжун-Го) яки «Күк асты патшалыгы» дип атый. Кытай цивилизациясе дөньяның иң борынгы цивилизацияләреннән санала. Ул Хуанхэ елгасының урта һәм түбән агымы территориясендә һәм шуңа янәшә җирләрдә неолит чорында барлыкка килә. Кытай этносының формалашуында «Яншао» һәм «Луньшань» исемле соңгы неолит мәдәниятләре зур роль уйный

(б.э.к. 3—2 меңьеллыклар). Хуанхэ елгасының урта агымында һәм аның төп кушылдыгы Вэйхэ буенда яшәгән Яншао мәдәнияте вәкилләре чама белән б.э.к. 3 меңьеллык уртасында ук инде игенчелекне һәм терлекчелекне белгән.

Үзәк Азиянең борынгы халкы

Бик борынгы заманнарда Япон диңгезе һәм Сары диңгездән алып, Хуанхэ елгасыннан төньякка таба Тибетка һәм, Шәркый Төркестанны да үз эченә алып, Тарим бассейнына кадәр булган зур мәйданнарда күчмә халыклар яши. Алар күчмә һәм ярым күчмә терлекчелек, гади игенчелек һәм аучылык белән шөгыльләнә. Күчмәннәр турында сүз чыккач, сорау туа: күчмә терлекчелек Азия халыкларының беренчел яшәү ысулы булганмы? Галимнәр, археологик һәм башка чыганакларга таянып, «юк» дип җавап бирә. Б.э.к. 2 меңьеллыкта Үзәк Азия кабиләләре утрак тормыш белән яши, аларның кайберләре игенчелек һәм утрак терлекчелекне үзләштерә. Бу кабиләләрнең җисми һәм рухи мәдәнияте б.э.к. 1 меңьеллыкта яшәгән кабиләләрнекеннән күпкә югарырак баскычта була. Ни өчен шулай килеп чыга, моны нәрсә белән аңлатырга? Климатның кинәт кискен үзгәрүе һәм б.э.к. 1 меңьеллыктагы корылык дала кабиләләрен күчмә тормышка күчәргә мәҗбүр итә. Сирәк һәм аз уңышлы үләннәрне терлек тиз ашап бетерә, һәм кешеләр көтү артыннан китәргә мәҗбүр була[2].

Кытайларның борынгы тарихи хроникасы «Цзинь-шу» далада яшәүче ис, иань, дис кабиләләрен «варварлар» дип атый. Аларга Кытай хөкүмәте күп төрле аерым йөкләмәләр салган: кытайларның кырларын эшкәрткәннәр, түрәләрен саклаганнар, сирәк очрый торган әйберләр түләгәннәр. Чыганакта язу буенча, аларның теле аңлашылмый, законнары, гадәтләре башка, ел исәпләре үзгә. Алар комсыз, саран, көчсез чакта, куркудан бүйсыналар, көчәеп китсәләр, баш күтәрәләр[3]. Ә Хуанхэ елгасының көньягында климат дымлы булып кала, һәм кытайлар утрак тормышларын дәвам итә. Яшәү рәвешенең кискен үзгәрүенә — күчмә терлекчелеккә күчүгә карамастан, Үзәк Азия кабиләләре үзләренең хуҗалыгын үстерә. Бу дөнья цивилизациясенең һәм кешелек тарихының әһәмиятле өлеше булып тора. Үзәк Азиянең бу кабиләләре шул чорда скиф тибындагы күчмә мәдәният булдыра. Алар бронза һәм тимер эретергә, алардан эш һәм сугыш кораллары, көнкүреш кирәк-яраклары эшләргә өйрәнә. Бу турыда безгә археологик материаллар һәм Кытайда сакланган язма чыганаклар хәбәр итә. Бу күчмәннәр турындагы мәгълүматлар хайван сөякләренә һәм тарихи трактатларга язылган.

Кытайларның төньяк күршеләре булган бу күчмәннәр турында Сыма Цянь «Тарихи язмалар»ында өзек-өзек булса да мәгълүматлар язып калдырган. Үзәк Азиянең б.э.к. VII—VI гасырларында яшәгән бу күчмәннәрен ул «жуннар» яки «ди» кабиләләре дип атый. Соңрак аларны «ху» дип атыйлар. Шул ук чорда Эчке Монголия, Көньяк Маньчжурия далаларында һәм Зур Хинган тау тармакларында тау жуннары, яки дунхулар яши.

Сыма Цянь күчмәннәрнең иҗтимагый тормышы турында да мәгълүматлар калдыра. Аларның ыруг башлыклары була, ләкин сәяси берләшмәләре булмый. Башлык вазифасы нәселдән килми. Бәхәсләрне оста хәл итәрлек көчле, гайрәтле кешене аксакал итеп куялар. Һәр торулыкның үз түрәсе бар. Йөздән алып меңгә кадәр тирмәсе булган торулык бер ыругка берләшә. Аларда бар кеше дә тигез була, берсе хезмәтеннән икенчесе файдалану күзәтелми. Ыруг башлыклары да үз терлеген үзе көтә. Чыганаклар жун һәм дунхуларның тары чәчүлекләре турында хәбәр итә, ләкин төп шөгыльләре күчмә терлекчелектән гыйбарәт, алар үлән һәм су микъдарына карап, терлекләре белән урыннан урынга күчеп йөриләр. Һәр эштә дә хатын-кыз фикерен тыңлыйлар, ә сугыш эшләрен ирләр генә хәл итә. Сугышны әһәмиятле гамәлгә саныйлар[4]. Ганимәт алу өчен, сугыш алар тормышында әһәмиятле урын тота, байлыкның кадерен беләләр, ләкин җирнең кадере булмый, алар өчен байлык — алтын, яшма (кварцның бер төре), тукыма һәм ефәк[5].

Дала цивилизациясе Кытай, Һиндстан, Мисыр, грек-рим цивилизациясеннән үзгә булса да, кешелек дөньясында аның әһәмияте ким түгел, ул башка цивилизацияләр белән дә, җир биосферасы белән дә органик рәвештә бәйләнгән.

Сөннәр

«Сөнну» исемле күчмә халыкның бабалары Ордос өлкәсендә яши, бу өлкә Кытайда, Хуанхэ елгасының урта агымында урнашкан. Бу халык турында мәгълүмат бирүче бердәнбер чыганак булып Кытай тарихи хроникасы тора. Ләкин Кытай елъязмаларының мәгълүматлары да кыска һәм өзек-өзек. Бу мәгълүматлар кытайларның сөннәргә каршы сугышлары б.э.к. 3 меңьеллыкта башлануын раслый. Димәк, сөннәр кытайларга моннан 5000 ел элек билгеле булган. Кытай хроникасында сөннәр «Күк асты дәүләтенең», ягъни Кытайның иң борынгы идарәчеләреннән булган император Яо заманына кадәр үк яшәгән дип искә алына. Яо тәхеткә б.э.к. 2357 елда утыра. Сыма Цяньның «Тарихи язмалар»ында сөннәр дәүләтенең кайчан оешуы турында да хәбәрләр бар, ләкин алар Кытай



Кабиләләрнен Үзәк Азиядә таралып урнашуы (б.э.к. VII гасыр). Чыганак: *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия, 1993



Үзәк Азия б.э.к. 135 елларда (сәяхәтче Чжан Цянь мәгълүматлары буенча). Чыганак: *Гумилев Л. Н.* Хунну// Степная трилогия, 1993

риваятьләренә нигезләнгән. Сыма Цянь язуынча, Сөн дәүләтенең тарихы Ся династиясе патшасының улы Шун-вэйдан башлана. Шун-вэй Кытайдан качып китә, тик үзе генә түгел, үзе белән тагын 500 кытай кешесен алып килә дә сөннәрнең патшасы була[6]. Ся династиясе, Кытай риваятьләрендә сөйләгәнчә, б.э.к. 2219—1819 елларда хакимлек итә. Димәк, Сөн дәүләте Кытай риваятьләре буенча б.э.к. 2000 ел чамасы элек төзелгән. Риваятьләрнең берсендә әйтелгәнчә, Хуанхэның көньягында яшәгән кытайлар үзара даими сугышып тора, һәм кайбер кабиләләр төньякка китәргә мәҗбүр була. Бу вакытта Кытайдан качучылар аз булмый. Алар борынгы бай һәм шактый югары мәдәнияте булган дала качаклары — динлиннар, ди һәм башка кабиләләр арасына килеп керә. Кытай качакларының дала кабиләләре белән кушылуыннан сөннәр барлыкка килә. Бу хәлләр Ся династиясе чорында була. Бу риваять — Шун-вэй турындагы риваять белән дә аваздаш. Риваятьләрдәге вакыйгаларның дөреслеге башка вакыйгаларны һәм археологик материалларны чагыштыру юлы белән дә раслана. Бу вакыйгалар турында б.э.к. 1300—1200 елларда хайван сөякләренә төшерелгән иероглиф язулар да хәбәр итә[7].

Кытайлар сөннәрне каты кысрыклый, көньяктагы джунглиларга куа, ләкин алар б.э.к. 1200 елга кадәр Ордоста кала. Кытайның төньягындагы җирләрдә сөннәр генә түгел, башка күчмә кабиләләр дә яши. Алар озак еллар Кытай империясе өчен коллар чыганагы булып тора.

Б.э.к. 1200 еллар тирәсендә сөннәр тарихи батырлык кыла — Гоби чүлен үтеп чыга. Кытай чыганаклары чүл аша чыгучы сөн кабиләләренең исемнәрен дә хәбәр итә — болар хянь-юнь һәм хуньюй кабиләләре. Аңарчы Гоби аша бер генә кабиләнең дә чыкканы булмаган, һәм аны кичү һич мөмкин түгел дип саналган, чөнки бу чүл коелучан күчмә комнан тора, көндез эсселек 60 градуска, күләгәдә 35 градуска кадәр җитә һәм таңга кадәр кимеми. Адашып һәлак булган антилопа, кыргый дөя үләксәләре, мыжлап торган кимерүчеләр, көчле җилләр һәм ком бураннары, сусызлык бу үле җиргә килгән һәркемнең котын алган[8].

Гоби аша кичкәндә, ихтимал, корбаннар да аз булмагандыр. Ни өчен сөннәр шундый хәтәр эшкә тәвәккәлли соң? Сәбәпләре аз түгел. Һәр дала билгеле сандагы халыкны гына туендырып тора ала. Кытай идарәчеләренең явызлыгы чиксез була. Кытайлар күчмәннәрне «төньяк варварлары» дип атый, табигатьтән файдаланып, берни дә җитештермәүчеләр дип бәяли. Күчмә терлекчелекнең кыенлыклары кытайларга билгесез була. Алар күчмәннәргә каршы туктаусыз сугышлар алып бара, сөннәрдән котылырга тели.

Сөннәр үзләре дә тынгысыз һәм дәһшәтле күршеләр булган. Дала аларны туендыра алмый башлагач, зур урда белән хәрби походлар оештыралар. Моның өчен зур көч, түзем сугышчылар кирәк булган. Л. Н. Гумилев ул чорда Бөек далада климатның зур үзгәреш кичерүен сөннәрнең чүл аша күчү сәбәпләренең тагын берсе итеп күрсәтә. Муссоннар юнәлеше үзгәрә, бу явым-төшемнең кимүенә һәм даланың кибүенә китерә[9].

Үзләренең Гоби аша күченүләре белән сөннәр бер-берсенә билгеле булмаган ике дөньяны — Кытай һәм Себерне тоташтыра. Кытай чыганаклары сөннәрне төрлечә атый: «шан жун», соңрак «хянь-юнь», «хунь-юй», «сюнну һәм хунну»[10]. Франция галиме Абель Ремюза сөннәрнең Кытай елъязмаларында китерелгән исемнәренең вариантлары — аларны кимсеткән атамаларның төрләре дип яза. Әйтик, «хунь-ё» — сатлык колны, «гуй-фан» — дию пәрие кебек колны, «хьян-юнь» — оятсыз, алдакчы колны, «хун-ну» явыз колны белдерә[11]. Билгеле полиглот һәм фәнни тикшеренүче Клапрот болай ди: «Кытай тарихчылары сөннәрне Шан династиясе вакытында (б.э.к. 1766—1134) «хьюнь-ю» дип, Чжоу династиясе чорында (б.э.к. 1134—256) «хьянь-юнь» дип, Цинь һәм Хань династияләре вакытында (б.э.к. 256 — б.э. 263) «хун-ну» дип атый[12]». Н. Я. Бичурин, Г. Е. Грумм-Гржимайло, К. Иностранцев һәм Л. Н. Гумилев аларны «хун» һәм «гун» (Европага күчкәч) дип атыйлар. Сөннәр төзегән дәүләтне кытайлар «Хунну» дип атый. В. С. Таскин, Кытай чыганакларын тәрҗемә иткәндә, бу дәүләтне «Сөнну» дип атый.

Сөн юлбашчысы. V гасыр.
М. В. Горелик реконструкциясе

Археолог, тарихчы һәм нумизмат Ә. Г. Мөхәммәдиев сөннәрнең үзатамасы «hunuk» булган дигән гипотеза белдерә. Үзенең гипотезасын ул Харәзем тәңкәләрендәге һәм Кама буенда табылган савыттагы язулар белән бәйли. Рун язмаларында «ун ук» кабиләсе еш искә алына, ул төрки телле «сир» кабиләсенә каршы көрәшкән[13].

Хәзерге татар телендәге тарихи әдәбиятта бу этнонимны ике төрле язу күренә: «һун» һәм «сөн». Рус тарихи әдәбиятында «хун», ә Европага күчкәннән соң «гун» дип атау гадәткә кергән. Кайбер галимнәр фәкать «гун» терминын гына куллана. «Хун»

Сөн җайдагы. Кытай рәсеме

бер үк халыкның — кытайча, «һун» Рим-Византиячә әйтелеше диган фикер дә бар. Бу хезмәтнең авторы рус телендә язганда «хун» һәм «гун» дигән, ә татар телендә «сөн» һәм «һун» (Европага күчкәч) дигән терминнарга тукталды.

Без Кытай елъязмаларында сөннәр турында беренче мәгълүматлар б.э.к. 2357 елга бәйле, аннан соң б.э.к. 2219 елга нисбәтле күзәтелә дигән идек. Шуннан соң 1000 ел буена, ягъни 882 елга кадәр Кытай тарих хроникалары сөннәр турында бер мәгълүмат та бирми. 882 елдан 304 елга кадәр алар тагын онытыла[14]. Югарыда әйтелгәнчә, сөннәр тарихының төп язма чыганагы булып Борынгы Кытай тарихчысы Сыма Цяньның «Ши-цзи» («Тарихи язмалар») исемле хезмәте тора, анда Кытай тарихы язылган. Сөннәр тарихын язуга ул бу китапның тулысынча 110 нчы бүлеген багышлый. Сөннәр турында хәбәрләр башка бүлекләрдә дә бар. Сыма Цянь сөннәр турында бик борынгы заманнардан алып үзе яшәгән чорга кадәр булган мәгълүматларны эзлекле итеп яза. Ул сөннәрнең бабалары Кытай хроникаларында «жун» дип аталган кабиләләр дигән фикергә килә.

Кытай тарихчысы Ванговэй (1877—1927), борынгы язма чыганакларны җентекләп өйрәгәннән соң, төрле чорларда, төрле чыганакларда «гуйфан», «хуньи», «сюнюй», «сйянюй», «жун», «ди» һәм «ху» дип аталган кабиләләр соңыннан «сөн» дип аталган бер халык атамасы дигән фикергә килә[15].

Шулай итеп, сөннәр инде Кытай дәүләте төзелү чорында ук актив тормыш алып барганнар, үзләренең күршеләре белән аралашканнар.

Сыма Цянь язганча, сөн җәмгыяте үсеше ике чорга бүленә: беренчесе — сөннәрнең риваятьләрдә сөйләнгән патша Шунь-вэйдан алып Төмән шаньюйга кадәрге чор, икенчесе Төмән шаньюйдан башлана. Бу чорның хронологик рамкаларын шартлы рәвештә генә билгеләп була: Шун-вэй б.э.к. 2219—1819 елларда яшәгән Ся династиясе чорында патшалык иткән, Төмәннең патшалык итә башлаган елы билгесез, 209 елда һәлак була.

Сөннәр турында чыганаклардагы мәгълүматлар бик каршылыклы. Бертөрле чыганакларның язуы буенча сөннәр ыруглык җәмгыятендә

яшәгән, аларның әле дәүләте булмаган. Француз галиме Дегинь, Сыма Цянь язмаларына таянып: «Б.э.к. 1200 ел тирәсендә без Сөн дәүләте төзелүне теркәргә тиешбез»,— дип яза. Бу фикерне икенче бер француз фәнни тикшеренүчесе Кордье да яклый[16].

Борынгы сөннәр күчмә терлекчелек һәм җәнлек аулау белән шөгыльләнә. Кытай тарихчылары аларның өйләре булмавы, чатырларда яшәүләре турында яза.

Сыма Цянь намуслы тарихчы була, тарихи вакыйгаларны зур төгәллек һәм дөреслек белән теркәп барырга тырыша. Әмма борынгы хәлләрне тасвирлаганда, үз заманының вакыйгаларын һәм күренешләрен ерак чорларга да күчерергә, аларны тәңгәлләштерергә тырышкан. Ләкин нигездә ул киләчәк буыннар өчен күп дөрес мәгълүмат калдырган. «Ук белән ата белгәннәрнең барысы да кораллы атлы гаскәргә кергән... Һәркем һөҗүм ясау өчен хәрби күнегүләр белән шөгыльләнгән... Көчлеләр майлыракны һәм яхшыракны ашый; олыгайганнар алардан соң калганнар белән туена, яшьләрне һәм көчлеләрне ихтирам итәләр, картларны һәм көчсезләрне аз хөрмәт итәләр... Гадәттә, бер-берсен исемнәре белән атыйлар, кушаматлары һәм ыругны белдерүче атамалары юк»[17].

Сыма Цяньның бу мәгълүматы сөннәрнең Ордоста яшәгән чагына туры килә. Һәм анда ыруг мөнәсәбәтләренең йомшаруына киная бар, ә бу чорда ыруг мөнәсәбәтләре көчле булырга тиеш иде. Сыма Цяньның соңрак язуынча, 1200 елдан соң сөннәрнең гадәтләре башка була, алар «өлкәннәрне ихтирам итә, елның билгеле вакытында үз эшләрен көйләү өчен җыелалар»[18].

Чыганаклар булмау сәбәпле, сөннәрнең 1200 елдан IV гасырга кадәр тормышы караңгы. Б.э.к. III гасырда алар инде Гобидан алып Себер тайгасына кадәр даланың хуҗасы була. 1000 елга сузылган бу чорда Көньяк Себердә күп вакыйгалар була, сөннәрнең һәм Себернең башка кабиләләренең үзара йогынты ясаулары дәвам итә. Бу, әлбәттә, эзсез калмый. Чүл аша күчкән 1200 елдан соң ук инде сөннәр үзләренең Кытай риваятьләрендә тасвирланган Ся династиясе чорындагы бабаларыннан нык аерыла. Чүл аша чыгып, тагын 1000 ел узгач, алар тышкы кыяфәтләре белән дә, гореф-гадәтләре белән дә үзгәрә төшәләр. Ләкин кайбер авторлар язганча, сөннәрнең европеоид кыяфәтле булуы дөрес түгел.

Б.э.к. 1 меңьеллыктан башлап, сөннәр алып килгән, үзендә Кытай мәдәнияте элементлары булган Карасук мәдәнияте бөтен Көньяк һәм Көнбатыш Себердә тарала. Тарих сөннәрне беренче күчмәннәр буларак белә. Аларда хуҗалык нигезен гаилә тәшкил

итә. Һәр гаилә үзенең ат, сарык һәм мөгезле эре терлек көтүе белән күчеп йөри. Ләкин бу тәртипсез күченү булмый, аның гаиләләр арасында килешенгән үз тәртибе була. Күчү урыннары катгый тәртиптә бүленә, ыругның һәм гаиләнең милке булып тора.

Күп санлы Себер кабиләләре өстенә сөннәр арасына Кытайдан даими рәвештә халык килеп тора. Кытайда халык артык күп була, бик катгый законнар хөкем сөрә. Кытай чиновнигы Хоу Инның хөкүмәткә җибәргән хәбәре буенча Кытай чиновниклары тарафыннан изелүче кабиләләр, сәяси җинаятьчеләр, сәяси эмигрантларның гаиләләре: «Сөннәрдә яшәве күңелле»,— дип, чик артына качу турында гына уйлый. Сөннәр аларны теләп кабул итә, ләкин үз ыругларына кертми, тегеләр аерым авыллар булып урнаша, үзара аралашып кушыла һәм сөн телен кабул итә. Сөннәр аларны «кул» дип атый һәм кол итеп куллана. Б.э.ның 1 меңьеллыгы башында сөннәрнең саны 300 мең була[19]. Сөннәрдән көнчыгыштарак, хәзерге Маньчжуриядәге Зур Хинганда сөннәргә охшамаган борынгы кабиләләр яшәгән. Кытайлар аларны «дунху», ягъни «көнчыгыш варварлары» дип атый. Аларның варислары сяньби һәм ухуаннар була[20].

Сөннәрнең күршеләре

Бу чорда сөннәрдән төньяктарак динлиннар яши, алар Саян сыртының ике ягында, Енисейдан Селенга елгасына кадәр араны биләп тора. Г. Е. Грумм-Гржимайло динлиннарны ак расага нисбәтле дип расларга тырыша, ләкин моның бернинди нигезе дә юк. Енисей буенда, Минуса казанлыгында борынгы кыргызлар (кытайча «цигу») яши, алар динлиннар белән гяньгуньнәр кушылудан барлыкка килгән халык була. Алардан көнбатышта, Алтайның төньяк итәкләрендә кыпчакларның бабалары (кытайча «цюеше») урнашкан була. Кыпчаклар турындагы беренче хәбәрләр б.э.к. III гасырга карый. Саян-Алтайның төньягында аз билгеле бома халкы яшәгән. Аларның күршеләрендә алакчин һәм бикиннар яши. Гоби аша чыкканнан соң, сөннәр югары мәдәниятка ия булган җирле дала халыклары белән кушыла[21]. Соңрак сөннәр Глазков мәдәнияте кабиләләре белән очраша[22]. Бу кабиләләр арасында сөннәр сугышчанлыклары белән аерылып торган, ләкин башка гайрәтле кабиләләр дә була. Башта сөннәрне сяньбиләрнең (борынгы монголларның) бабалары үзләренә буйсындыра, аннан согдиялеләр (юэчжиләр), Урта Азиядән Ордоска кадәр җирләрне басып алып, сөннәргә ясак сала[23].

Сөнну дәүләте

Без, Кытай риваятьләрендә сөннәрнең б.э.к. 1200 елда, хәтта алдарак та дәүләтләре булу турында мәгълүматлар барлыгын белсәк тә, бу хәбәрләр башка язма чыганаклар белән расланмагач, сөннәрнең дәүләт тарихын ул заманнардан башлап китә алмыйбыз. Ә сөннәрнең б.э.к. IV гасырда үзләренең куәтле дәүләтен — гомерлеккә куелган идарәче һәм ыруг башлыклары иерархиясе тарафыннан идарә ителгән кабиләләр берлеген төзү турында чыганаклар ышанычлы итеп язалар. Шуңа күрә күп тарихчылар Сөнну дәүләте тарихы б.э.к. IV гасырдан башлана дип исәпли. Үзләренең идарәчеләрен сөннәр «ябгу» дип атап йөрткән, ә кытайлар аларны «шаньюй» дип атый. Ыруг башлыклары үз ыругылары белән халык ополчениесенә таянып идарә иткән, ул ике меңнән бер меңгә кадәр атлы сугышчыдан торган. III гасырда бөтен Үзәк Монголия сөннәр хакимлеге астында була. Сөннәр дәүләтен тарихи әдәбиятта «Сөнну», «Бөек Сөн каһанлыгы», «Бөек Сөнну дәүләте» дип атыйлар. Сөнну — төрки телле борынгы халыкларның озын гомерле бөек дәүләте. Бу дәүләт составында күп кенә борынгы төркиләр яши, бер-берсе белән аралаша, этногенетик процесслар дәвам итә.

Сөннәр дәүләте хәрби держава була. Сугышчыларның төп коралы ук-җәядән торган. Дошманны алҗытып хәлсезләндерү практикасы кулланыла. Хәрби хезмәт түләүсез була, басып алынган малга хокук тәртибе саклана.

Кытай биш гасыр буена жуннар белән сугыш алып барган чорда сөннәр үзләренең җисми һәм рухи мәдәниятләрен үстерә. Бу турыда Монголиядә һәм Байкалның көньягында табылган археологик материаллар сөйли. Бу зур регионда үзенчәлекле каберләр системасы табыла, аларны археологлар «яссы ташлы» дип атый. Бу чорда сөннәр башка халыклар белән элемтәләрен Һинд океанына кадәр җәелдерә. Нигездә терлекчелек белән шөгыльләнеп, алар металл табу, эшкәртү һөнәрен үзләштерә, металл, бигрәк тә бронза кою техникасын камил дәрәҗәгә җиткерә. Тимер әйберләр дә очрый.

Б.э.к. IX—IV гасырларда сөннәр шул кадәр көчәеп китә, алар IV гасырда Гоби чүленең көньягына — ата-бабалары җире булган борынгы ватаннары Ордоска кире кайта һәм игенчелек белән шөгыльләнә башлый.

Б.э.к. III гасырда сөннәрнең хәле Кытай чигендә генә түгел, ә көнбатышта да, көнчыгышта да катлаулана. Сяньбиләрнең бабалары сөннәрне буйсындыра, көнбатыштан килеп согдиялеләр

(юэчжиләр) дә сөннәрне буйсындыра һәм аларга ясак сала. Бу чорда Сөнну дәүләте белән Төмән (Тумын, Тогрил) шаньюй идарә итә, аның төп уе үз хакимлеген саклап калу була, дәүләт эшләре аны аз кызыксындыра.

Ордостан куылганнан соң, җәмгыятьнең яшь көчләре дәүләттә бердәмлекне ныгытуга омтыла. Төмән шаньюйның улы Модэ (кайбер чыганаклар буенча Босхар, Мете яки Маодунь) әтисенең гамәлләре белән риза булмый, ул аны радикаль гамәлләр кылмый дип гаепли. Үзенең улыннан шикләнеп, Төмән аны юэчжиләргә тотык итеп җибәрә һәм аларга каршы провокацион сугыш башлый, улын үтерерләр дип уйлый. Модэ, әтисенең хыянәтен сизеп, аның янына әйләнеп кайта. Әтисе аңа 10 мең гаиләне бүлеп бирергә мәҗбүр була. Модэ үз биләмәсендә ныклы тәртип урнаштыра. Яшь көчләр ярдәмендә дәүләт түнтәреше ясый, шул вакытта әтисе, аның хатыны һәм энесе һәлак була. Модэ, үз тирәсенә сугышчан яшьләрне туплап, шаньюй булып китә һәм илдә катгый тәртипләр кертә.

Сыма Цянь бу хәлләр турында «Тарихи язмалар»да: «Маодунь б.э.к. 209 елда, үзенең әтисен үтереп, тәхеткә күтәрелде һәм шаньюй булды. Соңрак (б.э.к. 201 ел тирәсендә) Маодунь төньякта хуньюйлар, цуюшэләр, динлиннар, гэгуньнар һәм синьлиләрне буйсындырды, Сөннүнең барлык күренекле кешеләре һәм түрәләре аңа буйсынды һәм Маодунь шаньюйны акыллы дип исәпли башлады»,— дип яза.

Модэ үз эшчәнлеген күрше кабиләләрне буйсындырудан башлый. Яңадан Ордосны сугышып ала, согдиялеләрне (юэчжиләрне) көнбатышка куа. 201 елда Динлин дәүләтен буйсындырып, аларны төньякка куа һәм гяньгуньнәр җиренә утыра. Элекке урыннарында калган динлиннар, гяньгуньнәр белән кушылып, яңа Таштык археологик мәдәниятенә нигез сала (б.э.к. I гасыр — б.э.V гасыр). Көнчыгышта дунхуларны тар-мар итә[24].

Шулай итеп, Үзәк Азиядә тарихи әдәбиятта «Сөнну» яки «Бөек Сөн каһанлыгы» дип атала торган бөек дәүләт барлыкка килә, һәм аның белән барлык күрше дәүләтләр һәм кабиләләр исәпләшергә тиеш була. Хәтта Сыма Цянь да Модэ чорында сөннәр: «Урта дәүләткә тиң дәүләт төзеде»,— дип яза. Сөнну дәүләтенең чиге көнбатышта хәзерге Циньцзянга җитә, көнчыгышта Ляохэ елгасына һәм Маньчжуриягә, көньякта Кытайга җитеп, Бөек Кытай стенасы буйлап уза, төньякта Сөнну биләмәләре Байкал күленә кадәр сузыла[25].

Бу вакытта Кытайда үзара сугышлар, восстаниеләр башлана, алар ватандашлар сугышына китерә. Сугыш рәхимсез була, Борынгы Кытайда әсирләр алу гадәте булмый. Цинь гаскәрләре

эсирлеккә эләккән кешеләрне терелэй җиргә күмә, шуңа күрә халык күп һәлак була.

Зур югалтуларга карамастан, Хань империясе Сөнну чикләрен борчып тора. Модэ Ханьга каршы сугыш башлый һәм 200 елда Лю Банны җиңә, «туганлык һәм тигезлек шартнамәсе» төзергә мәҗбүр итә. Шартнамә буенча Кытай императоры үз кызын Модэга кияүгә бирә һәм ел саен аңа бүләкләр җибәреп тора, ягъни яшерен ясак түли.

Хисапсыз сугышлардан соң сөннәр алардан алҗыйлар. Кытай белән тыныч яшәргә, азык-төлек, ефәк һ.б. товарлар белән сәүдә итәргә телиләр, алмашка үзләренең терлекчелек һәм аучылык продуктларын тәкъдим итәләр. Бу сөннәргә дә, кытайларга да файдалы була. Ләкин Хань хөкүмәте бу акчасыз товар алмашуны тыя, чөнки казнага аннан табыш керми. Сөннәр Кытайга һөҗүмнәрен яңарталар. Ләкин сөннәргә күбесенчә Хань императорыннан сакланырга туры килә.

Ватандашлар сугышыннан һәм Хань династиясе урнашканнан соң, Кытайда көчле үсеш башлана. Халык саны 60 миллион чамасына җитә[26]. Кытай галиме Ця И (б.э.к. 200—168 еллар) «Синшу» китабында сөннәрнең чама белән 60 мең атлы сугышчысы бар, чама белән биш кешегә бер атлы сугышчы туры килә, димәк, сөннәр барлыгы 300 мең кеше дип язып калдыра. Сыма Цянь бу санны киметелгән дип исәпли. Ул бераз элегрәк Модэ Кытай гаскәрләрен чолгап ала, бер авторның хәбәр итүе буенча аның 400 мең, икенчесенеке буенча 300 мең атлы сугышчысы булган дип саный. Бу сан дөреслеккә якын булса, сөннәрнең 1 млн 400 мең кешесе була. Шуңа да карамастан сөннәр б.э.к. 202—57 еллар эчендә Хань агрессиясенә каршы тора ала. Шуңа күрә Хань идарәчеләре, Сөн дәүләтен бетерү өчен, сугыштан башка чаралар да эзли башлый[27].

Модэ бөек держава төзи, ул хәрби яктан гына түгел, үзенең хуҗалыгы белән дә көчле булган. Сөн җәмгыятенең икътисади тормышы да алга китә. Сөн идарәчеләре яулап алынган халыклар һәм дәүләтләр тормышын үз дәүләте хуҗалыгын ныгытуга көйли. Мәсәлән, Тывада һәм Алтайда сөн гаскәрләренең зур булмаган гарнизоннары урнаштырыла. Сөннәрдә бу чорда кара металлургия уңышлы үсә. Сөн металлурглары тарафыннан күршеләрнең тимер һәм бакыр рудниклары тикшерелә. Тимер һәм бакыр рудасы чыгару өчен, җирле тау эше осталары, эретүчеләр һәм тимерчеләр хезмәте файдаланыла. Яулап алынган халыкның хезмәте һәм салымнары сөн законнары белән көйләнә. Байкал аръягында шәһәрләр һәм һөнәрчеләр бистәләре, Минуса казанлыгында кальгалар төзелә.

Модэ шаньюй тарафыннан ныгытылганнан соң, Борынгы Сөн дәүләте бөек державага әверелә. Барлык күрше дәүләтләр һәм кабиләләр аның белән килешергә һәм бөеклеген танырга тиеш була.

Модэ үлгәннән соң, аның улы Гиюй шаньюй булып кала, ул үзенә «Лаошань шаньюй» дигән исем ала. Хуҗалык һәм тышкы элемтәләр өлкәсендә ул этисе сәясәтен тота. Бу вакытта Сөннүнең халыкара хәле бераз катлаулана. Әгәр элек сөннәр таркау кабиләләр белән мөнәсәбәткә кергән булсалар, соңрак аларның тирә-ягында көчле дәүләтләр барлыкка килә. Б.э.к. II гасырда Амудәрья буйларында Александр Македонский империясе калдыгы — Грек-Бактрия дәүләте яши. Б.э.к. 160 елда аның территориясенең бер өлешендә Согдиана дәүләте төзелә. 129 елда аны юэчжиләр яулап ала. Аларның дәүләте Кытай белән янәшә, Наньшаньда урнашкан була. Җидесуда үсүннәрнең көчле дәүләте төзелә. Сөннәр һәм үсүннәр, мөгаен, үз чамаларын белгәннәр, берберсе белән сугышмаганнар, тыныч мөнәсәбәттә булганнар. Ач далада Кангюй дәүләте урнашкан була. Бу көнбатыш дәүләтләр Сөннүгә куркыныч тудырмый, киресенчә, үз дәүләтләренең чикләрен саклап, Сөннүнең көнбатыш чикләрен дә куркынычсызрак итә. Сөннәргә Кытай белән көрәшкә күбрәк көчләр куярга мөмкинлек туа.

Көнбатыш төрки дәүләтләр белән сөннәр тыныч яши, ә көнчыгышта алар үзләрен дөньяның бу өлешенең хуҗасы итеп сизә. Көньяк Маньчжурия далаларында Кытай белән янәшә урнашкан Дунху дәүләте Модэ тарафыннан буйсындырыла. Дунху каршылык күрсәтми, чөнки күршедә тагын да агрессиврак дәүләт — Кытай урнашкан була. Тиздән дунхулар үз исемнәрен дә оныта һәм «ухуань» этнонимы ала.

Дунхудан көнбатыштарак «сяньби» һәм «тоба» исемле монголоид кабиләләр яши. Сөннәрнең динлиннарны һәм гяньгуньнәрне җиңүе турында инде без беләбез. Шулай итеп, көнбатыштан, төньяктан һәм көнчыгыштан сөннәргә беркем дә янамаган, алар дөньяның хуҗасы була.

Кытай, әйткәнебезчә, күчмәннәргә карата агрессив сәясәтен үзгәртмәгән. Бу турыда дәүләтләре булган һәм булмаган барлык күчмәннәр, шул исәптән сөннәр дә белгән. Кытайга каршы торуның төп авырлыгы сөннәр өстенә төшә, чөнки башка дәүләтләр һәм кабиләләр көчсез була.

Үзенең көньяк күршесенең сәясәтен белеп, Лаошань шаньюй б.э.к. 166 елда Кытайга яу белән бара. 140 меңле атлы гаскәр Төньяк-Көнбатыш Кытайга бәреп керә, «бик күп халык, терлек һәм

байлык яулап ала» һәм императорның җәйге сараен яндыра. Сугыш Кытай императоры Вэнь-динның солых сорап мөрәҗәгать итүеннән соң гына туктатыла. Солых Кытай өчен хурлыклы була. Сугышта катнашкан ике дәүләт тә тигез дип таныла. Кытай, Сөнну дәүләтенең «салкын климатын исәпкә алып», шаньюйга ел саен «билгеле күләмдә тары, ак дөге, парча, ефәк, киҗе-мамык тукымалар һәм башка төрле әйберләр җибәреп торырга тиеш була»[28].

Б.э.к. II—I гасырларда Кытай Сөннүне алҗытуга юнәлдерелгән вак сугышлар алып бара. 166 елгы җиңелүдән соң ул Сөннүгә агрессиясен көчәйтә. Сөннәр бу агрессиягә даими каршы тора. Сөннү белән Кытай арасындагы мөнәсәбәтләр император У-ди вакытында бик кискенләшә, Кытай сугышка әзерләнә башлый. Ләкин сөннәр беренче булып һөҗүм итә. Сугыш әле бер, әле икенче якның җиңүе белән 120 елга кадәр, ягъни 6 ел дәвам итә. 119 елда Кытай Гоби аша походка чыга, ике яктан да зур югатулар була. 7 ел әзерләнгәннән соң, Кытай 100 меңле җәяүле, 70 меңле атлы гаскәр белән, тагын 70 мең күрше жуннарны да кушып, төньякка һөҗүмгә чыга һәм җиңелә[29].

Сөн дәүләтендә терлекчелек үсә, һөнәрчелек югары үсешкә ирешә. Сөннәр Кытай базарларында терлекчелек һәм һөнәрчелек продуктлары белән сәүдә итә, кытайлардан икмәк һәм кием-салым ала башлый. Кытайлар үрнәгендә сөннәр үзләренең игенчелеген тагын да интенсивррак үстерә, бу эштә әсирлеккә алынган кытайларны яки Кытайдан качып килгән кешеләр хезмәтен файдалана.

Кытай белән мөнәсәбәтләр

Сөн дәүләте яшәү чорында Кытайда колбиләүчелек җәмгыяте хөкем сөрә. Коллар сафын кытайлар сөннәр һәм башка күчмәннәр хисабына тулыландырганнар. Шуңа күрә Кытай белән күчмәннәр арасында сугышлар еш була. Ике арада һәрвакыт сугышлар кабынып торганга күрә, Кытай чыганаклары сөннәрне агрессив итеп күрсәтә.

Үзәк Азия күчмәннәренә һәрвакыт ике фронтта көрәшергә туры килә: яшәү өчен көрәш һәм Кытай агрессиясеннән саклану. Агрессив көньяк күршегә каршы көрәшү сөннәрне берләшергә мәҗбүр итә. Аннан соң сөннәр тирәсенә башка кабиләләр: динлиннар, үсүннәр, дунху кабиләләре (сяньби һәм монголларның бабалары), Тибетның күчмә кабиләләре берләшә. Бу полиэтник берләшмә Кытайга каршы тора алган. Колбиләүчеләргә каршы көрәштә Кытай коллары сөннәргә һәм башка күчмәннәргә таяна. Күп кенә коллар, Кытай стенасын үтеп, коллыктан котыла, утрак тормышка

күчеп, сөн ябгуына ясак түли[30]. Колбиләүчелек Кытаеның һәм ирекле күчмәннәрнең бәрелешләре котылгысыз көрәшкә һәм колбиләүчелек җәмгыятенең әкренләп таркалуына китерә.

Гоби аша күчкәч, сөннәр Кытай белән күрше булудан котыла, бу аларга агрессив дәүләттән еракта тыныч яшәргә мөмкинлек бирә. Сөннәр һәм Кытай арасында ул вакытта жуннар — көнчыгыш монголлар яши, аларны «дунху» дип тә атыйлар[31]. Кытайда бу чорда Чжоу кенәзлеге яши. Ул 1855 вак кенәзлектән торган агрессив, ләкин көчсез дәүләт була. Чунцю чорында вак кенәзлекләр берләшә, алар бары 124 кә кала, ә Чжонга чорында 7 зур һәм 3 кечкенә кенәзлек кала. Бу Чжоуны көчәюгә китерә. Б.э.к. 1125 елда Чжоу үзенең күршеләренә каршы сугыш башлый. Ул чорда сөннәр һәм Кытай арасында жуннардан башка «сина» һәм «сера» исемле халыклар яши[32]. Кытай биш гасыр буе алар белән һәм жуннар белән сугыш алып бара һәм, җиңеп, жуннарга караганда күпкә көчле сөннәр белән күрше булып кала[33].

Ләкин кытайлар күчмәннәрнең дошманнары булып кала һәм аларны кырып бетерү бурычын куя. Алар сөннәр һәм башка күчмәннәр белән туктаусыз сугышлар алып бара, әкренләп, әмма туктамыйча аларны туган илләреннән төньяккарак кысрыклый. Бу процесс 1000 ел буе бара. Бу чорның ахырына кытайлар яшәп килгән меңнән артык вак кенәзлек урынына бердәм Цинь дәүләте төзи. Б.э.к. 215 елда Император Цинь-ши-хуанди яңадан Ордосны яулап ала, хуннарны куа. Цинь дәүләте көчәя, «Чин» һәм «Мачин» исеме астында Һиндстанда, Иранда һәм Көнчыгышның башка илләрендә билгеле була. Сөннәр кире Монголиягә күчеп китә[34].

Кытай идарәчеләре дүрт гасыр буена Азиядә хакимлек итүче көч булырга һәм Себерне яулап алырга омтыла. Себердән соң аларның Европага китү ихтималы була, чөнки бу чорда аларның юлында сөннәрдән башка каршы торырлык көч калмый. Ләкин сөннәр кытайларны Себергә үткәрми, бу аларның бөек казанышы булып тора. Кытайлар Себергә үтеп керергә б.э. VII—VIII гасырларында да (Бөек Төрки каһанлыгы чорында) омтылып карый. Бу юлы да төркиләр Себерне саклап кала. Сөннәр кытайларга караганда берничә дистә мәртәбә азрак булса да, Цинь чорында да, Хань чорында да алар Кытай агрессиясенә каршы тора алган. Сыма Цянь язуы буенча, моның ике төп сәбәбе бар: беренчесе — күчмә империя шартларында дәүләт идарәсен оригиналь рәвештә оештыру. Дәүләт өч өлешкә бүленә: үзәк, уң, сул канатлар. Бөтен хакимият шаньюй кулында була. Шул ук вакытта ул үзәк белән идарә итә. Сул канат белән тәхет варисы — олы улы идарә итә, уң канат белән идарә итү шаньюйның иң якын туганнары кулында туплана. 24 югары

дәрәҗәле түрә эре кабилә берләшмәләре белән идарә итә, алар «төмән башлыклары» (төмән 10 мең сугышчыны берләштерә). Һәр дистә, йөз, мең сугышчының җитәкчесе була. Алар сугыш вакытында да, тыныч чорда да җитәкчелек бурычларын башкара[35]. Сөннәргә каршы көрәштә Кытай армияне генә түгел, дипломатияне, икътисадны, зиннәтле малны да файдалана. Икенче сәбәбе сөннәрнең хуҗалык итү системасына бәйле. Югарыда әйтелгәнчә, сөн хуҗалыгының нигезен күчмә терлекчелек тәшкил иткән. Аларда беркадәр игенчелек тә, һөнәрчелек тә була. Ит, сөт продуктларына алмашка сөннәр кытайлардан үсемлекчелек продуктлары, кием өчен ефәк һәм башка кирәкләр алган. Ләкин сөннәрне һәрвакыт дошман санаган Кытай җитәкчеләре бу алмашуны тыя. Шул шартларда сөннәр Кытайга сугыш белән керә, җиңү күбесенчә алар ягында була. Сөннәр Кытай императорын килешү шартнамәсе төзергә мәҗбүр итә. Шартнамә буенча Кытай ягы сөннәргә ел саен «бүләкләр» бирә: ашлык, башка азык продуктлары, ефәк, һөнәрчелек әйберләре. Шаньюй, халык мәнфәгатеннән чыгып, бүләкләрне халыкка җитәрлек итеп сораган. Мәсәлән, ел саен сөн шаньюйлары Кытайдан 10 мең кисәк ефәк алган, бер кисәктә 9,24 метр ефәк була. Бу кадәр ефәк шаньюй түрәләре өчен киемгә дә, кабилә башлыкларына бүләк итеп бирергә дә җиткән. Бүләк бирергә теләми икән, Кытай ягы алмаш сәүдәгә рөхсәт бирергә тиеш була, императорлар кытайларның сөннәр белән аралашуыннан курыккан.

Сөннәрне көчсезләндерү өчен, Кытай бик еш сугышлар оештыра. Сугышта нигездә сөннәр җиңә, Кытай җиңсә дә, сугыш бетүгә, гаскәр кайтып китә, далада, күчмәннәр арасында яшәп булмый[36].

Император Цинь-ши-хуанди үзенең төньяк чикләрен ныгытырга һәм Бөек стена төзергә тотына. Бу төзелеш күптән башланган була, ләкин стеналар өзек итеп, төрле урыннарда төзелә. Цинь-ши-хуанди аларны бердәм чылбырга тоташтыра. Эш тәүлек буе алып барыла, бу эштә хәрби әсирләр, хөкем ителгәннәр файдаланыла. Күп кенә төзүчеләр стена астында мәңгелеккә кала. Нәтиҗәдә кеше хезмәтен мәрхәмәтсез эксплуатацияләү һәйкәле — озынлыгы 4000 км, биеклеге 10 метр булган, һәр 60—100 метр саен саклау манарасы куелган стена калка. Күчмәннәр бу корылманы үтеп чыгу ысулын тиз таба, стенада һәм манарада торучы Кытай сугышчылары күчмәннәр өчен тере мишень була. Тик күчмәннәрнең атлы гаскәре һәм Кытайдан качып китүчеләр стенаны алдан әзерлексез үтеп чыга алмый.

Б.э.к. 210 елда Цинь-ши-хуанди үлгәннән соң, Цинь дәүләтендә эчке ызгышлар, восстаниеләр башлана, алар ватандашлар сугышына китерә. Күп халык һәлак була. Бигрәк тә Цинь гаскәрләре коты-

рына, алар әсирләрне терелә жиргә күмә. Крестьяннар юлбашчысы Лю Бан сугышны туктата һәм Хань династиясе башлануын хәбәр итә, б.э.к. 202 елда Цинь династиясе яшәүдән туктый[37].

Кытай диверсиясе

Сөннәрнең хуҗалыгы ныгу кытайларны борчый, ә Кытай хөкүмәте аларны көчсезләндерүгә нигезләнгән, еракка юнәлдерелгән стратегия һәм тактика эшли. Сөннүнең икътисадын какшату максатыннан чыгып, кытайлар сөннәргә арзан бәядән икмәк, һөнәрчелек әйберләре сата башлый. Сөнну базарлары арзан бәяле Кытай товарлары белән тула. Әкренләп сөннәр игенчелек һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнүне ташлый һәм бу эшләрне бөтенләй оныта. Сөннәр Кытай икмәге һәм һөнәрчелек әйберләренә бөтенләй бәйле булып беткәч, Кытай хөкүмәте аларны сөннәргә сатуны тыя. Сөнну дәүләтендә ачлык, һәртөрле товарларга кытлык башлана[38].

Кытай сөннәргә каршы сугыш сәясәтен беркайчан да үзгәртмәгән, ләкин күп вакыт сөннәрне тыныч юл белән килештерү сәясәте кытайлар өчен уңайрак була. Шул юл белән Хань хөкүмәте, кыйммәткә төшә торган һәм җимерүгә китергән сугышлардан котылу һәм Сөнну җәмгыятен эчтән какшату өчен, махсус «биш азындыру» (кытайча «хэцинь») стратегиясен эшли. Ул биш максатны күздә тота: 1) күзләрен камаштыру өчен, күчмәннәргә тукымалар һәм арбалар бирергә; 2) авызларын томалау өчен, аларга тәмле ризык бирергә; 3) колакларын томалау өчен, музыка белән алдарга; 4) ашказаннарын тынычландыру өчен, ашлык саклагычлар төзергә, коллар бирергә; 5) Кытай протектораты алырга теләүче кабиләләр өчен бүләкләрне күбрәк бирергә һәм аерым игътибар күрсәтергә.

Кытай сөннәргә карата алтынчы чараны да бик оста куллана — бу хәмер. Тарих буенча беләбез — халыкларны колонияләштерү процессында эчертеп исертү барлык чорларда да киң кулланыла. Бу явызлык Африкада да, Америкада да, Россиядә дә басып алынган халыкка бик зур зарар китерә. Рус колонизаторлары, Себернең хәмер зарары турында берни дә белмәгән кабиләләрен исертеп, аларның ел буе аулаган кыйммәтле җәнлек тиреләрен бөтенләй юк бәягә алып китә һәм шул рәвешчә ачлыкка, үлемгә дучар итә. Казанны яулап алгач, колониаль администрация, татар, чуваш, мари, удмурт авылларында кабаклар ачып, аларны русларга хезмәт итүгә күчкән җирле кешегә биреп, бик арзанга яки бурычка аракы сатып, эчү, исерү гадәте кертә.

Цинь сәясәте нигезендә Кытай Сөн шаньюйына һәр елны 10 мең дань дөге аракысы бирә. Бу 1 миллион литр дигән сүз, көнгә 2730 литр туры килә. Сөнну армиясендә 300 мең укчы булган дип фараз иткәндә дә, анда 300—350 гаскәр җитәкчеләре булырга мөмкин. Аларның һәрберсенә көнгә 8 литрга якын аракы туры килә[39]. Ә икмәк бик аз бирелгән. Ул 5000 ху тары булган. Кытай нормалары белән исәпләгәндә, бер ир кешегә елга 36 ху икмәк кирәк була. Шул норманы 5 кешегә бүлеп биргәндә дә, ул 700 кешегә генә җитәрлек була, ул шаньюй тирәсендәге түрәләрдән артмагандыр. Хецинь сәясәте, әлбәттә, сөннәр мәнфәгатен түгел, ә Кытай мәнфәгатен саклап башкарыла. 60 миллион халкы булган Кытай күп дигәндә 1 миллион ярым халкы булган Сөннүне җиңә, басып ала алмаганмыни? Бу күп факторларга бәйле була. Беренчедән, Кытай армиясе я ялланган яшьләрдән, я төрле җинаятьчеләрдән торган. Аларга көн үтеп, акча килеп торса, шул ярый. Ул армия бик кансыз кылана, әсирләрне нигездә кол итеп, күбрәк булганда үтереп бара. Сугышта җиңсә дә, сөннәрнең ганимәт малы итеп алырдай байлыгы булмаган. Терлекне сугыш башланганчы алар ерак алып киткән. Өйләрен дә җимереп булмый, чөнки алар тәгәрмәчле, кая кирәк, шунда алып китәләр. Сөн шәһәрләре Кытайдан ерак төзелә. Кытай армиясе кансыз булса да, гайрәтсез, әкрен хәрәкәтләнүче армия була. Сөннүнең дистә, йөз, мең, ун мең укчыга бүленгән атлы гаскәре җил искәндәй хәрәкәт иткән. Ат өстендә барган көе ук ату, кылыч белән дошманны кыру, кинәт маневрлар белән дошманның һушын алу тактикасы Сөннү гаскәрен дәһшәтле иткән.

Кытайның халык тыгыз утырган шәһәр, авылларын талап, ганимәт малы җыю Сөннү гаскәренең төп максаты була. Бу мал дистә, йөзлек, меңлек, ун меңлек гаскәр башлыкларына да, гади укчыга да борынгыдан килгән гадәт буенча тигез итеп бүленгән. Менә шуңа күрә дә Кытай императорлары хэцинь сәясәтен куллану файдалырак дип исәпләгән. Сөннү шаньюйлары, үз халкын ач тотмау максатыннан чыгып, Кытайга һөҗүм яки бүләкләр алуны чиратлаштырган. Шулай да сугышларның күбесен Кытай башлаган, кытайлар сөннәрне берни эшләмичә көн күрүче дип санаган, күчмә тормышның авырлыгын да, сөннәрнең югары дала мәдәнияте булуын да алар аңламаган.

Кытайлар сөннәргә каршы дипломатияне дә оста файдалана. Зур хакка сөн яшьләрен Кытай армиясендә хезмәт итәргә чакыралар, аларга уңай шартлар тудыралар, шуңа күрә яшьләрнең күбесе туган иленә кайтмый. Тик хәрби белем алган яшьләрнең билгеле бер өлеше кире кайта, ләкин алар белән махсус әзерлек алып

барыла. Офицер дәрәҗәсе бирелә. Кире кайткан бу яшьләр, Сөнну армиясенә кереп, Кытайга хезмәт итә. Бу чаралар Сөнну армиясенең көчен нык какшата, армия Кытай шымчылары белән тула.

Сөн аксөякләре үз балаларын Кытай уку йортларына җибәрә, укудан соң аларга ватаннарында урын булмый, Сөнну дәүләтенә укымышлы, әзерлекле кешеләр «кирәк булмый». Шулай итеп, сөн яшьләренең белемле өлеше Кытайга хезмәт итә башлый. Кытай хөкүмәте, Сөннугә җибәрү өчен, күп санлы шымчылар әзерли. Бу максат өчен нигездә хатын-кызларны җәлеп итәләр. Махсус әзерлектән соң аларны сөн аксөякләренә кияүгә бирәләр. Өстен катлау сөннәрнең хатыннары гомер буена Кытай мәнфәгатенә хезмәт итә. Кытайдан «качып килгән» махсус кешеләр Сөнну дәүләтенең югары урыннарын били. Бу хәлләр гасырларга сузыла, бигрәк тә б.э.к. II—I гасырларда һәм б.э. ның I гасырында күзәтелә. Шулай итеп, Сөнну җәмгыяте икътисади, рухи һәм хәрби өлкәдә какшатыла, әкренләп кыргыйлана.

Ачлыктан, катгый тәртипләрдән Кытайдан качучылар, һәртөрле җинаятьчеләр, сәяси эмигрантлар сөннәр белән якынаймый, сөннәргә кыен вакытларда Кытай яклы булып кала[40].

Бер үк вакытта Кытай үз күршеләрен Сөннугә каршы котырта, ул карашын көнбатышка юнәлтә. Монда алга ике максат куела: көнбатыш җирләрен басып алу (кытайларның юлында сөннәр тора) һәм сөннәр белән көрәштә союздашлар эзләү, алар ярдәме белән Сөннуне тар-мар итү, соңыннан аларның барысын үзенә буйсындыру.

Хань династиясе урнашканчы, кытайларның географик белемнәре бик чикле була: үз илләреннән башка алар Кореяны гына белгәннәр, Кытайны дөньяның үзәге дип исәпләгәннәр. Союздашлар эзләп, Кытай идарәчеләре Урта Азиядә яшәүче юэчжиләргә Чжан Цянь исемле чиновникны җибәрә. Ул Даванда (Фирганәдә) була, Согдиана аркылы юэчжиләргә килә, аны яхшы кабул итәләр. Кытайга б.э.к. 120 елда әйләнеп кайта. Көнбатыш дөньясы турында белемнәр эзсез калмый: Кытай Парфиягә, Сарматиягә, Месопотамиягә, Һиндстанга, хәтта Римга илчеләр җибәрә[41].

Император Ву-ди (б.э.к. 140—87 еллар) идарә иткән елларда Кытай, Шәркый Төркестанга үзенең экспансиясен көчәйтү һәм Көнбатыш белән өзлексез сәүдә элемтәләре булдыру кебек ике максат куеп, Сөнну белән туктаусыз сугышлар алып бара. Б.э.к. 121, 119, 101, 99 елларда хәрби походлар оештырыла, нәтиҗәдә сөннәр үзләренең ышанычлы авыл хуҗалыгы базасы булган Шәркый Төркестанны югалта. 80 нче елларда сөннәрнең күршеләре — үсүннәр, сяньбиләр һәм динлиннар сөннәрне тар-мар итә. Б.э.к.

104, 103 елларда император У-ди вакытында Кытай Көнбатышка поход оештыра, анда 60 мең сугышчы, азык-төлек белән 100 мең үгез һәм 30 мең ишәк җибәрелә. Кытай гаскәрләре, сугыша-сугыша, сөн җирләре аша уза, Согдиана белән сугыша. Кытайга 10 мең генә сугышчы әйләнеп кайта[42]. Модэ вакытында көчәюгә карамастан, Кытайда бара торган вакыйгалар Сөннүнең сәяси һәм иҗтимагый тормышына көчле йогынты ясый. Б.э.к. I гасыр уртасында борынгы ыруглык строе эчендә колбиләүчек мөнәсәбәтләре үсә, ул җәмгыятьнең таркалуына һәм Сөннүнең җимерелүенә китерә. Монда Кытайның роле зур була. Модэдан соң Сөннү өстен катлавының император сараена таба авышуы сизелә. Кытай, сөн өстен катлавын сатып алу өчен, гаҗәеп актив сәясәт алып бара. Элек сөн ыруг башлыклары, борынгы традициягә тугрылыклы булып, сугышта алынган ганимәт малын ыругдашлары белән бүлешкән булса, хәзер исә алар, Кытай өстен катлавының купшы тормышын күреп, ганимәтнең күп өлешен үзләрендә калдыра һәм ыругдашларын хәерчелеккә дучар итә. Аннан башка Сөн аксөякләре Кытай императорыннан зур бүләкләр ала. Сөн ыруг башлыклары, кытайлардан күреп, сугышта әсирлеккә алынган коллар хезмәтеннән файдалануны киңәйтә, ыругдашларын эксплуатацияләүне көчәйтә. Шулай итеп, сөн өстен катлавы үзенең кармакларын ирекле ыругдашларга юнәлтә.

Сөннүнең өстен катлавы колбиләүчелеккә авыша, ә гади күчмәннәр, Кытайдагы колбиләүчелекнең «яхшылыклары» турында хәбәрдар булып, иске тәртип, ягъни азатлык ягында була. Нәтиҗәдә б.э.к. I гасыр уртасында сөн җәмгыяте тирән кризис кичерә.

Б.э.к. I гасырда Сөннүдә эчке ызгышлар, партияләрнең эчке көрәше башлана, бу вазгыятьтә хәлиткеч рольне Кытай диверсиясе һәм дипломатиясе уйный. Тәхеткә б.э.к. 105 елда килгән Ушилу шаньюй вакытында экренләп Кытай белән килешү яклылар оеша. Кытайның зиннәтле әйберләре белән мавыгу, сугышта алынган малны үзенә алу, исерткеч эчемлекләргә, тәм-томга, аш тәмләткечләргә ияләнү көчәя[43].

Сөннү җәмгыятенең кризисы. Бүленү

Б.э.к. 80 нче еллар башында сөннәрнең бер тармагы булган үсүннәр Кытай ягына чыга, сөн өстен катлавы арасында ызгыш тагын да көчәя. Иске сөн партиясен тәшкил итүче урта катлау илдә хакимиятне үз кулына ала. Бу партия югалтылган барлык җирләрне — Үсүнне, Согдиананы, Ухуаньны, Ордос һәм Иньшаньны кире кайтарырга омтыла. 80, 79, 78 елларда бу җирләргә уңышсыз

походлар оештырыла. 72 елда Сөннүгә кытайлар һөҗүм итә. 72, 71 елларда сөннәр үсүннәргә бәреп керә һәм күп кенә картларны, балаларны үтерә. 71 елда үсүннәр алардан бик нык үч ала. Бер үк вакытта көнчыгыштан Сөннүгә ухуаньнар һөҗүм итә, төньяктан илгә динлиннар бәреп керә. Шул елларда Сөннүдә көчле терлек үләте башлана, һәм көчле ачлык дәһшәтлек итә. Шул вазгыятьтән файдаланып, Сөннүдән барлык буйсындырылган өлкәләр ычкына. Сөнну дәүләте йомшара[44]. Б.э.к. соңгы 50 еллыкта Сөннүне эчке көрәш һәм ызгышлар тагын да йомшарта. Ыруглык җәмгыятенең кыршаулары шартлый, җәмгыятьнең гади әгъзалары үзләренең ыруг башлыкларын тыңлаудан баш тарта, чөнки алар һаман да табышны гадел бүлми, күп өлешен үзләштерәләр. Социаль катлауларга бүленү арта, ыругдашларны турыдан-туры эксплуатацияләү көчәя. Ыруглык строе яклылар һәм аларга каршыларның көрәше сөн җәмгыятен бүленүгә һәм таркалуга китерә.

Б.э.к. 58 елда тәхеткә Хуханье шаньюй утыра. Таркаулану, бүленү һаман дәвам итә. Хуханье көнчыгышка кача. Бераз вакыттан ул, әйләнеп кайтып, көнбатыш сөннәргә һөҗүм итә һәм аларны җиңә. Хуханье илнең тулы хокуклы шаньюйы булып китә, ләкин аның халыкта абруе түбән була. Көнбатыш сөннәр 56 елның ахырында —55 елның башында Хуханьедан аерыла. Хуханьега каршы күтәрелешләр башлана. Баш күтәрүчеләр арасында аның бертуганы Хутуус була, ул үзен шаньюй дип игълан итә, үзенә Чжичжи-гудухи шаньюй дигән исем ала.

Б.э.к. 52 елда Хуханье үзен Кытайның вассалы итеп таный, шуның белән үз ватанына хыянәт итә. Чжичжи кулы астында сөннәрнең күпчелек өлеше кала, ләкин тынычлык яклылар Хуханье ягына чыга. 48 елда тагын 8 ыруг Кытай ягына чыга. Болар ыруглык строе яклылар була. Кытай ягына чыгучылар Көньяк Сөн дәүләтенә нигез салучылар була. Моңарчы бердәм булган сөннәрнең төньяк һәм көньяк сөннәргә бүленүе шулай барлыкка килә[45].

Б.э.к. 52 елда Хуханье Кытай императоры янына килә, аны тантаналы төстә каршы алалар. Кабул итү вакытында Хуханье, исеме дә әйтелмичә, вассал дип күрсәтелә. Аңа баш киеме, билбау, тышкы һәм эчке кием, яшел тасмада алтын мөһер, яшма ташы белән бизәлгән кылыч, хәнҗәр, ук-җәя, утыргычлы арба, ияр, йөгән, 15 ат, 20 цзинь алтын, 200 мең данә тәңкә һ.б. бик күп нәрсәләр бүләк ителә. Үзеннән соң халыкта ватан һәм халык мәнфәгатенә хыянәт итүче исеме калдырып, Хуханье 32 елда үлә[46].

Чжичжи 55 елда үз халкын Тубылга алып китә, аннан соң башкаласын Джунгариягә күчерә. Тиздән ул Кангюй дәүләте башлыгының Үсүн дәүләтенә каршы бергәләп яуга чыгу турындагы

тәкъдимен кабул итә. Ул Кангюйга уңышлы һөҗүм ясарга, аннан соң бергәләп Кытайга каршы чыгарга уйлый. Шул максат белән ул Кангюй идарәчесенең тәкъдимен кабул итә, һәм аның җитәкчелегендә сөннәр б.э.к. 47 елда яуга кузгала. Чжичжига каршы ике Кытай экспедициясе чыга.Тарбагатай калкулыклары һәм Бетпак дала аша узганда, Чжичжи гаскәре көчле буран һәм суыкка дучар була. Күп кеше өшеп үлә, 3000 сугышчы гына исән кала. Чжичжи үзе дә б.э.к. 36 елда һәлак була. Чжичжи көнбатышка киткәч, Хуханье Сөннүнең тулы хокуклы идарәчесе булып кала, ләкин Кытай кулы астында. Чжичжи шаньюй белән килгән төньяк сөннәрнең бер өлеше Тубыл буенда кала, чөнки анда иркен аучылык урыннары, бай көтүлекләр җәйрәп ята.

Б.э.ның I гасырында Көньяк Сөнну чәчәк ата. Төньяк Сөннүдә ватандашлар сугышы башлана. Ул әлегә мөстәкыйль дәүләт була, ләкин Кытайга шактый бәйле кала. Бөтенләй бетерү максатында Кытай аның белән һәртөрле сәүдәне туктата. Әлеге максатны тормышка ашыруда ул үзенең күптәнге дошманы булган сяньбиләрне файдалана. Сяньбиләр элек бердәм этнос булмаган, алар Монголия территориясенә килгән төрле кабилә калдыклары гына. Соңрак алар монгол телен алалар.

Б.э.ның 86 елында Төньяк Сөнну Көньяк Сөннүгә һөҗүм итә. 87 елда Кытайның, сяньбиләрнең һәм динлиннарның берләшкән көчләре Төньяк Сөннүгә каршы сугыш башлый һәм аның җиренә барып керә. Төньяк Сөнну идарәчесе Юлю шаньюйны тотып, тиресен салдыралар. 93 елда сөннәр җиңелә. Бу җиңелү Сөнну дәүләтенең язмышын хәл итә. Төньяк сөннәр тагын бүленә. 200 мең кешене эченә алган 58 ыруг Кытайга күчеп китә һәм буйсына. Хань хөкүмәте, илләрендә калган төньяк сөннәргә каршы көрәштә файдалану максаты белән, аларга урын бирә. Сяньби хөкүмәте дә җиңелеп, илләрендә калган сөннәргә шарт куя: кемнәр Сөнну принципларыннан ваз кичә һәм үзен сяньби дип исәпли башлый, шулар сяньбиләр белән кала ала. 100 мең сөн бу тәкъдимне кабул итә[47].

93 елгы җиңелүдән соң Кытайга да китмәгән, сяньби исемен дә алмаган төньяк сөннәре тагын бүленә. Аларның бер өлеше Тарбагатай, Саура һәм Джунгария Алатавы чикләрендә утырып кала. Төньяк сөннәрнең икенче өлеше 93 елда төньяк-көнбатышка — Бараба далаларына китә. Алар Көнбатыш Себернең урман-далаларына игътибар итә, чөнки көньякта, җылырак булса да, чүл бар, ә бирәдә, салкын булса да, зубрлар, боланнар, кәҗәләр бик күп, урманда ягулык һәм уклар өчен, күчмә өйләр өчен материал тулып ята. Кытайга киткән көньяк сөннәр арасында

ыруглык строе белән риза булмаган яшь сөннәр күп була, алар, беркая да күчмичә, төньякта калган сөннәр янына кире кайта. Барабада һәм күршедә яшәгән угорлар, самоедлар (селькуплар, ненецлар) аларга урын бирә — алар төньякка китә.

Б.э.104 елында Сөннүнең төньягында дәүләт торгызыла. Кытайлар Сөннүдән һәм элек Сөннүгә буйсынган территорияләрдән куыла. Төньяк Сөннү дәүләтенең чикләре Баркул күленнән «Көнбатыш диңгезенә» кадәр, ягъни Каспий, Аралга кадәр сузыла. Төньяк сөннәр Барабага киткән сөннәр белән берләшә. Торгызылган Сөннү дәүләтенә сугышчан угорларның, скифларның, сарматларның калдыклары һәм төрки телле кабиләләр яшәгән Көнбатыш Себер киңлекләре керә, бу Төньяк Сөннүне көчәйтеп җибәрә, ләкин бу процесска яңадан сяньбиләр килеп тыгыла. Алар Сөн-нүгә бертуктаусыз һөҗүмнәр оештыра башлый, бу 101, 110, 117, 118 елларда кабатлана. Сөннәрнең берләштерелгән көчләре бу һөҗүмнәрне кире кайтара. Төньяк Сөннү 155 елга кадәр яши[48].

Сөннү мәмләкәтенең һәлакәте

155 елда сяньби идарәчесе Таншихай сөннәрне ватаннарыннан куа, шуннан соң Төньяк Сөннү дәүләте яшәүдән туктый. Төньяк сөннәр ватаннарын ташлап китә. Китешли алар тагын бүленә. 200 мең сөн Тарбагатай һәм Кара Иртеш бассейнының урманнары һәм тау араларына, Җидесуга килеп утыра. Аларны «аз көчле сөннәр» дип атау гадәткә кергән. III гасырның ахырында алар «Юебань» исемле дәүләт төзи.

Шул ук 155 елда сөннәрнең зур өлеше, бик борынгыдан яшәгән ватаннарын калдырып, көнбатышка таба китә. Алар зур кызулык белән бара. Л. Н. Гумилев, көнбатышка китеп, шул кадәр ерак араларга күчүнең кыенлыгына тик ирләр генә түзә алган, ә хатын-кызлар, балалар һәм картлар Көньяк Себердә калган дип раслый. Аларны «буйсынмас сөннәр» дип атыйлар[49].

155 елда Сяньби дәүләте төзелә. 155—166 елларда сяньбиләр барлык күршеләрен буйсындыра. Бу дәүләтнең чикләре 6,5 мең километргa — Уссуридан Иделгә кадәр сузыла. Таншихай сөннәрне Джунгариядән Тарбагатайга куып чыгара, динлиннарны да куып, ул сяньби-монголларга 400 елга якын далада хакимлек итәргә мөмкинлек тудыра.

Археология материалларына караганда, сяньбиләр чорында Үзәк Азиядә мәдәниятнең түбән төшүе һәм Сөннү дәүләте белән чагыштырганда иҗтимагый регресс күзәтелә. Сөннәр заманында



Сөнну дәүләтенең җимерелүе (б.э.к. 71—61 еллар). Чыганак: *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия, 1993



Үзәк Азия (б.э.к. 30 нчы еллар). Чыганак: *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия, 1993

чәчәк аткан күп санлы шәһәрләр һәм утрак тормыш белән яшәгән торак урыннар бушап кала, аларда тормыш бетә. Һөнәрчелек эше кыскара һәм игенчелек учаклары сүнеп кала. Кытай чыганаклары Сяньби дәүләтенең абруе төшүне күрсәтә. Сөн шаньюйларын алар, Кытай императорларына тиңләп, «Күк улы» дип атый, Сөннү дәүләтен Кытай тарихчылары урта дәүләткә тиңли. Сяньби дәүләтенә мөнәсәбәт бөтенләй үзгәрә. Хәтта Сяньбинең иң куәтле вакытында да Таншихай «вана» (кенәз) титулы белән аталып йөртелә[50].

Шулай итеп, б.э. I—II гасырларында бердәм сөн этносы территория белән берничек тә бәйләнмәгән берничә субэтноска таркала:

1. Берничә агым булып, 48, 54, 85 елларда Төньяк Кытайга киткән көньяк сөннәр. Алар 304 елда восстание күтәрә, Кытай хакимиятеннән котылып, Лю-хань империясе төзиләр. 318 елда ул икегә — Олы Чжао һәм Кече Чжао дәүләтләренә бүленә. 329 елда Кече Чжао Олы Чжаоны һәм барлык Төньяк Кытайны буйсындыра, ләкин 350 елда сөн идарәчесе тарафыннан уллыкка алынган кытай Жань Минь исемле гаскәр башлыгы хакимиятне үз кулына ала һәм Кече Чжаодагы барлык сөннәрне кырып бетерергә әмер бирә. Ордоста яшәүче дала сөннәре һәм аларның икенче бер тармагы Ганьсуда ике Сөн дәүләте төзи: Ордоста — Ся (407—432), Ганьсуда — Хэси (397—439), соңыннан икесен дә Табгачлар империясе — Тоба Вэй басып ала[51].

2. Төньяк сөннәр. Аларның күпчелеге 93 елда Бараба далаларына, Көньяк һәм Көнбатыш Себернең башка регионнарына китә. Аларның күбесе, көч туплап, Үзәк Азиягә кире кайта һәм 104 елда дәүләтләрен торгыза. Ләкин 155 елда илдән куыла, Көнбатыш һәм Көньяк Себергә, Көньяк Уралга, Түбән Идел һәм Түбән Донга китә. Тарихи әдәбиятта алар «буйсынмас сөннәр» дип атала. Угорлар, сабирлар, аланнар һәм башка халыклар арасында яшәп, алар ассимиляцияләнә һәм «һун» исемле халыкка нигез сала[52]. Һуннарның Көньяк Уралдан алып Түбән Донга кадәр далаларда килеп чыгуы турында 158 елда антик географ Дионисий Перигиет язып калдыра. Аннан соң 200 ел буе һуннар турында бер хәбәр дә юк. Борынгы грек тарихчысы Аммиан Марцеллин «Тарих» исемле әсәрендә һун союзы турында хәбәр итә (353—376 еллар)[53].

3. 93 елда Көнбатыш Себергә килгән сөннәрнең һәм «буйсынмас сөннәрнең» бер өлеше, 155 елда көнбатышка күчкәндә, Көнбатыш һәм Көньяк Себердә кала, төрки кабиләләр белән кушылып, җирле угорларның аерым төркемнәрен ассимиляцияли. Алар Себер татарлары бабаларының бер тармагын тәшкил итә[54].

4. Тарбагатай, Джунгария һәм Җидесуга күчеп утырган 200 мең «аз көчле» сөннәр «юебань» дип атала башлый, шулай ук алар төзегән дәүләт тә «Юебань» дип атала. V гасырда теле кабиләләре бу дәүләтне җимерәләр.

5. Үзләренең «сөн» дигән исеменнән баш тартып, «сяньби» исеме алган сөннәр. Бу төркем бердәм булмый. Алар сяньбиләргә кушылмый, алдагы этник процессларда аларның бер өлеше төрки этносының нигезе була.

Шулай итеп, б.э. I гасыры ахырында Үзәк Азиядә сөн чоры тәмамлана, әмма Европа халыкларының һуннар белән бәйле тарихы башлана. Б.э.к. 200 елдан б.э. 150 елына кадәр Кытайның Хань династиясе Сөнну дәүләтен җимерүгә юнәлтелгән үтә дә актив тышкы сәясәт алып бара, һәм бу Сөнну мәмләкәтенең һәлакәте белән тәмамлана. Кытай идарәчеләренең сөннәргә карата алып барган сәүдә сәясәте сөннәр өчен генә түгел, Кытайның хезмәт халкы өчен дә зарарлы була. Бөек Сөн дәүләте таркалганнан соң ук, Кытай шул кадәр зәгыйфьләнә, IV гасырда ук Кытайның төп җирләре күчмә халыклар: төньякка киткән сөннәр, сяньбиләр, кяннар (күчмә Тибет кабиләләре) һәм башка күчмә кабиләләр кулына килеп керә. Монда сәбәп күчмәннәрнең көчәюендә түгел, аларда бернинди көчәю галәмәте булмый. Бу һәлакәтнең төп сәбәбе — Кытай императорларының дөрес булмаган эчке һәм тышкы сәясәтендә. Ил таркаулана, халык кырыла. II гасыр уртасында халык санын алу мәгълүматлары буенча Кытайда 50 миллион кеше яшәгән, III гасыр уртасында анда 7,5 миллион гына кеше кала. Бу таркаулык бик озакка сузыла, тик 300 елдан соң гына Кытай хәлләнә башлый[55]. Сөнну дәүләтенең һәлакәт сәбәпләре турында тарихи әдәбиятта аз язылмады. Алар күптөрле.

Сөннүнең көчсезләнүенә һәм сөннәрнең көнбатышка китүенә глобаль сәбәпләр тәэсире күзәтелә. Тарихи документлар, бу чорда даланың климаты үзгәреп, корылык килү, көтүлекләрнең бозлануы, саранча һөҗүме турында хәбәр итә.

Сөннәрдә элек тә трагик вакыйгалар аз булмаган, ләкин алар ватаннарын ташлап китмәгән. Ни өчен алар 155 елда ватаннарын калдырып китә соң?

Л. Н. Гумилев һәм башка кайбер галимнәр сөннәрнең китүен сяньбиләрдән җиңелү генә түгел дип саный. Б.э. II гасырында климатта гаять зур үзгәрешләр була. Атлантик циклоннар үзләренең көнчыгышка, Евразиянең үзәгенә үтеп керү юлын үзгәртә. Нәтиҗәдә Бөек далада һава салкыная, корылык башлана. Далада явым-төшем күләме елга 150 мм га гына кала. Күп сулы елгалар, күлләр кибә, Арал, Каспий диңгезләре саега, күп үсемлекләр юкка чыга, алар

белән тукланучы җәнлекләр китә. Күп көтүлекләр чүлгә әверелә. Шулай итеп, сөннәр явыз дошманнан гына түгел, үзгәргән климаттан, тормышны кыенлаштырган ландшафттан кача[56].

Даланың хәтта үзенең нормаль климат шартларында да билгеле бер сандагы кешеләр яшәү өчен мөмкинлекләре чикле. Биш кешедән торган бер гаилә ихтыяҗлары өчен 15 атка тәңгәл күләмдә терлек асрарга кирәк (1 ат 5 сыерга тәңгәл, яки 6 сарыкка, 2 яшьлек ат — 0,5 олы атка, колын $^1/_4$ атка тәңгәл). Моннан тыш әле өйне күчереп йөртү, атланып йөрү өчен дә гаиләнең һәр олы кешесенә берәр ат кирәк. Күчмән көне буе аттан төшми. Шуңа күрә ул бер ат кына тота алмый. Шул сәбәпле һәр күчмән, колынлы бия, яшь тайларны исәпкә алмыйча, 10—12 ат тотарга тиеш була. Коры далада үлән азыгы табу мөмкинлекләре бик чикле. Терлекне көтү өчен, кар катламы 30 сантиметрдан артмаска тиеш[57]. III гасырда корылык сәбәпле угорлар һәм самоедлар Обь һәм Енисей буенча төньякка китә.

Һун мәмләкәтенең җәмгыятьтәге төрле көчләр көрәше нәтиҗәсендә бүлгәләнүе дә бу һәлакәтнең төп сәбәпләреннән була. Сөнну дәүләте эченә кергән яки күрше кабиләләрнең көчәюе нәтиҗәсендә этногенетик процессларның артык «җылынуы» да эзсез калмый. Тарихи үсеш, шул исәптән этник үсеш тә тукталып тормый, бер кабиләләр көчәеп китә, икенчеләре ниндидер сәбәпләр аркасында зәгыйфьләнә.

Күчмә тормышка нигезләгән дәүләтләрдә элита геометрик прогрессия буенча арта. Күчмән аристократиянең балалары, оныклары, мирас хокукы нигезендә җир, терлек алып, нәсел байлыгын ваклый, ул нәселнең дәрәҗәсе төшә. Бу социаль стабильлекне какшата. Сөн җәмгыятендә патриархаль-ыруглык мөнәсәбәтләренең артык озакка сузылуы үзенең кире йогынтысын ясый. Патриархаль-ыруглык шартларында, алар җимерелмичә торып, сөн аристократиясенең, Кытай колбиләүчеләре кебек, байлыкка, купшылыкка, зиннәтле әйберләргә хирыслыгы, Кытайдан бүләкләр алуы, Кытайга барып бәйрәм итүләр гади ыругдашларда ризасызлык тудыра, алар ыруг башлыкларын танымый һәм тыңламый башлый, бу хәл иҗтимагый таркаулыкка китерә. Сөннәрне эчүчелеккә тарту һәм Кытай диверсиясенең башка чаралары да эзсез калмый.

Тарихта бернәрсә дә мәңгелек түгел. Евразия далаларындагы күчмә империяләр дә аерым бер тарихи чорларда гына яши. Бу канун Сөнну җәмгыятен дә читләтеп үтми.

Менә шушы сәбәпләр һәм әлегә безгә билгеле булмаган факторлар төркиләрнең беренче озын гомерле дәүләте — Бөек Сөн каһанлыгының җимерелүенә китерә.

Сөннүнең хуҗалыгы һәм рухи мәдәнияте

Сөннәр хуҗалыгының нигезен күчмә терлекчелек тәшкил иткән. Алар ат, мөгезле эре терлек һәм сарык асрыйлар. Терлекне җәй көне көтүлектә, кышын көньяктагы кышлау урыннарында тоталар. Терлекчелек продуктлары мул, ә игенчелек продуктларына ихтыяҗ күзәтелә. Минуса казанлыгында гяньгуньнәр ул заман өчен бик зур сугару системасы булган игенчелек белән шөгыльләнгән. Сөннәр бирердә су җибәрүне үз кулларына ала һәм игенчеләрне икмәкнең төп өлешен дәүләткә тапшырырга мәҗбүр итә[58]. Буйсындырылган кабиләләр генә түгел, сөннәрнең үзләре дә сөрүле игенчелек белән шөгыльләнәләр һәм төп кораллары тимер калаклы сукадан гыйбарәт була. Алар тары һәм арпа игәләр. Ләкин игенчелек әле төп шөгыль булмый. Терлек тоту, дуңгызчылык һәм кошчылык юнәлешләре дә үсә. Коры далалар зонасында һәм тау тезмәләрендә атлар, дөяләр һәм сарык асрыйлар.

Кара металлургия аерым тармак рәвешендә үсеп китә, металл осталары бистәләре барлыкка килә, аларда археологлар йөзәрләгән тимерче күрекләре таба. Ювелирлар аерылып чыга, алар алтыннан һәм көмештән төрле әйберләр эшли. Бик нәфис ювелир инструментлар ясала, андыйларны көнбатышта да, көнчыгышта да белмәгәннәр. Археологлар күп санда ритуаль статуэткалар таба. Чүлмәк ясау җайланмасыннан башка эшләнгән керамик әйберләрнең күплеге шаккатарлык. Л. Р. Кызласов бу чорда сөннәрдә язу булу ихтималы турында яза[59].

Сөннәр күн, мех, киез, тупас йон тукымадан тегелгән кием кигән, өстен катлауның киеме купшы булган. Курганнарда ефәктән һәм нәфис күннән тегелгән кием калдыклары күп очрый. Күн аяк киеме кигәннәр. Курганнарда шулай ук ирләр һәм хатын-кыз җиләннәре, чалбарлар, баш киемнәре табыла. Киемнәр мех, ефәк, тасма һәм чигеш белән бизәлгән. Алар даланың кырыс шартларына яраклашкан һәм уңайлы булган[60].

Сөннәрнең төп ашамлыгы сөт ризыклары була, икенче урында ит тора. Шулай ук игенчелек ризыклары, бигрәк тә тары һәм арпа ярмасы кулланалар. Кырдан җыелган азыклар, бигрәк тә ашарга яраклы тамырларны азык итеп файдаланалар.

Сөннәр физик хезмәт белән шөгыльләнмәгән, аларны коллар башкарган.

Сөннәр күп сугышлар алып барганлыктан, аларда әсирләр дә җитәрлек булган. Әсирләрне коллар итеп файдалансалар да, аларга мөнәсәбәт начар булмаган. Сөннәрдә колбиләүчелек системасы булмый, ләкин коллар була, алар йорт хуҗалыгында авыр эшләрне

башкара: утын җыя, су ташый һәм һәрчак күз алдында була. Аларны терлек көтүдә, ауда, сугышта да файдаланалар. Сөннәрдә бурыч коллыгы һәм коллар сату булмый. Сөн коллары Рим колоннарына охшаш хәлдә яши. Сөн җәмгыятендә әкренләп, ыруглык җәмгыятенең калдыкларын саклап, феодализм традицияләре туа[61].

Сөннәр үз хуҗалыкларын даланың күпме кеше туйдыра алу мөмкинлегеннән чыгып, максатка яраклаштырып алып бара. Тик таза ир кеше генә үзен һәм гаиләсен тәэмин итә алган. Картлар һәм балалардан кала хезмәткә яраксызларны беркем дә туендырып, киендереп тора алмаган. Иҗтимагый әхлак, тормыш кагыйдәләре дала шартларына яраклашкан. Ә бу шартлар бик кырыс булган, далада яшәү катгый шартларга көйләнә. Күчмәннәрнең тормыш-көнкүреше даланың кырыс шартларына бәйле була. Озак елларга сузылган корылык яки кыш көне, кар өстенә яңгыр явып, көтүлекләрнең бозлануы бик зур бәлаләр китереп чыгарган, бу шартларда ачлыктан бик күп терлек һәм кеше һәлак булган.

Лаошань шаньюй идарәсенә кадәр сөннәр салым түләмәгән. Дәүләт җиңелгән һәм буйсындырылган халыклардан кергән мөлкәт хисабына яшәгән. Гади сөннең тормышы күчеп йөрүләрдә (елга 2—4 тапкыр), хәрби күнегүләрдә һәм ялда үткән. Аларның ыругы патриархаль булган[62].

Кыш көне туган баланы карга ташлаганнар, аннан тунга төргәннәр, әгәр исән калса, яхшы сугышчы булыр дигәннәр, үлсә, берәү дә хәсрәтләнмәгән, димәк, ул даланың кырыс шартларына яраклы түгел, бер елдан башкасы туачак. Үсеп җиткәч (сөн карашы буенча), күршеләргә һөҗүмгә җибәргәннәр, әгәр һәлак булса, башкасы үсеп җитәр, мал алып кайтса, киләчәктә ышанычлы сугышчы булыр дип исәпләгәннәр. Бу шартларда буыннар алмашыну тиз барган, чөнки күпләр картайганчы яши алмаган. Бу хәл җитештерү мөнәсәбәтләре үсүгә кире йогынты ясаган, чөнки тормыш тәҗрибәсе булганнар тормыштан иртә киткән[63].

Көньяк Себернең күп этнослы халкы сөн администрациясе тарафыннан хәрби-территориаль принцип буенча дистәләргә, йөзләргә, меңнәргә, ун меңнәргә бүленгән. Һәр бүленешнең башында махсус хәрби башлык торган. Бу система ыруглык җәмгыятенең соңгы калдыкларын какшаткан, сыйнфый җәмгыять туугa һәм иртә феодаль мөнәсәбәтләр үсүгә мөмкинлек биргән.

Тормышның кырыс шартлары, Кытай белән өзлексез сугышлар күчмә сөннәрне көнкүреш һәм яшәү шартларын камилләштерергә

мәҗбүр иткән. Алар киез белән капланган түгәрәк тирмә уйлап таба, аннан бүрәнә кисентеләре куелган (тәгәрмәч урынына) арба барлыкка килә (тәгәрмәч соңрак уйлап табыла). Кытайда моңа охшаган бернәрсә дә булмаган. Алга таба арбаны тирмә белән берләштерәләр, көймәле арба — кибитка ясала. Бу уңайлы «торакка» утырып, ерак аралар үтеп була.

Көньяк Себердә үткәрелгән археологик тикшеренүләр күрсәткәнчә, б.э.к. I гасырда сөн шаньюйлары сарайлар төзетә башлый. Абакан һәм Ташеба елгалары арасында археологлар шундый сарайларның берсен таба. Сарай үзәк залдан, аны урап алган анфилада тәртибендә төзелгән 19 бүлмәдән торган. Ягу идән астыннан була. Тора-бара Урта Азия халыкларында һәм Идел Болгарстанында киң таралган әлеге җылыту системасы борынгы төркиләр (бәлки сөннәрдер) уйлап тапкан казаныш була. Сарай төзелешендә һәм бизәлүендә бернинди Кытай элементлары табылмый[64].

Күчмәннәргә күршеләре — утрак һәм күчмә халыклар цивилизациясе чит булмаган. Сөннәр, һичшиксез, Кытайдан нәрсәдер алганнар, ләкин аны тормышка яраклылык принцибы аша кабул иткәннәр. Гасырлар буенча алар мөстәкыйль булып кала алган, Кытай мәдәнияте һәм Кытай тәртипләре йогынтысына бирелмичә, үз традицияләре буенча яшәгәннәр.

Сөн җәмгыятендә халыкның биштән бер өлешен сугышчылар тәшкил иткән. Сугыш булмаган вакытта алар үз хуҗалыгында эшләгән.

Б.э.к. 2 меңьеллыкта Гобидан төньяктарак яшәүче кабиләләр неолиттан бронза гасырына күчә. Бу кабиләләр берьюлы яши торган берничә мәдәният учагы төзи. Л. Н. Гумилев, С. И. Руденконың археологик тикшерү нәтиҗәләрен башка күрсәткечләр белән чагыштырып, сөннәрнең Гоби аша күчүләре б.э.к. XII гасырда түгел, X гасырда булган дип исәпли.

Кытай тарихчылары Сыма Цянь һәм Бань Гу сөннәр турында тулы ихтирам белән язалар, аларда мәдәният мирасы барлыгы, күршеләр мирасын үзләштерү белән кызыксынулары турында язалар, сөннәрне башка күршеләрдән өстен куялар. Сөн мәдәнияте скиф һәм сармат мәдәниятенә якын тора. Аларны Кытай мәдәнияте дә, Иранныкы да, эллиннарныкы да аз кызыксындырган, ә бу мәдәниятләр аларга таныш булган. Сөн мәдәнияте казанышлары бик борынгы, аларның күбесеннән әле дә бөтен кешелек дөньясы файдалана. Сөннәр чалбар уйлап таба, аннан башка атка атланып йөрү мөмкин түгел. Чалбарны Европага һуннар алып килә, аңарчы анда ирләр дә итәк яки озын күлмәк киеп йөргән.

Сөннәр, тау сыртларын үтү өчен, йөкне ат сыртына салып йөрүне уйлап таба, ат өстендә барган көе дошманга һөҗүм итү өчен, кәкре кылыч, озын сөңге ясыйлар. Укны 700 метрга кадәр ата торган җәя — шулай ук сөннәр табышы. Сөн каберләрендә Кытай фарфоры, Кытай ефәге, парчаның күп табылуы аларның көндәлек тормышында бу әйберләрнең кулланылуына дәлил булып тора.

XIX гасыр ахырында башланган сөн археологиясе Кытай хроникаларының тенденциоз булуын, аларның сөн мәдәниятен түбәнрәк итеп күрсәтергә омтылуын ачыклады. Хәзерге вакытта Байкал артында һәм Монголиядә 3500 сөн кабере табылды, шуларның 500 е казылды. Улан-Батордан 90 км төньяк-көнбатыштагы Ноин-Ула каберлеге — шуларның иң билгелесе. 1925—1926 еллардагы экспедиция вакытында анда сенсацион археологик материаллар табыла. Алар Кытай тарихчыларының Сөннү мәдәниятен бәяләгәндә кимсетүле караштa булуын бөтен дөньяга исбатлады[65]. Яхшы сакланган уникаль табылдыклар 6 курганда була: матур бизәкле келәмнәр, киемнәр, ефәк тукымалар, алтыннан, бронзадан эшләнгән бизәнү әйберләре, көнкүреш кирәк-яраклары. Лаклы бер чынаякта датасы (б.э. 2 елы) һәм урыны да язылган (Шаньлин) [66].

Сөннәрнең үз язулары булу турында да хәбәрләр бар. «Өч патшалыкның тарихы» исемле китапта Фунан иленә (Камбоджаның борынгы исеме) барган Кытай илчелеге әгъзасы Кан Тай исемле кешенең мәгълүматы китерелгән. Ул болай ди: «Фунанлыларның китаплары бар һәм аларны архивларда саклыйлар. Язулары сөннәр язуын хәтерләтә». Фунанлылар Һиндстан алфавитын кулланган. Сөннәрдә язу булу турында Кан Тай, тулы ышанып, абсолют билгеле нәрсә турында сөйләгән кебек сөйли һәм шуның белән сөн язуының Һиндстаннан килеп чыгуын раслый. Кытайларның сөннәргә кимсетеп карауларын да исәпкә алсак, бу мәгълүмат бик әһәмиятле. Сөннү дәүләте Кытай белән дә, Һиндстан белән дә элемтә тоткан. Бу мәгълүматның башка чыганаклар белән расланганын көтәргә кала. Бәлки, аны киләчәктә археологик тикшеренүләр раслар[67].

Көньяк Себердә үткәрелгән археологик тикшерүләр сөннәрнең, утрак игенчеләр һәм һөнәрчеләр яшәү өчен, тораклар һәм шәһәрләр төзегәнен күрсәтә. Сөн идарәчеләренең Җидесуда һәм Ташебада төзелгән сарайлары аларда төзү техникасының югары булуын күрсәтә[68].

Сөннәр Кытай диненә һич тә охшамаган борынгы динне тотканнар. Алар табына торган төп объект галәм була. Фәндә бу

динне «тәңречелек», яки «Тәңре дине»дип атыйлар. Тәңре — сөннәрнең Алласы, ул күк, галәмнең күренә торган өлеше, хуҗа, рух. Тәңречелекнең тамырлары б.э.к. V—IV гасырларга барып тоташа[69]. Сөннәрнең галәмне гәүдәләндерүче потлары булган. Дала күчмәннәре исә табигать белән тыгыз бәйләнгән, алар аны Алла итеп күргән.

Сөннәр рухларга, үлгәннән соң яшәешкә ышанганнар, аны җир тормышының дәвамы дип уйлаганнар. Кабилә башлыкларын, өстен катлау кешеләрен бик зурлап күмгәннәр, аның белән дуслары һәм җарияләре дә үләргә тиеш булган[70]. Сөннәрнең үлгәннән соң яшәүне күзаллавында һәм күмү йолаларында мисырлылар белән уртаклык бар. Шулай да, һичшиксез, сөннәрнең күмү йоласы Мисырныкына караганда күпкә тыйнаграк була.

Б.э.к. II гасырда сөннәрнең бер өлеше, игенчелек һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнеп, утрак тормыш алып бара. Дәүләтнең борынгы җәйге башкаласы Лунчин шәһәре, кышкы башкаласы Дайлин шәһәре була[71]. Сарайларны башкалада гына түгел, башка урыннарда да төзегәннәр. Мәсәлән, Чжичжи шаньюйның сарае Җидесуда булган[72].

Сөннүнең иҗтимагый һәм дәүләт төзелеше

Сөн җәмгыятенең дәүләт төзелгәнчегә кадәр үсешен өйрәнерлек чыганаклар бик аз. В. С. Таскин ул борынгы община җәмгыяте булгандыр дип фаразлый[73].

Сөннәрнең дәүләт идеологиясе шаньюйның бөеклеген бик хөрмәтләгән. Тарихчы Бань Гу язуы буенча, шаньюй титулын йөртүче кеше «Күк кебек олуг» санала. Сөннәр күзаллаганча, шаньюй хакимлеге астында, Күк астындагы кебек, бөтен Җир тора. Шаньюйның бөеклеге Кытай дәүләте белән алып барылган язышу документларында да чагылган. «Сөннүнең Күк һәм Җир тарафыннан тудырылган, Кояш һәм Ай тарафыннан куелган бөек шаньюйы ихтирам белән Хань императорының хәлен сорый». Кытай сарае шаньюйга шундый ук ихтирам белән мөрәҗәгать итә: «Император ихтирам белән Сөннүнең бөек шаньюйы сәламәтлеге турында сорый»[74].

Шаньюйның хакимлеге нәселдән килгән. Тәхет идарә итүче шаньюйның олы улына тиеш була. Бу система бары тик Хуханье шаньюй вакытында гына үзгәрә. Аның барлык уллары өлкәнлек тәртибендә берсе артыннан икенчесе тәхеткә утыра башлый. Шушы яңа кертелгән тәртиптән соң тәхет варисы булуның икеле системасы барлыкка килә. Чыганаклар аерым очракларда сарай низаглары

вакытында тәхеткә утыруның системасы бозылу турында яза. В. С. Таскин Л. Н. Гумилевның: «Нәсел буенча тәхеткә утыру тәртибе бик соң гына гадәткә кергән, хакимият алмашу нигездә васыять аша барган, күбесенчә шаньюй хакимиятне улына тапшырган»,— дигән сүзләре белән килешми[75].

Югары идарәче буларак, шаньюй башка дәүләтләр һәм халыклар белән мөнәсәбәтләр урнаштырган, югары хәрби җитәкче вазифасын да үзе башкарган. Сөнну тормышында, барлык күчмә җәмгыятьләрдәге кебек, сугышлар, басып алулар, талаулар әһәмиятле урын тоткан. Сугышларны уңышлы алып бару өчен, бердәм җитәкчелек кирәк була, моны шаньюй башкара. Кайвакытта шаньюй сугышта катнашмаган, ләкин гомуми җитәкчелек аның кулында була. Мәсәлән, Бань Гу «Хань-шу» исемле әсәрендә шундый эпизодны тасвирлый. Б.э.ның 11 елында Учжило шаньюй Кытай императоры Ван Ман белән мөнәсәбәтләр кискенләшкән чорда: «Уңъяк һәм сулъяк җирләрнең барлык дувэйларына, барлык чик буе кенәзләренә чикнең теге ягына талау һөҗүмнәре ясарга, зур өерләрдә ун меңнән артык, уртачаларында — берничә мең, кечкенәләрендә берничә йөз атлы сугышчы булсын»[76],— дип боера.

Күрше илләргә һөҗүм итү белән бервакытта шаньюй үз территориясен саклау буенча да чаралар күрә. Сыма Цянь «Тарихи язмалар»да шундый эпизодны тасвирлый. Күрше дунху кабиләләре Модэ шаньюйга Сөнну белән Дунху арасында яткан ташландык җирдән бер буйны бүлеп бирүне сорап килә. Модэ якыннары белән киңәшә, кайберләре: «Бу — ташландык җир, аны бирергә дә, бирмәскә дә була»,— дип исәпли. Шаньюй: «Җир — дәүләтнең нигезе, аны читкә биреп буламыни?» — дип җавап бирә. Җирне бирергә киңәш иткәннәрнең барысының да башын кистерә[77].

Чыганаклар язганча, шаньюйлар югары хөкемдар да (судья) булган. Сыма Цянь әсәрендә кайбер хокук нормалары китерелә: «Җиңелрәк җинаять эшләүче таяк белән суктырыла, авыр җинаять ясаучы үлемгә хөкем ителә. Төрмәдә тотуның иң озак вакыты — 10 көн». Күренгәнчә, сөн җәмгыятендә законнар катгый, ләкин гади булган. Нигездә үлем җәзасы һәм таяк кулланылган. Кытайлар сөн законнары гади һәм җиңел башкарыла дип бәяләгәннәр. Шулай итеп, шаньюй югары идарәчегә әверелә, дипломатиядә, хәрби эштә, ил эчендәге мәсьәләләрдә аның сүзе өстен чыга. Шуңа күрә В. С. Таскин Л. Н. Гумилевның: «24 ыруг башлыгы арасында шаньюй беренче генә булган»,— дигән сүзләрен нигезсез дип исәпли[78].

Сөннүнең законнары гади һәм җиңел башкарыла торган булса да, сөн җәмгыятенең сәяси системасы шактый катлаулы була. Моны

раслаучы дәлилләрне без яңадан Сыма Цяньның «Тарихи язмалар»ыннан табабыз. Сул һәм уң сянь-ваннар куела (сянь — акыллы, ван — кенәз). Аннан башкалары билгеләнә: сул һәм уң хәрби җитәкче; сул һәм уң бөек дувэй; сул һәм уң бөек данху; сул һәм уң бөек гудухоу. Шаньюйның өлкән улы туци (акыллы) ван итеп күрсәтелә. Барлыгы 24 җитәкче билгеләнә. Һәрберсе кулында 10 меңгә кадәр атлы сугышчы булган. 24 түрә дә нәселдән килә. Хуян, Лань һәм соңрак барлыкка килгән Сюйбу ыругы дәрәҗәле саналган.

Тарихчы һәм язучы Нурихан Фәттах Сөннүдәге 24 ыруг һәм 24 өлкәне, аларны уңга, сулга бүлүне «24 кә бүлүгә нигезләнгән төрки традициясе» дип атый. Ул уң һәм сулга бүлү нәтиҗәсендә һәрберсендә 12 шәр ыруг килеп чыга дип яза. Борынгы Мисырда Нилның көнчыгышында 12 өлкә була. Мисырлылар беренче булып елны 12 айга бүләләр, тәүлекне икегә бүлеп, 12 сәгатьне табалар. Н. Фәттах борынгы мисырлылар һәм борынгы төркиләр арасында элемтә булу ихтимал дип саный[79].

Сул якның барлык кенәзләре һәм хәрби җитәкчеләре көнчыгышта, ә уң якныкылар көнбатышта яши. Һәркемнең бүлеп бирелгән җир биләмәсе бар, үз җирендә ул үлән һәм су эзләп күчеп йөри. 24 җитәкченең һәрберсе үзе мең, йөз, дистә башлыкларын, вак кенәзләрне, төп ярдәмчеләрне, дувэйларны, данхуларны һәм цезюйларны билгели. Фан Е язуы буенча, ун мең башлыклары шаньюйның уллары яки ир туганнары арасыннан куелган.

Сөнну тормышында бик әһәмиятле урын тоткан бер гадәт турында әйтеп китү кирәк булыр. Елның беренче аенда барлык ыруг башлыклары шаньюй урдасына кече җыенга киләләр, корбан чалалар. (Ел башы көн белән төн тигезләшкән көннән башланган, бу — хәзергечә март ае.) Көз көне, атлар симереп җиткәч, Дайлинда яңадан олы җыенга җыелалар, кеше һәм терлекләрне исәпкә алалар. Шунда ук әһәмиятле дәүләт эшләре тикшерелә һәм күңел ачулар үткәрелә. Бу җыеннар ел фасыллары белән бәйле була[80].

Төркиләрнең сөннәр нигез салган бу борынгы җыен традицияләре заманнан заманга күчеп бара. Татарларның язгы кыр эшләре төгәлләнгәч үткәрелә торган традицион Сабан туена нигез бик борынгы заманнарда, күчмә чорда салынган. Гасырлар узгач кына, бу бәйрәмнәр игенчелек эшләренең еллык циклына, кыр эшләренең башлануына яки тәмамлануына бәйләп үткәрелә башлый. Башта алар игенчелек циклы белән бәйле булмый. Шулай итеп, Сабан туе, кайберәүләр уйлаганча, сабан бәйрәме түгел, аның килеп чыгуы күчмә халыклар традицияләре белән бәйле, Сабан туена һәм Җыенга нигез сөннәр тарафыннан салынган. Утрак тормышка

күчкәч, ул яңа форма һәм эчтәлек белән баетылган. Ат һәм җәяүлеләр чабышы, көрәш, баганага үрмәләү, капчык белән бәрешү һ.б. ярышларның башлангычын рус ярминкәләреннән түгел, ә борынгы күчмә тормыштан, сугыш хәрәкәтләреннән эзләргә кирәк. Татарларда Сабан туе булып формалашкан борынгы уен башка төрки халыкларда ат чабышы, атка атланып кызларны куып тоту, көрәш һәм башка ярышлар формасында үскән. Шаньюй җыйган бу бәйрәмнәргә кабилә башлыклары һәм башка түрәләр бай бүләкләр, соңыннан ясак алып килә торган булган, бу гадәт тә бездә Сабан туе өчен, бөтен кешегә күрсәтеп, шаулап бүләк (бәйге) җыю формасында сакланган.

Ибн Фадлан язганча, хәзәрләрнең хаканы һәр дүрт ай саен үзенең гаскәре белән халык алдына чыккан. Болгарларда да мондый уеннар булмый калмагандыр. Болгардагы данлыклы Ага-Базарда да сәүдә итеп кенә калмаганнардыр. Татарлар яшәгән төбәкләрдә Кызлар тавы, Кызлар убасы дигән урыннар бар, аларданиләр булганы да әлегә өйрәнелмәгән. Рус ярминкәләрендәге уеннарның барысын да борынгыдан русныкы дип карау кирәкмидер, алар күп халыклар мәдәниятен үзләштергән.

Катлаулы сәяси системада яшәгән сөннәрнең җир мөнәсәбәтләре бик гади корылган. Сөннәрнең барлык җирләре шаньюй кулында була. Ул җир биләмәләрен улларына һәм якын туганнарына бирә. Алар да үз нәүбәтендә шуннан үз якыннарына өлеш чыгара. Сөннүнең катлаулы сәяси системасы дәүләт белән идарә итүне камилләштерә, ул сөн җәмгыятенең һәр кешесенә аңлашылган. Кытай императоры сараендагы евнух Чжунхан Юэ: «Дәүләт башлыгы һәм аның кул астындагы кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр гади һәм дәүләт белән идарә итү үз тәнең белән идарә итүгә охшаган»,— ди. Җир алуга хокук җәмгыятьнең барлык кешеләренә билгеле бурычлар йөкли. Бурычның төп формасы, барлык күчмә җәмгыятьләрдәге кебек, хәрби хезмәттән гыйбарәт була.

Ыруг башлыклары шаньюйны тәхеткә күтәрү мәрасимендә катнашкан. Шаньюй янында дәүләт аппараты чиновниклары булган, ләкин безгә аларның хокуклары һәм бурычлары билгеле түгел. Алардан башка шаньюйның ярдәмчеләре дә булган, алар киңәшче вазифасын башкарган.

Сөнну дәүләтенең сәяси системасы көтүлек җирләр милкенә корылган, ул көтүлекләрдән файдалану хокукы формасында була. Күчмә җәмгыятьнең сөннәр тарафыннан салынган сәяси системасы соңыннан барлыкка килгән төрки һәм монгол дәүләтләрендә нигездә саклана. Сәяси системаның күчмә традицияләрен Чыңгыз хан һәм аның варислары саклап кала[81].

Һәлакәттән соң сөннәрнең язмышы. Көньяк сөннәр, Юебань һәм һуннар

Көнбатыш Себернең урман-дала зонасында төрле кабиләләр яши: угорлар, скиф һәм сарматларның калдыклары, сабирлар. Көньяк Себер һәм Урал буе угорлары III гасырда үзләренең берләшмәләрен булдыра, аны Кытай географлары Ун-Бейго (Угор дәүләте) дип йөртә[82]. Ул урманлы зонаның чигенә, чама белән хәзерге Омск шәһәре тирәсенә урнашкан була. Сөннәр 200 ел буе Урал буйларында һәм Көнбатыш Себердә угорлар һәм Көнбатыш Себернең башка кабиләләре белән күрше яши. Күп галимнәр фаразлаганча, скиф һәм сармат берлекләре эчендә төрки кабиләләр аз булмаган. Шул кабиләләр белән бергә яшәп һәм ассимиляциягә кереп, сөннәрдән һуннар барлыкка килә. Европага сөннәр түгел, һуннар килә. Алар үзләренең төрки телләрен саклап кала. Сөнакацирлар сарагур һәм оногур кабиләләре белән кушыла, һәм болгарлар барлыкка килә. Ганьсуда яшәгән сөннәр Ашина ыругы варислары составына кушыла[83].

«Юебань» исемле Сөн дәүләте турында язганда, Кытай тарихчылары андагы сөннәр санын 200 мең дип күрсәтә: «Гадәтләре һәм телләре гаогюйларныкы (ягъни төркиләрнеке) кебек, ләкин чәчләрен пөхтәрәк итеп кисәләр һәм кашларына клей сылап буйыйлар, ул ялтырап тора. Һәркөн өч мәртәбә юыналар, юынгач кына ашарга утыралар»[84]. Юебань дәүләте V гасырның 80 нче елларына кадәр яши. Аның мөстәкыйльлеген телеутлар җимерә. Ләкин 495—496 елларда телеутларны эфталитлар яулап ала һәм 547 елда түркүтләр буйсындыра. Үзләрен буйсындырган кабиләләрнең тиз алмашынып торуы Юебань сөннәренә сакланып калырга мөмкинлек бирә. Соңыннан алардан 4 кабилә: чуюе, чуме, чумугунь һәм чубань кабиләләре барлыкка килә, бу кабиләләр Бөек Төрки каһанлыгы яшәгән чорда гаять зур роль уйный — алар төрки-шато һәм кимәкләр составына керә. VI гасырда этнос буларак сөннәр инде беркайда да булмый, ләкин алар башка төрки кабиләләр булып яшәүләрен дәвам итә[85].

Көньякка киткән сөннәр кытайларга бәйлелеккә төшә һәм Кытай тотыкларына әверелә. Аларга Кытай йогынтысына эләккән үз кенәзләре хыянәт итә. Көньяк сөн җәмгыяте җитәкчесез кала. 407 елда Хэлом Бобо Ордоста «Ся» исемле сөн дәүләте төзи. 400 елда Мэн Су хәзерге Ганьсу провинциясе территориясендә Хэси кенәзлеге төзи. Ике сөн дәүләте дә озак яшәми — Сяны 431 елда һәм Хэсины 460 елда табгачлар яулап ала. Көньяк сөннәр Европа һуннары белән бер үк елда һәлак була. Бу гади туры килү генә булмаска мөмкин[86].

Чыганаклар күрсәтүе буенча, Европага омтылган һуннар бөтенләй башка халык булган. Алар IV гасыр уртасында аланнарга һөҗүм итә, аларның бер өлеше Кавказга китә, калганнары һуннарга кушыла. Буйсындырылган халыкларны үзләре белән алып китеп, һуннар Донны кичә, көнчыгыш герман кабиләсе булган готларга һөҗүм итә. Алар Доннан Карпатка һәм Түбән Дунайга кадәр арада үз хакимиятен урнаштыра. Европа һуннарының тарихын тирәнтен белүче И. П. Засецкая, һуннарның 370 елдагы һөҗүме Төньяк Кара диңгез буйларында фарсы телле халыкларның хакимлеген туктатты һәм көнчыгыш төрки телле халыкларына юл ачты, дип яза. Һуннарның басып алуы җирле халыкны күпләп кыру белән бергә алып барыла. Исән калганнары буйсындырыла. Бу вакыйгалар нәтиҗәсендә Төньяк Кара диңгез буе далаларында һуннар җитәкчелегендә VI гасыр ахырында күчмә кабиләләр берләшмәсе төзелә һәм, 454 елда Аттила державасы таркалганчы, ул Көнчыгыш Европада иң куәтле сәяси берләшмә булып кала. Европа һуннарының тарихын И.П.Засецкая 4 чорга бүлеп карый: 1 — һуннарның Көнчыгыш Европа далаларына һөҗүме (370—378); 2 — шунда кабиләләрнең Һун берләшмәсе төзелү (378—445); 3 — Паннониядә Аттила державасы төзелү (445—454); 4 — Һун кабилә берләшмәсенең таркалуы (454—V гасырның икенче яртысы) [87].

Күп санлы булулары һәм гайрәтле һөҗүмнәре белән һуннар халыкларда курку тудыра. Юнаннарга һәм римлыларга аларның кыяфәте, тәбәнәк, киң җилкәле бәдәне, сөякчел, сакалсыз йөзе, иләнмәгән тиредән эшләнгән тупас киеме ошамый. Һуннар дошманга тупланган саф белән түгел, таркалып, чәчелеп, һәрьяктан һөҗүм итә, кинәт кенә кире чигенә дә тагын һөҗүмгә күчә. Дошманны аркан ыргытып аулый, кәкре кылыч белән турый[88].

Әлбәттә, һуннар турында византиялеләр дошман күзлегеннән карап яза, ә бу позиция еш кына ялгыш картина бирә. Сыма Цянь, сөннәрне Кытайның дошманнары дип санаса да, аларга ихтирам белән карый һәм цивилизацияле халык дип саный. Ә Византия авторлары алар турында чи ит ашаучы, кайнар ризыкны белмәүче кыргый халык итеп яза. IV гасырның 70 нче елларында һуннарның көнбатышка гомум хәрәкәте башлана, алар Иделне кичә, Төньяк Кавказ аланнарын буйсындыра, Баламбер җитәкчелегендә Донны үтә һәм 375 елда Кара диңгез буенда готларны тар-мар итә һәм, остготларның күпчелеген буйсындырып, вестготларны Фракиягә чигенергә мәҗбүр итә. Һуннарның хәрәкәте халыкларның Бөек күчешенә сәбәп була, ә ул Европада, бигрәк тә Рим империясе территориясеннән гомуми этник күченү була. 394—395 елларда һуннар Кавказ аша уза, Сүрия, Каппадокияне талап, Панно-



IV гасырда Көнчыгыш Европага һуннар һөҗүме. Чыганак: История татар с древнейших времен, 2002

ниядә туктала, аннан Көнчыгыш Рим империясенә һөҗүмнәр оештыра[89].

Ә. Г. Мөхәммәдиев Көнбатыш Һун дәүләте көнчыгыштан көнбатышка ниндидер «һөҗүм» вакытында төзелмәде, ә даими рәвештә, Модэ заманыннан башлап, сөннәрнең хәзәр, авар, болгар, барсил, искил, сувар һ.б. кабиләләрне берләштерү нәтиҗәсендә барлыкка килде дип саный. Һөҗүмгә сәләтле Сөн дәүләте б.э.ның I гасырында яшәүдән туктый.

Бу вакыйгалардан соң 350 ел үткәч,V гасыр уртасында (Аттила идарә иткән елларда) көнбатышта үз составына халыкара планда «Скифия» һәм «Германика» исемнәре астында билгеле герман кабиләләрен алган зур һәм куәтле Һун дәүләте төзелә. Һун дәүләте төзелгәч, Кара диңгез һәм Кавказ тирәсендә яшәүче күп кабиләләр, шул исәптән болгарлар, суварлар «һун» дип атала башлый. Көнбатыш чыганаклары күрсәткәнчә, ул кыргый дәүләт түгел, ә рун язуы куллана торган, югары үсешкә ирешкән дәүләт булган. Һун дәүләтенең барлыкка килүе Көнбатыш Рим һәм Көнчыгыш Рим (Византия) колбиләүчеләре өчен көтелмәгән хәл була. Һуннарның Төньяк Кавказдагы тарихын тикшерүче Л. Б. Гмыря, археологик тикшеренүләр һуннарның торулыкларны тоташтан җимереп килүе, зур мәйданнарның буш калуы турындагы тарихи әдәбият язмаларын расламады, дип кистереп яза. Киресенчә, V—VII гасыр катламнары бу регионда икътисадның һәм рухи мәдәниятнең үсүен раславы хакында әйтә[90].

IV гасыр тарихчысы Аммиан Марцеллин «Гамәлләр» әсәрендә, сарай язучысы буларак, аларга, һич дөреслеккә туры килмәгән кыргыйлык ябыштырып, яла яга. Иң әһәмиятлесе шунда: ул һуннарны кыргый итеп күрсәткән мәгълүматларны Геродотның 1000 ел элек кыргый скиф кабиләсен тасвирлавыннан күчереп яза. Геродот язуы буенча, ул кабилә ияр өстенә салып, атлы сугышчы астында йөртелгән чи ит ашый[91]. Россиянең югары уку йортлары өчен чыгарылган дәреслек һәм хрестоматияләрдә, дип яза Ә. Г. Мөхәммәдиев, кызганыч, Аммиан Марцеллинның бу уйлап чыгару һәм ялганнарына күп урын бирелгән. Ә галим һәм язучы, Византия илчелегендә катнашучы Приск Панийскийның кызыклы һәм әһәмиятле мәгълүматлары бөтенләй кертелмәгән[92]. Һуннар арасында озак яшәгән Приск Панийскийның аларның гореф-гадәтләре, әхлагы, киеме, кораллары һәм бизәнү әйберләре турындагы язмалары Аммиан Марцеллин уйдырмаларының дөреслеккә һич якын килмәвен күрсәтә[93].

Көнбатыш Рим империясе һәм һуннар V гасыр уртасына кадәр союздашлар булганнар. Һуннар, готларны, остготларны,

герулларны, гепидларны һ.б. кабиләләрне берләштереп, куәтле кабиләләр берлеге төзи, бу берлекнең иң куәтле чоры Аттила заманына (434—453 еллар) туры килә. Һуннар Аттила җитәкчелегендә 451 елда Галлиягә үтеп керә, ләкин ике яктан 500 мең сугышчы катнашкан, Каталун кырларында (Франциянең төньяк-көнчыгышында) узган сугышта Рим һәм вестготлар гаскәрләре тарафыннан тар-мар ителә. 453 елда, Аттила үлгәннән соң, алар уңышсыз сугыш хәрәкәтләре алып бара һәм соңыннан халык буларак юкка чыга.

Һуннарның Европага һөҗүме 410 елда вестготларның Римны алуы һәм талавы, коллар восстаниесе нәтиҗәсендә Рим империясенең җимерелүенә китерә. Европада колбиләүчелек җәмгыяте бетә[94].

Сөн-сармат үзара мөнәсәбәтләре мәсьәләсе әле өйрәнелмәгән килеш кала бирә. Б.э.к. III гасырдан башлап, 700 ел буена сөннәр һәм сарматлар күрше була, алар тарихи үсешнең бертигез баскычында тора, телләре дә бер була, аларның симбиозы булу бик ихтимал.

Сөннәр тарихы, беренче чиратта, Үзәк Азия белән бәйләнгән, шуннан алар Европага китә. Сөннәр тарихы Кытай тарихы белән нык бәйләнгән. Ә һуннар тарихы Европа тарихы белән бәйләнгән.

XVIII гасырда Көнбатыш миссионерлары Кытай тарихын өйрәнгәндә, берничә сорау калкып чыга: сөннәр кемнәр алар, аларның теле нинди булган? Һуннарның сөннәргә мөнәсәбәте ничегрәк? Сөннәр һәм һуннар мәсьәләсе фәнни бәхәс тудыра. Шулай ук борынгы Азиянең башка кабиләләренең дә этник чыгышы әле дә бәхәсле кала. Тарихта шундый бер үзенчәлек бар: җиңүче кабилә яки ыругның исеме җиңелгән барлык халыкларга күчә. Сөн кабиләләре җиңә икән, бар да сөн була, сяньби кабиләсе җиңсә, бар да сяньбигә әверелә. Шуңа күрә күчмә халыкларның атамаларында үзгәрешләр еш булып тора, Азия кабиләләренең этник чыгышын билгеләгәндә, буталыш китереп чыгара. Мәсәлән, борынгы татарларның этник чыгышын билгеләүдә дә буталышлар аз түгел, бу турыда Кытай, фарсы һәм гарәп авторлары күп язды.

Сөннү тарихын өйрәнүнең төрле чорында сөннәрнең этник чыгышын төрлечә аңлатучылар үзара көрәшә: берәүләр аларны монгол чыгышлы ди, икенчеләр — төрки, өченчеләр фин-угор яки славян чыгышлы диләр.

К. Иностранцев, күп чыганакларны һәм француз галимнәренең хезмәтләрен җентекләп өйрәгәннән соң, сөннәр көчәеп киткән төрки ыругтан барлыкка килгән, дигән нәтиҗә ясый. Европага күчкәндә, сөннәр башка кабиләләр, беренче нәүбәттә фин кабилә-

ләре белән очраша, аннан соң аларга славян һәм герман кабиләләре ияրә, барган саен аларда төркилек сыегая, дип яза. Модэ һәм Аттила ватандашлары арасында гомумилек бик аз булуы бик ихтимал, дигән фикер белдерә. Шулай да ул һуннарның төрки телле булуларына шикләнми[95].

Әйткәнебезчә, кайбер галимнәр «сөн» һәм «һун» бер үк атаманың Азиячә һәм Европача әйтелеше дип исәпли. Сөннәр һәм һуннар проблемасын өйрәнүгә бик күп хезмәтләрен багышлаган Л. Н. Гумилев әлеге халыкларның төрки телле булуы турында нәтиҗә ясый. Ул һуннарның башка кабиләләр, бигрәк тә угорлар тарафыннан көчле ассимиляцияләнгән булуын таный. Бу юлларның авторы Л. Н. Гумилев фикерләре белән тулысынча килешә һәм, көчле ассимиляциягә карамастан, һуннар үзләренең төрки телләрен саклаган дип саный.

* * *

Өйрәнелгән материалларга таянып, кыскача йомгаклар ясарга мөмкин. Сөннәр Бөек даланың борынгы төрки телле кабиләсе булган. Б.э.дан күп элек үк сөннәр белән янәшәдә төрки телле башка халыклар яши: динлиннар, гяньгуньнәр, канглылар һ. б. Киләчәктә сөннәр берничә төрки халык ясалуга нигез була. Көнбатыш Себергә килгәч, сөннәр фәкать угорлар белән генә түгел, анда скифлардан, сарматлардан калган төрки телле кабиләләр белән дә очраша. Көнбатыш Себергә кайбер төрки телле кабиләләрнең сөннәргә кадәр килүе турындагы фаразлар да кире кагылмый.

Һуннар сөннәрнең варислары булган. Алар угорлар һәм башка кабиләләр, бигрәк тә төрки телле кабиләләр белән ассимиляцияләшкәннәр, үзләренең төрки телләрен саклап калганнар.

Сөн чоры — гомумтөрки тарихының иң озын чоры. Искә төшерик: Кытай риваятьләрендә Ся династиясенең б.э.к. 2600 елда сөннәргә каршы сугышка чыгуы турында сөйләнә. Кытай тарихы сөннәрнең б.э.к. 2357 елга кадәр Ордоста яшәвен күрсәтә. Кытай елъязмасы сөннәр турында б.э.к. XVIII гасырда тагын искә ала. 1200 елда сөннәр Гоби аша чыга. Кытай хроникасы сөннәр турында тагын 882 һәм 304 елларда яза. Чыганаклар б.э.к. IV гасырда Сөнну дәүләте төзелүне ышанычлы итеп раслый. 209 елда властьны Модэ үз кулына ала. Б.э. 93 елында Сөнну сяньбиләр һәм күршеләре тарафыннан җиңелә, ләкин 104 елда Сөнну дәүләте, яңадан торгызылып, 155 елга кадәр сяньби идарәчесе Таншихай сөннәрне ватаннарыннан куганчы яши.

Ләкин ватаннарыннан куылгач та, сөннәр югалмый, шулай ук үз дәүләтләрен төзиләр. Европага киткән һуннар дәүләте 451 елга

кадәр яши. Көньякка киткән сөннәр дә үз дәүләтен төзи. 304 елда «Лю-хань» исемле сөн дәүләте, 407—432 елларда Ордоста «Ся» исемле сөн дәүләте, 397—439 елларда Ганьсуда «Хэси» исемле сөн дәүләте төзелә. «Аз көчле сөннәр» тарафыннан төзелгән Юебань дәүләте V гасырның 80 нче елларына кадәр яши. Шулай итеп, сөннәр тарихы безгә 3000 ел дәвамында — б.э.к. 2600 елдан б.э. V гасырына кадәр билгеле.

Сөнну дәүләтенең әһәмияте, беренче чиратта, шунда: сөннәр, үз дәүләтләрен төзеп, күп гасырлар буе үз мөстәкыйльлекләрен саклап килә. Гоби аша кичеп, алар аңарчы бер-берсенә билгеле булмаган ике дөньяны — Кытай һәм Себерне тоташтыра, әмма Себергә кытайларны кертмичә саклап кала.

Сөн хуҗалыгы нигезен күчмә терлекчелек тәшкил иткән, шулай ук Сөннудә игенчелек, утрак һәм ярымутрак терлекчелек тә үскән. Тимер, кыйммәтле металлар чыгару һәм алардан төрле әйберләр эшләү киң таралган. Бөек Сөн каһанлыгында борынгы төрки мәдәнияте нигезләре салына, һәм ул шактый нык үсешкә ирешә. Сөннәргә күрше дәүләтләрнең — Кытайның, Иранның һ.б. мәдәниятләре чит булмаган, ләкин аларга скиф-сармат мәдәнияте якынрак торган.

Сөннәрнең җисми һәм рухи мәдәнияте казанышлары Азия һәм Европа халыклары мирасы булып китә. Ат җигеп һәм атланып йөрү гадәтен, уңайлы кием (чалбар, җилән, бүрек, итек һ.б.), хәрби коралларның кайбер төрләрен алар сөннәрдән ала. Арбага куелган киез өйне сөннәрдән барлык төркиләр мирас итеп ала.

Сөннәр төрки дәүләтчелегенең нигезен сала. Ул кырыс дала шартларында яшәү таләпләреннән чыгып барлыкка килә. Сөн шаньюйлары Кытай идарәчеләренең тәҗрибәсен дә куллана.

Бөек Сөнну дәүләте борынгы төрки дәүләтләре арасында иң озын гомерлесе була — ул биш гасырдан артык яши. Шул ук вакытта Сөн дәүләтенең һәм җәмгыятенең тискәре яклары да була: ыруглык җәмгыяте озак саклана, үзәк хакимият йомшак була, өстен катлаулар күбесенчә зиннәтле әйберләр белән мавыга, күрше кабиләләрне басып алалар һәм буйсындыралар. Шул сәбәпләр һәм Кытайның агрессив хәрәкәте Сөннүнең һәлакәтенә китерә.

Бөек Сөн каһанлыгы составында сөннәр генә түгел, анда күп төрле төрки телле халыкларның бабалары яши һәм үзләренең җисми һәм рухи мәдәниятен үстерә. Шуңа күрә Бөек Сөн каһанлыгы һәм башка сөн дәүләтләре җимерелгәннән соң, борынгы төркиләр тарихында трагик чор башлана, ул Бөек Төрки каһанлыгы төзелгәнче дәвам итә.

[1] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 7.

[2] *Артамонов М. И.* К вопросу о происхождении скифов // Вестник древней истории.— 1950.— № 2.— С. 161; *Гумилев Л. Н.* Ритмы Евразии.— М., 1993.— С. 320.

[3] *Гумилев Л. Н.* Сочинения. Т. 9. История народа хунну.— М., 1997.— С. 363.

[4] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I—II.— М.; Л., 1950.— С. 142—143.

[5] *Кляшторный С. Г.* Гунны на Востоке // История татар в VII томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности.— Казань, 2002.— С. 125.

[6] *Иностранцев К.* Хунну и гунны // Труды туркологического семинария. Вып. 1.— Л., 1926.— С. 57.

[7] *Бичурин Н. Я.* (*Иакинф*). Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I—II.— М.; Л., 1950.— С. 50.

[8] *Берг Л. С.* Путешествия Н. М. Пржевальского.— М.; Л., 1952.— С. 20.

[9] *Гумилев Л. Н.* Роль климатических колебаний в истории народов степной зоны Евразии // История СССР.— 1967.— № 1.— С. 53.

[10] *Васильев В. П.* Об отношениях китайского языка к среднеазиатским // Журнал Министерства народного просвещения, 1872.

[11] *Иностранцев К.* Күрсәтелгән хезмәт, 52 б.

[12] *Иностранцев К.* Күрсәтелгән хезмәт, 11 б.

[13] *Мөхәммәдиев Ә. Г.* Һуннар һәм Туран язмалары.— Казан, 2000.— 7—8 б.

[14] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 20.

[15] *Фәттах Н. С.* Сызгыра торган уклар.— Казан, 1991.— 755 б.

[16] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 25.

[17] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 40 б.

[18] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 2.— М., 1973.— С. 151.

[19] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 79.

[20] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I. Ч. 1.— Л., 1926.— С. 15, 16, 470.

[21] *Дебец Г. Ф.* Палеоантропология СССР.— М.; Л., 1948.— С. 31.

[22] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т.II.— Л., 1926.— С. 15.

[23] *Гумилев Л. Н.* Конец и вновь начало.— СПб.,— 2002.— С. 288.

[24] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. I.— М., 1968.— С. 38—41.

[25] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 2.— М., 1973.— С. 5.

[26] *Захаров И.* Историческое обозрение народонаселения Китая // Труды членов русской духовной миссии в Пекине. Т. I.— СПб., 1852.— С. 270—281.

[27] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 2.— М., 1973.— С. 5.

[28] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I—II.— М.; Л., 1950.— С. 60.

[29] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 76 б.

[30] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М.; Л., 1950.— С. 95—96.

[31] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II.— Л., 1926.— С. 45.

[32] *Томсон Дж. О.* История древней географии.— М., 1953.— С. 439.

[33] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т.II.— Л., 1926.— С. 15.

[34] *Фань Вэнь-лань.* Древняя история Китая от первобытно-общинного строя до образования централизованного феодального государства. Т. I.— М., 1958.— С. 239.

[35] *Крадин Н. Н.* Современные проблемы хуннологии // *Гумилев Л. Н.* История народа хунну. Соч. Т. I.— М., 1997.— С. 425.

[36] *Крадин Н. Н.* Империя Хунну.— Владивосток, 1996.— С. 28 — 34.

[37] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 47—48.

[38] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 76, 78 б.

[39] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 2.— М., 1973.— С. 22.

[40] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 78, 95 б.

[41] *Томсон Дж. О.* История древней географии.— М., 1953.— С. 427.

[42] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 72 б.

[43] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 103.

[44] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 83 б.

[45] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. III.— М.; Л., 1953.

[46] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. 2.— М., 1973.— С. 35.

[47] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 151 б.

[48] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 242.

[49] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 81.

[50] *Таскин В. С.* Материалы по истории древних кочевых народов группы дунху.— М., 1984.

[51] *Гумилев Л. Н.* Күрсәтелгән хезмәт, 200, 201 б.; БСЭ. 3 изд.— М., 1978.— С. 424.

[52] *Гумилев Л. Н.* Күрсәтелгән хезмәт, 200—203 б.

[53] *Дионисий.* Описание населенной земли / Пер. И. П. Цветкова // Вестник древней истории.— 1949.— № 4; *Аммиан Марцеллин.* История/ Пер. Ю. А. Кулаковского.— Киев, 1908.

[54] *Головнев А. В.* Сибирские татары. Проблемы // Тюменская правда.— 1989.— 13 апр.

[55] *Гумилев Л. Н.* Сочинения. Т. 9. История народа хунну.— М.; 1997.— С. 287.

[56] *Гумилев. Л. Н.* Гетерохронность увлажнения Евразии в средние века // Вестник Ленинградского ун-та.—1966.— № 18.

[57] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 117.

[58] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Изд. Красноярского ун-та, 1992.— С. 18, 19.

[59] *Кызласов Л. Р.* Таштыкская эпоха в истории Хакасо-Минусинской котловины.— М., 1960; *Сунчугашев Я. И.* Древняя металлургия Хакасии. Эпоха Железа.— Новосибирск, 1979.— С. 66—69.

[60] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Изд. Красноярского ун-та, 1992.— С. 21.

[61] *Гумилев Л. Н.* Күрсәтелгән хезмәт, 27 б.

[62] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т.I—II.— Л., 1950.— С. 40.

[63] *Гумилев Л. Н.* Хунны в Китае.— СПб., 1994.— С. 11.

[64] *Давыдова А. В.* Иволгинский комплекс — памятник хунну в Забайкалье.— Л., 1985.

[65] Краткие отчеты экспедиции по исследованию Северной Монголии в связи с Монгольско-Тибетской экспедицией П. К. Козлова.— Л., 1925; *Руденко С. И.* Культура хуннов и Ноинулинские курганы.— М.; Л., 1962.

[66] *Бернштам А. Н.* Очерк истории хуннов.— Л., 1951.— С. 37—38.

[67] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 79.

[68] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Изд. Красноярского ун-та, 1992.— С. 49.

[69] *Безертинов Р. Н.* Тенгрианство — религия тюрков и монголов.— Набережные Челны. Б.г.— С. 6.

[70] *Дэн Чжи-чэн.* История Китая на протяжении двух тысяч лет // Реферативный сборник. —1956.— № 13.— С. 134.

[71] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М., 1950.— С. 76, 83, 106.

[72] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. I.— М., 1968.— С. 34, 126, 128, 131.

[73] Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып.2.— М., 1973.— С. 5.

[74] Күрсәтелгән хезмәт, 7 б.

[75] Күрсәтелгән хезмәт, 8 б.

[76] Күрсәтелгән хезмәт, 10 б.

[77] Күрсәтелгән хезмәт, 10 б.

[78] Күрсәтелгән хезмәт, 11 б.

[79] *Фәттах Н. С.* Сызгыра торган уклар.— Казан, 1991.— 3—17 б.

[80] Материалы по истории сюнну...— С. 73.

[81] Материалы по истории сюнну...— С. 16, 17.

[82] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах... Т. III.— М., 1953. Примечания, карта 3 (время Сань-го).

[83] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 101.

[84] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах... Т. II.— М.; Л., 1950.— С. 267—295.

[85] *Гумилев Л. Н.* Хунны в Китае. Три века войны Китая со степными народами. III—IVв — СПб., 1994.— С. 202.

[86] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 88.

[87] *Засецкая И. П.* Культура кочевников южнорусских степей в гуннскую эпоху (конец IV—V в.).— СПб., 1994.— С. 5, 132.

[88] *Виппер Р. Ю.* Последний век империи // *Гумилев Л. Н.* Сочинения. Т. 9. История народа хунну. —М., 1997.— С. 410.

[89] *Евсевий Иероним.* Письмо 77. К океану. О смерти Фабиолы. Письмо 60. К Гелиодору / Пер. В. В. Латышева // Вестник древней истории.— 1949.— № 4.

[90] *Гмыря Л. Б.* Страна гуннов у каспийских ворот.— Махачкала, 1995.

[91] *Мөхәммәдиев Ә. Г.* Һуннар һәм Туран язмалары.— Казан, 2000.— 22 б.

[92] *Мөхәммәдиев Ә. Г.* Күрсәтелгән хезмәт, 25 б.

[93] *Латышев В. В.* Известия древних писателей греческих и латинских о Скифии и Кавказе. Ч. I—II.— СПб., 1904—1906.

[94] *Гумилев Л. Н.* Хунну // Степная трилогия.— СПб., 1993.— С. 209; БСЭ. 3-е изд. Т. VII.— М., 1972.— С. 450.

[95] *Иностранцев К.* Хунну и гунны.— Л., 1926.— С. 119.

III бүлек

БӨЕК ТӨРКИ КАҺАНЛЫГЫ

Борынгы төркиләр

II—III гасырларда Бөек даланың көнчыгыш өлешендә корылык дәвам итә. II гасырда аннан сөннәр китә. III гасырда ул бушап кала диярлек. Аның халкы үсеп баручы чүл читләренә урнаша. 326 елда, даланы ташлап, табгачлар көньякка күчә. Ләкин IV гасырда климат үзгәрә — далага океан муссоннары шифалы дымлы һава китерә, дала тиз арада яшәрә башлый. Далага үлән ашаучы хайваннар, алар артыннан кыргый җәнлекләр әйләнеп кайта. Кешеләр дә кайта башлый — болар Кытайда тар-мар ителгән сяньби һәм сөн кабиләләренең калдыклары, теле һәм жужаннар була.

Б.э.к. III гасырда теле дигән кабиләләр Ордостан көнбатыштарак далада яшиләр. Суй династиясе (581—618 еллар) һәм Тан династиясе (618—917 еллар) елъязмаларында «теле» термины белән хәзерге Монголия, Тыва, Алтай территориясендә күчеп йөргән күп санлы кабиләләр аталып йөртелгән. VI гасыр урталарында теле группасы 12 төрки кабилә конфедерациясен тәшкил итә. Бу кабиләләр: курыканнар (якутларның бабалары), теленгитлар, уйгырлар, сеяньто, вэйхо һ.б. Алга таба теле кабиләләре «телеут» исеме белән йөри башлый[1].

Төрки телле халыклар тирәсендә башка кабиләләр дә яшәгән, алар арасында жужаннар кансызлыклары белән аерылып тора, алар телеутларга да, сөннәр калдыкларына да куркыныч була. Әле сөн чорында ук далада Кытайдан качкан җинаятьчеләр төркемнәре яшәгән, бу кешеләргә Кытайда үлем җәзасы тиеш булган. Уртак борынгы бабалары булмаган бу төркемнәр дала «диңгезендә» төрле телле, төрле кабиләле юлбасарлар була. Тора-бара монгол теленә күчәләр. Жужаннар бөтен Халха буйлап Хинганга кадәр күчеп йөри. Аларның көнкүреше һәм җәмгыять төзелеше бик примитив була. 200 ел яшәү чорында жужаннар арасында алга китеш күзәтелми. V гасырда Жужан дәүләте далада Хинганнан Алтайга кадәрге җирләрдә хакимлек итә.

Чыңгыз Айтматов үзенең повестенда («И дольше века длится день») манкортлар турында риваять китерә. Жуанжуаннар (жужаннарның икенче исеме), янәсе, үз әсирләренең башына дөянең балтырыннан яңа тунап алынган тире кисәге кидерәләр, ул кояшта кибеп кечерәя, баш сөяген кысып, мине зәгыйфьли. Чәч кире борылып, баш тиресе эченә кереп үсә. Моңа дучар булган кешенең чыдый алмаслык булып башы авырта, ул хәтерен югалта, ләкин сүз тыңлаучан булып кала. Жуанжуаннар аларны манкортлар дип атый, терлек көтүдә һәм башка эшләрдә файдалана.

Түрк кабиләсеннән булган бер хатын жуанжуаннар даласында терлек көтеп йөрүче улын очрата, ул манкортка әвереллдерелгән була. Хатын улына аның әнисе икәнен аңлатырга тырыша, ләкин манкорт улы, берни дә аңламыйча, әнисен үтерә.

Бу коточкыч риваять жужаннарның ни дәрәҗәдә кансыз икәнен күрсәтә. Алар 200 ел буена (360—552) Бөек даланың хуҗасы була. Бу елларда Жужан дәүләте яшәгән. V гасырның 60—80 нче еллары — борынгы сөннәрнең Кытайга, Тарбагатайга һәм Җидесуга, Европага күчеп киткән варислары өчен иң хәтәр еллар, бу елларда аларның соңгы фаҗигасе була. 460—468 елларда көньяк сөннәр дәүләтләрен югалта, аларның Ордоста урнашкан Ся дәүләте, Ганьсудагы Хэси дәүләте җимерелә, 451 елда Аттила җитәкләгән Европа Һун дәүләте һәлакәткә дучар була, 487 елда телеутлар сөннәрнең Җидесуда соңгы дәүләте булган Юебань дәүләтен тармар итә. Бу дәүләтләр берсе дә торгызылмый. Шулай итеп, сөннәрнең 4 тармагы да бер үк чорда һәлак була. Ни өчен? Чөнки сөннәрнең ыруглык җәмгыяте артык озакка сузыла, ул анахронизмга әверелә. Аларның үткәндәге мирасы һәм иҗтимагый аңы көчле була, алар үзгәрә алмый. Ыруг башлыклары хакимлекләрен югалта.

Ләкин борынгы сөннәрнең варислары эзсез югалмый, башка төрки кабиләләр белән кушыла һәм төрки телле күп халыкларның этногенезында катнаша. Европа һуннарының варислары Көнчыгыш Европада яшәүләрен дәвам итә — алар болгарлар һәм башка төркиләр, шулай ук славян, угор, алан, венгр, герман, франклар составына кушыла.

Юебань дәүләтен җимергән телеутлар анда озак хуҗа була алмый, 495—496 елларда телеутларны эфталитлар, 547 елда түркүтләр яулап ала, бу Юебань сөннәренә исән калырга мөмкинлек бирә. Сөннәр турындагы бүлектә әйтелгәнчә, Юебань сөннәренең 4 тармагы — чуюе, чуме, чумугунь һәм чубань Бөек Төрки каһанлыгы чорында һәм аннан соң бик зур роль уйный[2].

Ордоста һәм Хэси дәүләте җимерелгәннән соң, чик буйларында калган сөннәр белән башкачарак хәл күзәтелә. 439 елда табгачлар

ханы Тоба Дао көньяк сөннәрнең Хэси дәүләтен җимерә, 440 елда табгачлар Хэсиның ханын үтерә, сөннәр идарәчесез кала. Ләкин алар югалып калмый, Гоби чүле аша көнбатышка китеп, Алтай тавы итәкләренә барып чыгарлык көч таба. Алтайда алар үзләренең кардәшләре — төркләр белән очраша. Суй династиясе елъязмасы «Вэйшу»да вакыйгалар бераз башкачарак сурәтләнә, ә бу елъязма иң ышанычлылардан санала. «Вэйшу»да язылганча, төркиләрнең бабалары б.э.к. берничә гасыр элек Хуанхэ елгасының төньягында яши. Алар Көнчыгыш Ганьсуның Пиньлянь округында яшәгән берничә этник катламның кушылуы белән барлыкка килә. 155 елда төньяк сөннәр җиңелгәннән соң, төркләргә кытайлар тарафыннан бөтенләй бетерелү куркынычы туа, алар тау мәгарәләрендә качып яшәргә мәҗбүр була, тик үзләренең тырышлыгы белән исән кала.

Төркләрнең берничә буыны шул рәвешчә гомер итә. 439 елда төркләрнең Ашина ыругы җитәкчесе көймәле 500 арбага утырган (һәр көймәдә бер гаилә) ыругдашларын Көнбатыш Шэньсидан Хэсига, Көньяк Сөн дәүләте ханы Мугань янына алып килә. Әмма Хэсида Ашина ыругын яңа кыенлыклар көтә — шул ук елны Хэсины табгачлар басып алган, Мугань хан үтерелгән була. Исән калган сөннәр Гоби аша төньякка — Алтай тау битләренә китә. Ашина ыругы башлыгы да үзенең 500 гаиләсен сөннәр киткән җиргә — Алтайга алып килә[3]. Алтайда Ашина ыругы үз тирәсенә җирле кабиләләрне туплый. Яңа кабилә союзы барлыкка килә, ул «төрк» дигән исем ала, телләрен дә «төрк теле» дип атый башлыйлар.

Шулай итеп, сөннәр һәм Ашина ыругы яшәү урынын Көньяк Алтайда таба, бу җирләрдә жужаннар хуҗа була. Монда килгән сөн варислары борынгы заманнардан Алтайның көньягында терлекчелек һәм тимер чыгару белән шөгыльләнеп яшәүче төрки кабиләләре белән кушыла[4].

Г. Е. Грумм-Гржимайло, Көньяк-Көнчыгыш Бараба төркиләрнең бишеге булды, дип яза. Алар анда әле сөннәр килгәнче үк яши һәм көньяк-көнчыгышка — Алтай-Саян таулыгына күчә, Енисей кушылдыклары бассейнын биләп, динлиннар белән мөнәсәбәткә керә, аларның бер өлешен буйсындыра, бер өлеше белән кушыла. Аннан соң төркүтләр сөннәр хакимлеге астына эләгә һәм аларның бер өлеше Ашина кенәзләре тарафыннан көньякка, Көнчыгыш Наньшаньга күчерелә. Ашина җитәкчелегендә дәүләт төзер көч әнә шулай барлыкка килә[5].

Ордоста, Шаньсида һәм Шэньсида калган сөннәр, табгачлар белән кушылып, Вэй империясе составында кала, аларны «ши-ху» (таулы ху) дип атыйлар. Ши-хуларның Шаньсида соңгы күтәрелеше 525—526 елларда була.

155 елда «сяньби» исеме алган сөннәр сяньбиләр белән түгел, үз кардәшләре белән ассимиляциягә керә.

Ордоста сөннәр һәм жужаннар союздаш була. Алтайда сөннәр һәм көньяктан килеп, борынгы заманнардан алып анда яшәүче башка төрки кабиләләр, Кытай хроникасы язуы буенча, жужаннар ясаклыларына әверелә, «жужаннар өчен тимер чыгара башлый». Ашина ыругы, мөгаен, пассионар яшь һәм кыю сугышчылардан торгандыр, тиздән бу ыруг күтәрелә һәм төрки кабиләләрнең башында тора.

Әмма әле жужаннар көчле була, һәм Ашина ыругы, башка төркиләр кебек, аларның хакимиятен танырга һәм тимер әйберләр белән ясак түләргә мәҗбүр була.

Кытай чыганаклары Ашина ыругының максатка омтылучанлыгына һәм оешканлыгына игътибар итә. Бу чыганаклар Ашина ыругы кешеләрен, ягъни түркләрне «ту-кю» дип атый. Бу сүз синологлар (Кытайны өйрәнүчеләр) тарафыннан «түркүт» дип шәрехләнә. «Түрк» Кытай телендә көчле сүзен белдерә, ә «үт» — күплек кушымчасы, ләкин монгол телендә. Кытай телендә «р» авазы булмаганга күрә, бу сүзне кытайлар «ту-кю» дип әйткәннәр. Ашина исеме «шоночино» дигән монгол сүзеннән килеп чыккан, ул — бүре дигән сүз. «А» — кытай телендә ихтирамны белдерүче кушымча. Шулай итеп, «Ашина» «югары затлы» бүре була[6].

Кытай елъязмалары түркүтләр турында тарихи хроника гына түгел, ә түрк риваятьләрен дә саклаган. Риваятьләрнең берсе Ерак Көнбатышта һуннарның явыз дошманнар тарафыннан кырылуы турында хәбәр итә. Ун яшьлек бер малай гына исән кала, аның кул-аякларын кисеп дошманнар күлгә ташлый. Малайны ана бүре күреп коткара. Берничә елдан бүре балага уза, ә дошманнар, малайның исән икәнен белеп, аны үтерәләр. Ялгыз калгач, бүре көнчыгышка кача һәм көнбатыш диңгезеннән еракта, Гао-чаннан (Алтай таулары үзәгеннән көньяк-көнбатышка таба, Чуя елгасы аккан урында) төньяк-көнбатышка килеп чыга. Ана бүре мәгарәгә кача һәм 10 ир бала таба. Соңыннан алар 10 буынның башлангычы була. Бүре оныкларының берсе «Ашина» исеме ала. Йоллыг-тәгин ташъязмаларда «Ашина» сүзенең мәгънәсен күк төсендә дип аңлата. Шуннан «күк бүре» сүзе барлыкка килә. Ашина зур сәләт иясе була һәм кабилә башлыгы итеп таныла. Аның ыругы әкренләп берничә йөзгә кадәр үрчи[7].

Малайны ташлаган үләнле күл Балатон күленә охшаган, аның янында һуннар җиңелүгә дучар була.

Икенче риваять түркләр җирле Со ыругыннан, шулай ук бүредән туган дип хәбәр итә. Со ыругының барлык вәкилләре дә һәлак була,

ана бүренең 4 оныгы гына исән кала. Беренче онык аккошка әверелә, Цигу исеме астында Абу һәм Гянь (Абакан һәм Енисей) елгалары арасына урнаша, өченчесе һәм дүртенчесе Көньяк Алтайда Чуси елгасында кала. Аристов риваятьтәге Со — кумандиннарның со ыругы, аккош — лебединнар нәселе (ку кижи), ә икенчесе кыргыз дип фаразлый.

Качкыннар килеп утырган Монгол Алтае тау итәкләрендә сөннәрдән килеп чыккан, төрки телдә сөйләшүче кабиләләр яшәгән. Ашина кенәзнең сугышчылары бу кабиләләр белән кушыла. Һәр төрки телле кабиләнең үз исеме була, ә аларның гомуми, берләштерүче «түрк» дигән исеме булмый. Ашина ыругы Алтайга «түрк» исеме белән килә, һәм шуннан аның барлык кардәшләрен «түрк» дип атый башлыйлар, шул ук вакытта элекке кабилә исемнәре дә саклана[8].

Әбелгази «Шәҗәрәи төрки» исемле хезмәтендә болай дип яза: «Туфаннан соң Нух пәйгамбәрнең 3 улы һәм 3 килене кала. Улларының исемнәре: Хам, Сими һәм Иафет. Соңгысы әтисе әмере буенча Идел һәм Җаек ярларында урнаша. Иафетның 8 улы һәм күп санлы нәселе була. Улларының исемнәре: Түрк, Хәзәр, Саклаб, Русь, Минг, Чин, Кеймари, Тарих. Иафет улы Түркне үз урынына калдыра һәм башка улларына: «Түркне хан итеп таныгыз һәм аңа буйсыныгыз!»[9] — дип әмер бирә».

Г. Е. Грумм-Гржимайло Иафет улы Түркне Каспийдан алып Корея култыгына кадәр булган җирләрдә яшәгән кабиләләрнең беренчел бабасы дип исәпләүләре хакында яза. Җиденче буында Түркнең ике улы туа: Татар һәм Монгол[10]. Алга таба Әбелгази Татар һәм Монголның этиләре Или хан Төркестанны икегә бүлә, бер улына көнчыгыш яртысын, икенчесенә көнбатышын биргән дип яза. Монголның өченче буынында Угыз хан — Кара хан улы туа. Монгол хан улы — Урта Азияне беренче яулап алучы[11]. Г. Е. Грумм-Гржимайло Угыз хан чынлыкта Модэ шаньюй дип яза[12].

Кытай елъязмаларындагы риваять Ашинаның тууы белән тәмамлана, аннан соң башка чыганаклар белән раслана торган тарихны тасвирлау башлана.

Шулай итеп, 439 елдан соң башында Ашина торган төрки кабиләләр жужаннарга буйсына. Һәр ел тимер әйберләр белән ясак түлиләр. Шул ук вакытта алар үз хуҗалыкларын да ныгыталар.

Бөек Төрки каһанлыгы төзелү тарихын безгә Кытай хроникалары хәбәр итә: Чжоу-шу (629 елда тәмамлана һәм соңыннан Бэйшидан өзекләр белән тулыландырыла) һәм Бэй-ши (659 ел). Алар хәбәр итүенчә, IV—VI гасыр башында «түрк» этник төркеме жужаннар кул астында була. Алар башка төрки телле кабиләләр

арасында, Алтайның көньяк итәгендә яши, күчмә терлекчелек белән шөгыльләнә, ләкин төп шөгыльләре тимер чыгару һәм аннан әйберләр ясаудан гыйбарәт була.

Тимер рудасы булмаган Көнбатыш Монголия шартларында тимер әзерләү югары бәяләнә һәм бу төркләргә файдалы була. Жужан дәүләтенең бөтен икътисады һәм аның армиясенең кораллануы төркләрнең тимер һәм аннан ясалган җиһазлар белән түләгән ясагына, шулай ук жужан армиясенең һөҗүм итү һәм саклану коралларын ясау, атлы гаскәр кирәк-яракларын эшләү дә төркләр металлургиясенә бәйле була[13].

Византия илчесе Зимарх, 568 елда Көнбатыш Төрки каһанлыгына барып кайтканнан соң, төркиләр үзләренең чи руда эшкәртә торган күрекләрендә югары сыйфатлы чистартылган тимер коялар, аңа сорау бик зур һәм бәясе дә бик кыйммәт, дип яза[14].

Бу чорда төркиләрнең этник аңы бик көчәя, Ашина ыругының килеп чыгышы турындагы төрк риваятен барлык төркиләр дә белә һәм үзенең нәсел башы итеп бүрене саный. Шулай итеп, борынгы төрк этносы яңара. Кытай хроникалары, төрк теле б.э.к. 25 гасыр элек билгеле иде, дип яза.

Бу чорда Кытай өч дәүләткә бүленгән була. Жужан һәм төркиләрдән көньяктарак Көнбатыш Вэй дәүләте урнашкан була. Чик Хуанхэ буйлап уза. Көнбатыш Вэй Көнчыгыш Вэй белән дошманлаша. Көнбатыш Вэйның хәле яхшыдан булмый. Көнбатыш Вэйның шымчылык хезмәте, Көнчыгыш Вэй жужан ханы Анахуан белән сөйләшүләр алып бара, жужаннар белән бергә яшәүче төркләр, Хуанхэ аша чыгып, кытайларны борчый башлаган, дип хәбәр итә.

Бу хәбәр Көнбатыш Вэй идарәчеләрен борчуга сала, һәм алар төркләр турында мәгълүмат җыярга тотына. Төркиләр турында җыеп язып куелган барлык мәгълүмат борынгы төркиләр турында хәбәр итүче бай чыганак булып кала[15].

Беренче Төрки каһанлыгы

534 елда Ашина ыругының һәм барлык төркиләрнең юлбашчысы Бумын була. Ул «Бөек ябгу» (кенәз) дигән титул йөртә. Формаль яктан жужан ханының вассалы санала, ләкин, төркиләргә таянып, биләмәләрен көнчыгышка таба еракка киңәйтә, ясакны тулысы белән түли. Төркиләр кытайлар белән сәүдә итә башлый, терлекләрен ашлык һәм ефәккә алмаша. Төркиләрнең Хуанхэ туңган вакытта Кытайга һөҗүмнәре ешая.

Көнбатыш Вэй көчсез дәүләт була. Император Вэньди күбесенчә бәйрәмнәр белән мавыга, дәүләт эшләре белән аның киңәшчесе Юй


Төрки сугышчылар

Вэн идарә итә. Бу дәүләтнең халыкара хәле дә катлаулы була. Көнчыгышта дошман Көнчыгыш Вэй, төньякта Жужан дәүләте һәм төркиләр, көнбатышта уйгырлар тарафыннан җитәкләнгән угыз кабиләләре урнашкан. Юй Вэн карашын түркләргә юнәлтә.

100 елдан артык чор эчендә (439 елдан башлап) түркүтләр мөстәкыйльлек өчен көрәш алып бара. 536 елда алар беренче булып жужаннар хакимлегенә каршы уңышсыз көрәшүче 50 мең угыз гаиләсен буйсындыра[16]. Угызларны җиңү түркүтләрне канатландыра, алар үзләренә 50 мең гаилә күләмендә көрәштәш таба.

Тиздән түркүтләрне канатландырган әһәмиятле вакыйга уза. Үгез елында, ягъни 545 елда, Көнбатыш Вэй илчелеге Бумын идарәсенә килә. Шулай итеп, түркүтләрнең дәүләте Көнбатыш Кытай дәүләте тарафыннан да, халыкара планда да танылу таба. Кытай тарихчысы бу вакыйга турында, түркүтләр аны бик югары бәяләде, ул аларда патриотик хисләр кузгатты, дип яза.

552 елда Бумын гасырлык дошманга — жужаннарга каршы сугыш башлый, аларның төп көчләрен тар-мар итә һәм җиңә. Жужаннарның зур төркемнәре көнбатышка, Кара диңгез буена һәм Карпат аркылы Венгриягә кача. Анда аларны «аварлар» дип атыйлар. Жужан каһаны үзенә кул сала. Шул ук елда Бумын борынгы төрки йоласы буенча ак киездә күтәрелә һәм Түрк иленең каһаны дип игълан ителә, аңа Или хан исеме бирелә. Борынгы Сөн дәүләтенең барлык территориясе диярлек түркләр хакимлегенә керә. Ул чордагы гадәт буенча Бөек далада тик бер генә каһан була алган. Бумын, Кытай императоры кызына өйләнеп, үзенең хәлен ныгытып җибәрә.

Татар тарихи әдәбиятында түрк кабиләләрен «төркиләр», ә түрк телен «төрки тел» дип атау гадәткә кергән, без дә шул традицияне дәвам итәрбез. Ашина ыругы вәкилләрен традиция буенча «түркүтләр» дип атарбыз.

552 елда түркләр дәүләте — Бөек Төрки каһанлыгы әнә шулай төзелә. Аның 552—630 еллардагы чоры тарихка Беренче Төрки каһанлыгы дип кереп калган. 552 елда Бумын каһан үлә, тәхеткә Кара Ыссык хан исеме астында аның улы килә. Ул да озак идарә

итми, тәхеткә Мугань каһан (553—572) исеме белән аның энесе утыра. Татабларны (кытайча «хи»), киданнарны һәм «утыз-татар» кабиләсен (кытайча «шивэй») буйсындырып, түркүтләр Сары диңгезгә чыга. Кытай хроникалары: «Бу өч халык — татаблар, киданнар һәм «утыз-татарлар» монгол телендә сөйләшкәннәр һәм үзара дошман булганнар»,— дип яза. Төньякта аларга Енисей кыргызлары һәм Тывада яшәүче чиклар буйсынган[17]. Шул ук елларда Мугань каһанның ир туганы Истәми каһан, Җидесу, Казакъстан һәм Харәземне буйсындырып, Арал диңгезенә чыга[18].

Егерме биш ел эчендә төркиләрнең беренче дәүләте бик зур территориягә хуҗа була. 560 елларда түркүтләр Әфганстан, Һиндстан һәм Шәркый Төркестанның бер өлешенә урнашкан эфталитлар (ак сөннәр) дәүләтен һәм зур булмаган Хотан кенәзлеген яулап ала.

Эфталитларны җиңгәннән соң, түркүтләр Сасанилар Ираны белән мөнәсәбәткә керә. Бөек Төрки каһанлыгы Византия белән союзда булып, Бөек ефәк юлын контрольдә тоту өчен, Иран белән сугышлар башлый. Ефәк Европа алтыны белән алмашка Кытайдан килгән. 567 елда алар Иран белән Урта Азияне бүлешү турында килешү төзи. Амударьяның көнчыгышында һәм төньягындагы барлык җирләр Беренче Төрки каһанлыгына, көнбатыштагы һәм көньяктагы җирләр Иранга бирелә. Көнбатышка таба һөҗүмнәрен дәвам итеп, төркиләр Каспий диңгезенең төньягыннан Төньяк Кавказга чыга. Төркиләрнең гаскәрләре 576 елда Кара диңгез буенда Византия белән бәрелешә, ул каһанлыкка 576—581 елларда Херсонесны, Боспорны һәм элекке Боспор патшалыгының Кавказ буе биләмәләрен бирергә ризалаша[19]. 558 елда түркүтләр Идел буен һәм Урал буйларын яулап ала.

VI гасырның соңгы чирегендә түркүтләргә Төньяк Кытай дәүләтләре Чжоу һәм Ци буйсына. Каһанлык гаять зур һәм икътисади яктан көчле дәүләткә әверелә.

VI гасырның 60 нчы елларында Бөек Төрки каһанлыгы шул заманның иң зур дәүләтләренең — Кытайның, Иранның һәм Византиянең — сәяси һәм икътисади мөнәсәбәтләре системасына кушыла[20]. Япон диңгезе һәм Маньчжуриядән алып Кара диңгездәге Керчь бугазына кадәр сузылган беренче Евразия империясе төзеп, төрки каһаннар Урта Азиянең һәм Көнчыгыш Европаның киләчәк тарихына да йогынты ясый. Әлеге дәүләтнең сәяси һәм рухи мирасы бу территорияләрдә яшәгән халыклар тарихында тирән эз калдыра.

Бөек Төрки каһанлыгын төзүдә Алтай түркүтләре генә түгел, теле кабиләләре дә катнаша, аларга соңрак уйгыр, дубо, курыкан, теленгит, байырку һәм башка кабиләләр дә кушыла.



Төрки һәм кыргыз каһанлыклары (б.э.ның VI—X гасырлары). Чыганак: *Вайнштейн С. И.* Восточно-Тюркский каганат и кыргызы, 1946

572 *елда* Мугань хан үлә. Аның варисы Тобо хан, ике Кытай дәүләте Бей–Ци һәм Бей-Чжоу арасындагы дошманлыктан файдаланып, зур табыш ала. Бей-Ци аңа һөҗүм итүдән баш тарткан өчен, ә Бей-Чжоу аңа дошман булган дәүләтләргә һөҗүм итәргә әзер торган өчен Бөек Төрки каһанлыгына зур бүләкләр бирә. Фәкать Чжоудан гына да түркүтләр бер *елда* 100 мең кисәк ефәк ала. Ци исемле Кытай дәүләте белән союз түркүтләрнең Кытай белән мәдәни аралашуына ярдәм итә[21].

578 *елда* Тобо хан Кытайга бәреп керә һәм Кытай армиясен җиңә. 580 *ел* Төрки дәүләте куәтенең иң югары биеклеге була. Шул ук *елны* Бөек Төрки каһанлыгының хәлен катлауландыра торган вакыйга уза. Төркиләрнең явыз дошманы — генерал Ян Цзянь дәүләт түнтәрелеше ясый һәм Кытайда Чжоу династиясен Суй династиясе белән алмаштыра. Сәяси вазгыять үзгәрә — Суй династиясе императорлары түркүтләргә каршы агрессияне көчәйтә. VI гасырның 70—80 нче *елларында* Беренче Төрки каһанлыгы Кытай, Иран һәм Византия белән сугышлар алып бара. Атлы гаскәрләрен файдаланып, түркүтләр һәрвакытта диярлек җиңә, ләкин бу сугышлар дәүләтнең куәтен сыекландыра һәм халкын бөлгенлеккә төшерә, дәүләтнең һәлакәтен якынайта.

Берләшкән Кытай дәүләте Суй 587 *елда* Көньяк Кытайны буйсындыра, һәм ул Бөек Төрки каһанлыгыннан көчлерәк булып китә. 581—618 *елларда* Суй Кытай империясе каһанлыкның эчке эшләренә катнаша. Шул сәбәпле Бөек Төрки каһанлыгының хәле аеруча катлаулана. Кытайлар хәрби көчне генә түгел, Бөек Сөн каһанлыгына каршы көрәштә күптәннән сыналган сатып алу, шымчылык, хәйләле дипломатия һәм корткычлыкны файдалана башлый. Кытай түрк аксөякләрен, зиннәтле әйберләр белән кызыксындырып, үзенә тарта. Ыруг башлыкларын сатып алу тактикасы гаять көчле була. Түркләрнең табигый демократиясе символы булган ыруг аксөякләре халыкның нәфрәтен казана[22].

Сатылган бәкләрнең роле Шаболио хан (588—600) идарә иткән *елларда* көчәя. Ул Дану хан белән сугыша, бу вакытта төркиләр арасында ыругара сугышлар бара, бу дәүләтнең көчсезләнүенә китерә. Шаболио үзен Кытайга ясак түләүче итеп таный, башта ул үзенең буйсынуы турында битек җибәрә, аннан ясак белән үз улын Кытайга озата. 588 *елда* ясак түләү өчен 10 000 ат, 20 000 сарык, 500 дөя һәм үгез җибәрә[23].

Сугышлар, ыруг башлыкларының купшылык һәм байлык белән мавыгуы халыкның ярлылануына китерә, югары катлау үз халкының көнкүреше турында торган саен кимрәк кайгырта. Болар барысы һәм көтүлекләр бозланудан килеп чыккан терлек ачлыгы



Төрки җайдагы. Дуньхуанда табылган балчык статуэтка

581—582 елларда Беренче Төрки каһанлыгын тирән кризиска китерә. Бөек Төрки каһанлыгы 582—603 елларда бер-беренә дошман булган ике дәүләткә — Көнчыгыш Төрки каһанлыгы һәм Көнбатыш Төрки каһанлыгына аерыла. Көнчыгыш Төрки каһанлыгы Алтайдан Бөек Кытай стенасына кадәр территориядә урнаша, һәм ул ярты гасыр чәчәк ата. Аның каһаны халыкны Кытайга каршы көрәшкә туплый. Көнчыгыш каһанлыкта төркләрнең бердәмлегенә омтылыш һәм Кытайга каршы тору көчле була. Бу хәл каһанны һәм халыкны берләштерә. Көнчыгыш төркләргә климатның җылынып китүе дә ярдәм итә, бу терлекчелекнең үсүенә булыша[24].

Көнбатыш Төрки каһанлыгы Алтайдан Кырымга кадәрге җирләрне били, аның үзәк төбәкләре булып Тарбагатай, Саура, Тянь-Шань тау итәкләре һәм Җидесу торган. Көнбатыш каһанлыкның табигый шартлары ыругларның таркалуына китерә, кабилә юлбашчылары көчәя. Элекке унитар дәүләт — бердәм Төрки иле урынына анда ун кабилә башлыгы конфедерациясе оеша, бу хәл Ашина ыругының абруен һәм көчен югалтуга китерә[25].

Бөек Төрки каһанлыгының икегә бүленүе дәүләт өчен дә, халык өчен дә зарарлы була. Көнчыгыш Төрки каһанлыгы белән Көнбатыш Төрки каһанлыгы арасында туктаусыз сугышлар булып тора, алар ике дәүләтне дә хәлсезләндерә. Көнбатыш Төрки каһанлыгы каһаны дәүләтнең элеккеге бердәмлеген торгызырга омтыла, шул максат белән ул 593 елда каһанлыкның ике кисәген берләштерә, алар арасында тыныч мөнәсәбәтләр урнаштыра.

VII гасыр башында Көнбатыш Төрки каһанлыгы идарәчесе Кара-Чурин Богю хан хәбәрсез югала. Тагын ике хан алмашканнан соң, кыска вакытка тәхет варисы булып сабый бала Нигю Чуло кала. Хакимиятнең йомшаруы белән дулу кабилә берлеге җитәкчеләре файдалана. Моңарчы хәрби, дәүләт һәм дини җитәкче булып каһан һәм ханнар торган, ә Көнбатыш каһанлыкта бәкләр ханны бу вазифалардан азат итә. Борынгыдан килгән гадәт буенча, каһаннар, үзләре елга ике тапкыр Тәңрегә дога укып, корбан чалган. Ә хәзер бу йоланы дулу кабиләсеннән бер бәк башкарган, шуның белән ул Ашина ыругының һәм хан хакимиятенең дәрәҗәсен төшергән[26].

Көнбатыш каһанлыкта чуалышлар башлана. Суй империясе мәкерле дипломатиясен көчәйтә. Каһанлыктан буйсындырылган кабиләләр аерыла башлый.

604 елда каһанлык тагын көнчыгыш һәм көнбатыш өлешләргә бүленә. Көнчыгыш каһанлыкта Жангар хан була, Көнбатышта — Чуло хан. 618 елда сәләтсез Чуло ханны фетнә вакытында үтерәләр. Хакимияткә Шегуй хан килә, элекке хакимият кайтарыла, түркүтләр яңадан дәүләт башына утыра. Җабгу хан вакытында әле көч саклана, ул хәзәрләр һәм болгарлар белән мөнәсәбәт урнаштыра[27].

Түркләрнең мөстәкыйльлеге үсү куркынычын сизеп, Кытай җитәкчеләре күптән сыналган сатып алу һәм мәкерле дипломатия ысулын көчәйтә. Суй хөкүмәте сатып алуга, бүләкләр бирүгә, мул сыйлауга корылган купшы бәйрәмнәр үткәрүне гадәткә кертә. 607 елда Жангар хан һәм 3500 ыруг башлыгы хөрмәтенә шундый «дуслык» бәйрәмнәренең берсе зур бүләкләр белән үткәрелә. 610 елдан бу бәйрәмнәр даими булып тора һәм Лоянда үткәрелә. Кунаклар өчен бертуктаусыз 18 мең музыкант уйный. Кытайның шулкадәр байлыгы, хәтта шәраб һәм ризык өчен хак алмавы турындагы сүзләргә ышандыру өчен, аларны бушлай ашаталар һәм эчертәләр[28].

Шегуй каһан (618—619) һәм Тон-ябгу каһан (619—630) идарә иткән елларда Көнбатыш Төрки каһанлыгы чәчәк ата. Бу хәл яңа территорияләр яулап алу һәм хәрби-ыруг башлыкларының баюы һәм йогынтысы үсү белән бәйле. Тон-ябгу каһан дәүләтнең чикләрен Амудәрьяның югары агымына һәм Һиндукуш тауларына кадәр киңәйтә. Ул Византия императоры Ираклий белән бергә (627—628) Дербентны һәм Тбилисины ала, түркүтләр кулына бик күп байлык керә. Ләкин Тон-ябгу каһанның деспот хакимияте, кабилә түрәләренең сугышларда баеп, башбаштаклыклар кылуы халыкта нәфрәт тудыра, илдә үзара ызгышлар башлана. Тон-ябгу каһанны туганнан туганы Күл Баһадир үтереп, үзен каһан дип игълан итә. Илдә кабиләара сугышлар башлана, 630—634 елларда

Көнбатыш каһанлык Урта Азиядәге шактый биләмәләрен югалта. Көнбатыш каһанлыктагы дулу һәм душибу кабилә берлекләре арасында хакимият өчен барган көрәш озакка сузылган сәяси кризис китереп чыгара. Каһанлыкның Җидесу өлкәсен 657 елда Кытай гаскәрләре басып ала. Көнбатыш төркиләрнең азатлык өчен көрәше VII гасырда Түргеш каһанлыгы төзелүгә китерә[29].

Шиби каһан (609—619) идарә иткән елларда Көнчыгыш Төрки каһанлыгы кризис хәленнән чыга, аның сәяси куәте арта. Кытайда 613—618 елларда барган ватандашлар сугышы, Суй династиясенең Тан династиясе (618—907) белән алмашынуы Шибига һәм аның энесе Ил каһанга (620—630) яңадан Кытайга каршы сугышлар алып барырга мөмкинлек бирә.

Ләкин бу чорда төркиләр арасында иҗтимагый вазгыять Бөек Төрки каһанлыгы төзелгән еллардагыдан үзгә була инде. Элек, сугышлардан кергән ганимәт малы барлык сугышчыларга да бүлеп бирелгәндә, халык сугышны кирәк санаган. Ганимәтне күбрәк биреп, каһаннар кабилә башлыкларын аздыра, алар, халыктан аерылып, байлык артыннан куып, үз мәнфәгатьләре белән яши башлый. Ә гади халык, тыныч кына терлеген көтеп, үзеннән арткан итен, маен, тиресен, йонын чик буенда кытайлар белән алмаштырып, тыныч яшәүне артык күрә. Кайвакытта каһаннар да, халык сүзен тыңлап, Кытай хөкүмәте белән алмашу сәүдәсе алып бару турында килешү төзи, ләкин Кытай идарәчеләре, сөннәр заманындагыча, төркиләрне басып тоту нияте белән бу алмашуны өзә, төркиләрне икмәксез, кирәк-яраксыз калдыра.

Шулай да халыкны азмы-күпме ганимәт белән кызыксындырып, Ил каһан 620—629 елларда Кытай чигендә 67 һөҗүм оештыра. Ганимәтнең зур өлеше каһанга һәм аристократиягә эләгә. Моның өстенә Ил каһан үз халкына төрле салымнар йөкли, борыннан килгән төрки тәртипләрне җимереп, идарә итәргә согдларны һәм кытайларны куя. Бу хәл ризасызлыкны көчәйтеп кенә калмый, халыкта нәфрәт тә тудыра[30]. Нәтиҗә озак көттерми. 629 елда Ил каһан Шаньсида тар-мар ителә. Император армиясе каһанлыкка басып керә, Ил каһанны беркем дә якламый, 630 елда ул әсир төшә. Шуның белән Беренче Төрки каһанлыгы тарихы тәмамлана.

Икенче Төрки каһанлыгы

630 елда Кытай гаскәрләре теле кабиләләре ярдәме белән Көнчыгыш Төрки каһанлыгын җимерә, һәм ул 50 ел буена Кытайга бәйле булып кала. Төрки кабиләләр Ордос һәм Шаньсиның төньягына күчерелеп утыртыла. Аеруча ихтирамга лаек 500 ыруг

башлыгы «хәрби башлыклар» итеп билгеләнә. Төркиләр Кытай өчен сугышларда катнашырга тиеш була. Төркиләргә бирелгән кечкенә мәйданнарда халык терлеген көтә алмый, аларның тормышы начарлана. Кошо-Цайдамдагы рун язуларында 679 елда Кытайга каршы башланган баш күтәрүнең сәбәпләре күрсәтелгән[31].

657 елда Кытай, буйсындырылган күршеләрнең көчен файдаланып, Көнбатыш Төрки каһанлыгын җимерә. Аның соңгы бәйсез идарәчесе Нивар Ышбара ябгу-каһан әсир итеп алына һәм 659 елда үлә. 630—680 еллар чоры көнчыгыш һәм көнбатыш төркиләр өчен авыр була, алар иске гадәт буенча «Табгач империясе» дип йөртелә торган Тан империясенә хезмәт итә. Бу 50 еллык чорда Кытай формаль рәвештә төркиләр өчен хан титулын саклый, ләкин мөстәкыйльлек булмый. Бу еллар ыруглык җәмгыятен феодаль тәртипләр белән алмаштыру чоры була. Кытайга төркиләр яшәгән гаять зур территориядән ясак агыла. Төркиләрнең өстен катлавы Кытайга бәйлелектән котылырга омтыла, ләкин ясакны үзенә алыр өчен генә. Гади төркиләр дә Кытайга бәйлелектән котылырга тели, туктаусыз баш күтәрә, ләкин аларның җитәкчеләре булмый, ә өстен катлау Кытай составында да бик шәп яши.

Тарихның кискен моментларында өстен катлаулар һәрвакыт диярлек үз халкының мәнфәгатьләренә хыянәт итә, тик патриотлар гына халык ягына баса. 679 елда Чеби хан заманында Кытайга каршы иң дәһшәтле баш күтәрүләрнең берсе башлана, ул Гудулу хан чыгышына кадәр дәвам итә. Халык күтәрелешенең җитәкчеләре Ашина-Ниши хан, аннан соң Фунян була. 681 елда Гудулу җитәкчелегендә Кытайга каршы күтәрелеш башлана. Ул, мөгаен, бай бәкләрнең берсе булгандыр, шуңа күрә үзен «Эльтерес хан» дип игълан итә[32].

681 елгы Кытайга каршы күтәрелештә төркиләр җиңә. Кутлуг Эльтерес хан Көнчыгыш Төрки каһанлыгын яңадан торгыза. Бу бик әһәмиятле тарихи вакыйга була. Кутлуг Эльтерес ханның батырлыгы халык көчен бәяли, һәм аны оештыра белүе турында Күлтәгин, Могилян, Тоньюкук һәйкәлләрендә һәм Онгин ташында күп язылган. Төркиләрне азат итү буенча Тоньюкук бик зур эш башкара. Ул Кытайда тәрбияләнә,ниндидер гамәлләре өчен төрмәгә утыртыла, төркиләргә каршы көрәшергә дигән сылтау белән иреккә чыгаруны сорый. Ирек алып, түркүтләргә кушыла һәм аларның Кытайга каршы көрәшен җитәкли. Һәйкәлдәге Тоньюкук язмасы үз эпохасының зур сәяси документы, оппозициянең сатлык төрки өстен катлавына каршы декларациясе булып тора. Тоньюкук ханнарның, хәрби башлыкларның киңәшчесе була, аны «акыллы» дип атап йөртәләр.

Түркүтләрнең идеологы Тонъюкук Кытайга һәм төркиләрнең тирә-ягындагы кабиләләргә каршы сугышларын гына тасвирлап калмый, ә үзенең һәм Эльтерес ханның илгә күрсәткән хезмәтләрен онытучыларны гаепләү сүзен дә әйтә. Ул төркиләрне, ханга хыянәт итеп, Кытайга сатылуда гаепли. Аннан соң вакыйгаларны санап китә. Тонъюкук һәйкәле язмасының эчтәлеге аның тексты Тонъюкукның үзе тарафыннан язылуны һәм үзе исән вакытта куелуны күрсәтә[33].

681 елдан Икенче Төрки каһанлыгы тарихы башлана. 681—745 елларда төркиләр яңадан Бөек даланың хуҗасы була. Капаган каһан чорында (691—716) Көнчыгыш Төрки каһанлыгы үз чикләрен Маньчжуриядән Сырдәрьяга кадәр җиткерә. Ләкин 712—713 елларда төркиләр гарәпләрдән җиңелә. Көнчыгыш каһанлык тарихының калган өлеше Орхон-Енисей язмаларында җентекләп язылган. Кытайның Тан империясенең көчәюе ызгышлар һәм халык күтәрелешләре белән бергә туры килә.

Капаган хан, Тан империясендәге дәүләт түнтәрелешеннән файдаланып, кытайларны хурлыклы солых төзергә мәҗбүр итә, төркиләрне Кытай армиясендәге хезмәттән кайтара. Аннан соң баш күтәргән уйгырларны җиңә. Әмма тиздән Кыргыз дәүләте Көнчыгыш каһанлыктан көчлерәк булып китә, һәм ул каһанлыкның куркыныч дошманына әверелә. Үзенең тәвәккәллеге белән Капаган кыргызларны җиңә[34]. Ләкин ул үз кабиләдәшләренең хыянәтеннән курка һәм аларны иң куркыныч походларга җибәрә. Капаган хан үзенең «Күчүк хан» титулын йөрткән улына тәхетне бирү өчен хәйләгә бара. Капаган хан кешеләрне яхшы таный белгән, хәлиткеч урыннарга кирәкле кешеләрне куйган, бәкләрне дә үз ягына аударырга оста булган. Ул тардушларның шады итеп үзенең кардәше Могилянны билгели, ә бу иң хәтәр нокта — гаскәрнең уң канаты була. 17 яшьлек Могилянны һәм аның 16 яшьлек энесе Күлтәгинне (икесе дә ханзадәләр) тибетлылар басып алган Джунгариягә сугышка җибәрә. Тибетлылардан Джунгарияне Тан империясе табгачлары алырга омтыла, чөнки Джунгария әһәмиятле регион була — аның аркылы зур табыш китерүче Бөек ефәк юлы үткән. Могилян һәм Күлтәгин Джунгарияне алалар, Юебань сөннәренең калдыкларын көнбатышка таба куалар, бу юлда урнашкан согдларны буйсындыралар. 701—702 елларда Күлтәгин ефәк юлына омтылучы табгачларны тар-мар итә. Могилян һәм Күлтәгин иң популяр каһарман төркиләр булып китә[35]. Аннан соң Могилян һәм Күлтәгин өч-угыз (карлуклар), утыз-угыз (басмаллар), аз, курыкан, байырку, тугыз-угыз кабиләләрен бастыра. Зур җиңүләргә карамастан Көнчыгыш Төрки каһанлыгының хәле ныклы булмый. Бу турыда акыллы Тонъюкук үзенең

һәйкәлендә болай дип яза: Көнчыгыш төркиләрнең эре дошманнары гына да өчәү иде: Көнбатыш Төрки каһанлыгында Көнчыгыш каһанлыгына карата дошман рухында булган түргешләр хакимлек итә, көнчыгыштан — Тан империясе, төньяктан төркиләрдән көчлерәк булган Кыргыз каһанлыгы яный».

Күлтәгин һәйкәле (төньягы). 732 *ел*. Монголия.
С. Г. Кляшторный фотосы

715 *елда* Көнчыгыш каһанлык өчен куркыныч ситуация килеп туа — барлык буйсынган кабиләләр: карлуклар, көнбатыш төркиләре, татаблар, киданнар, изгиллар, уйгырлар, байыркулар үз ирекләрен яклап баш күтәрә. Тонъюкук акыллы киңәшләре белән, Күлтәгин гаскәре белән дошманнарга каршы батырларча көрәшә. Бу хәлиткеч моментта Капаган үзенең варисы итеп улы Көчек ханны билгели. Күлтәгин гаскәрнең бер өлеше башлыгы Алып әл-Этмиш ярдәме белән Көчек ханны җәзалап үтерә, үзе барлык гаскәрләрнең башлыгы була, ә тәхеткә Билге хан титулы белән үзенең бертуганын утырта. Тонъюкук, Күлтәгин, Билге хан Көнчыгыш Төрки каһанлыгын батырларча коткаралар. 722—741 *елларда* анда тынычлык хөкем сөрә. 727 *елда* Кытай белән шартнамә төзелә, бу шартнамә буенча ул Көнчыгыш каһанлыгына *ел* саен 100 мең кисәк ефәк күләмендә ясак түли.

731 *елда* көнчыгыш төркиләрнең җиңелмәс гаскәр башлыгы Күлтәгин үлә. 734 *елда* Билге ханны агулап үтерәләр. Көнчыгыш тәхетенә Йоллыг тәгин утырып, 742 *елга* кадәр идарә итә. Могилян 733 *елда* үлә. Алардан соңгы ханнар — Могилян улы Ижань (739 *елда* үлә), аның энесе Биг Гудулу (739—742) идарә иткәндә, эчке низаглар дәвам итә. Көнчыгыш Төрки каһанлыгының бик йомшару, каушау чорында тәхеткә «сайланган» ханы хәтта түркүт династиясе вәкиле дә булмый[36]. 744 *елда* Ашина ыругы яшәүдән туктый. Каһан итеп басмаллар җитәкчесе куела, ләкин ул 2 *елдан* да кимрәк кенә хакимлек итеп кала. 745 *елны* Көнчыгыш Төрки каһанлыгын уйгырлар җимерә. Капаган ханның тәхеткә утыруыннан

716 елга кадәр булган барлык вакыйгалар Орхон һәйкәлләрендә язылган. Күлтәгин, Тоньюкук, Могилян, Билге хан 42 ел буена дәүләтнең язмышын гына хәл итеп калмыйлар, киләчәк буыннар өчен үз батырлыкларының тарихын язып калдыралар, дәүләтнең җимерелү сәбәпләрен күрсәтәләр. Төркиләр тарихының бу каһарманлык һәм хәвефле чоры бернинди фальсификациягә дә бирелми, чөнки ул каһарманнарның үзләре тарафыннан ташка язылган.

Өстен катлауның аерылуы, Кытайның туктаусыз агрессиясе, халыкның ризасызлыгы Көнчыгыш Төрки каһанлыгын вак биләмәләргә бүленүгә һәм дәүләтнең җимерелүенә китерә. Аның урынына яңа төрки дәүләт —Уйгыр каһанлыгы барлыкка килә, ул 745—840 елларда яши.

Бердәм дәүләт булган Бөек Төрки каһанлыгының бүленүе халык ихтыярына каршы килеп башкарылса да, Көнчыгыш һәм Көнбатыш каһанлыкларның юлы нык аерыла. Көнчыгышта түркүтләр нык берләшкән этник төркем булып кала, алар үз араларында гына түгел, башка төркиләрдә дә борынгы традицияләрне саклап кала һәм үстерә. Беренче уңайлык туга ук, көнчыгыш төркиләр дәүләтләрен торгызуга әзер була.

Көнбатыш каһанлыкта башкача вазгыять күзәтелә. Түркүтләр анда аз санда була. Ә Җидесуда, Чү үзәнлегендә, Тарим, Амударья елгалары буенда, Түбән Идел һәм Кубань буенда яшәгән башка төрки кабиләләр, Ашина ыругы түркүтләренә ышаныч белән карап, шулар тирәсенә берләшә. Тан империясе, төркиләр арасында түркүтләрнең абруе зур булудан файдаланып, шулардан булган каһан тирәсендәге түрәләргә таянып, көнбатыш төрки кабиләләре белән идарә итмәкче була.

Көнбатыш Төрки каһанлыгын ул заманда «Ун Ук иле» дип атап йөртәләр. Ул социаль-иҗтимагый төзелеше белән дә Көнчыгыш каһанлыктан нык аерылып торган. Көнчыгышта нигездә күчмә тормыш булса, көнбатышта игенчелек, сәүдә һәм һөнәрчелек белән көн күрүче утрак тормышлы кабиләләр яши. Социаль структурасы белән көнбатыш аерылып торган, биредә вазгыять шактый катлаулы була һәм Көнбатыш каһанлыкны чагыштырмача феодаль мөнәсәбәтләр үскән дәүләт дияргә мөмкин. Икенче Төрки каһанлыгы чорында Көнбатыш Төрки каһанлыгы зур күтәрелешкә ирешә алмый. Дулу һәм нушиби кабиләләренең үзара сугышлары аңа зур зарар китерә. Сугышны Ышбара Хилаш каһанның (634—639) илне ун укка — кабилә территорияләренә бүлүе дә ярдәм итми.

658—659 елларда Көнбатыш Төрки каһанлыгы җирләрен Кытай басып ала. 704 елда гына Көнбатыш каһанлык яңадан мөстәкыйльлеккә ирешә. Ләкин төньяк күршеләренең агрессивлыгы

һәм эчке каршылыклар Икенче Көнчыгыш каһанлыкны һәлакәткә китерә.

Каспий һәм Кара диңгез буйларын яулап алганнан соң, түркүтләргә Көнчыгыш Европаның төрки кабиләләре — хәзәрләр, болгар-утургурлар кушыла. Согдиялеләр һәм эфталитлар каһанлык составына Эфталитлар дәүләтен һәм Харәземне буйсындырганда кушыла[37].

Бөек Төрки каһанлыгының территориаль яктан икегә — Көнчыгыш һәм Көнбатыш Төрки каһанлыкларына, вакыт ягыннан Беренче һәм Икенче Төрки каһанлыкларына бүленеп йөртелүе укучыга аңлау өчен беркадәр кыенлык тудыра. Бөек Төрки каһанлыгы чорында андый бүленеш булмаган. Тарихи вакыйгаларны аңлауны җиңеләйтү өчен, аны тарихчы галимнәр шулай бүлә. Бу бүленешләргә йомгак ясап, шуны әйтергә кирәк: 552 елда төзелгән Бөек Төрки каһанлыгы 582 елда Көнчыгыш һәм Көнбатыш каһанлыкларга аерыла. Бөек Төрки каһанлыгының 552—630 еллар чоры *Беренче Төрки каһанлыгы*, ә Көнбатыш Төрки каһанлыгында 681—745 еллар чоры, Көнчыгыш Төрки каһанлыгында 704—740 еллар чоры *Икенче Төрки каһанлыгы чоры* дип атап йөртелә.

Хәзәр каһанлыгы һәм Азов буендагы Бөек Болгар дәүләте

Хәзәрләр турында IV гасырдан — һуннар һөҗүменнән башлап билгеле. Хәзәрләр түркүтләргә каршылык күрсәтми, аларны яклый һәм зарар күрми, Азәрбайҗанны һәм Грузияне буйсындыру өчен, бергә сугышка да бара. VII гасыр уртасында, Беренче Төрки каһанлыгы таркалганнан соң, хәзәрләр үз дәүләтен — Хәзәр каһанлыгын төзи. Каһан итеп Ашина ыругы кешесе куела, һәм Хәзәр дәүләтенең җитәкче үзәге дә Ашина ыругында тупланa. Килеп чыккан вазгыять хәзәрләр өчен отышлы була. Түркүтләрдә дәүләт белән идарә итү тәҗрибәсе, хәзәрләрдә сугышчанлык һәм үз мөстәкыйль дәүләтен төзергә омтылыш була. Хәзәр дәүләтенең башкаласы — Дагстандагы Сәмәндәр шәһәре, соңрак Иделнең түбән агымындагы Итил шәһәре була. VII гасыр уртасында хәзәрләр бортасларны, Азов буе болгарларын һәм Дагстандагы савирларны буйсындыра. Кавказ Албаниясе хәзәрләргә ясак түли.

VIII гасыр башында хәзәрләр Төньяк Кавказны, бөтен Азов буен, Кырымның күп өлешен, шулай ук Көнчыгыш Европаның дала һәм урман-дала территориясен били. Хәзәр дәүләтенә кергән кабиләләр төньякта Идел — Кама тамагына кадәр җирләрне үз кулы астына



Бөек Болгар дәүләте картасы (618—666 *еллар*). Чыганак: Татарский энциклопедический словарь, 1999

ала. Хәзәрләр Урта Днепрдагы көнчыгыш славян җирләрен буйсындырып тота. 735 елда көньяктан һөҗүм итеп, гарәпләр Хәзәр каһанлыгы армиясен тар-мар итә. Каһан һәм аның якыннары ислам динен кабул итә. Яңа дин халык арасында да тарала. VIII гасыр уртасында хәзәрләрнең бер өлеше иудаизм кабул итә.

Хәзәрләрнең төп шөгыле күчмә терлекчелек була, Түбән Иделдә һәм Идел белән Дон арасында яшәүче хәзәрләр, игенчелек, бигрәк тә бакчачылык, карбыз-кавын үстерү белән шөгыльләнеп, утрак тормыш алып бара. Анда утрак торак урыннар барлыкка килә. VIII гасырның икенче яртысында Хәзәр каһанлыгы Византия белән мөнәсәбәтләр урнаштыра, хәзәрләргә аннан христианлык килеп керә. IX гасыр ахырында Хәзәр каһанлыгында иудаизм дәүләт дине була, ләкин бу динне күбесенчә өстен катлау тота, күп хәзәрләр ислам динендә була. Византия күчмә халыкларны Хәзәр каһанлыгына каршы котырту сәясәте алып бара, бу аның көчсезләнүенә китерә. IX гасыр уртасында Хәзәр каһанлыгына бәҗәнәкләр һөҗүм итә. 964 елда аңа Русь кенәзе Святослав җимергеч һөҗүм ясый, аннан соң бу дәүләтне угызлар җимереп бетерә. X гасырда Хәзәр каһанлыгы яшәүдән туктый.

Кавказ алдында хәзәрләрдән башка болгарлар да яши. «Болгар» этнонимы тарихи чыганакларда 480 елдан билгеле. 480 елда Византия императоры Зенон болгарларга остготларга каршы көрәштә ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. IV—V гасырларда Үзәк Монголиядән Төньяк Казакъстанга кадәр булган зур территориядә төрки телле угыз кабиләләре яши, аларның бернинди дә берләшмәләре булмыйча, вак төркемнәрдә таркау көн итәләр. Борынгы төрки телдә «з» һәм «р» авазларын алмашып куллану очраклары була. Угызларның берничә төркеме «огур» дип аталып китә. Алар арасында «сарогур» (ак огур), «оногур» (ун огур) һ.б. кабиләләре була. V гасыр башында бу кабиләләр Иделнең көнбатышына күчә, аннан Азов буена килеп, һун-акацирларны куып җибәрә, Византия белән килешеп, шул җирләрдә урнаша. Болгарлар утургур, унногундор, оногур һ.б. төркемнәрдән тора, алар Кубаньның уң ягында Донга кадәр арада яши. VI гасыр уртасында Түбән Дон һәм Түбән Днепр тирәләрен болгар-кутургурлар били. Византия болгар-кутургурларның Фракиягә һөҗүмнәреннән җәфа чигә һәм бүләкләр белән дә, төрле мәкер белән дә болгар-утургурларны кутургурларга каршы хәрби хәрәкәтләргә котырта. Шул юл белән ул ике тугандаш халыкны кырып бетерә яза.

Утургурлардан көнчыгышта сугышчан савир (яки сабир) кабиләсе яши. Борынгы заманда алар Себердә яшәп, б. э. башында аннан, үзләренең серле исемен гаять зур илнең — Себернең атамасы итеп

калдырып, көнбатышка китә. Сабир-савирларның этник мөнәсәбәте хәзер дә галимнәр арасында бәхәсле булып кала бирә, ләкин сабирларның төрки чыгышлы булуын исбатлаучы дәлилләр күбрәк. VII гасырда алар Иран белән сугыша. Сабирларның калдыклары хәзерге көндә Дагстанда яшәүче төрки халыкларның берсе — кумыклар составына кушыла. 626 елда Кавказда дөнья сугышы җәелә, бу сугышта Иран, әрмәннәр, Ираклий җитәкчелегендә грузиннар, Византия, аварлар һәм Көнбатыш Төрки каһанлыгы катнаша. Соңгысы Грузияне буйсындыра, Әрмәнстанга һөҗүм итә. Ләкин тиздән Көнбатыш Төрки каһанлыгы өчен күңелсез хәлләр башлана. Көнчыгыш түркүтләр аның Кара Иртеш буендагы җирләрен тартып ала, карлуклар баш күтәрә. Дулу кабиләләре күтәрелә. Дулуларның ханы Кюмо Себер хан була. Аларга Кытай кире мөнәсәбәттә тора, ул түркүтләрнең хакимияттән төшүен һәм династияләре алмашуын теләми.

Көнбатыш Төрки каһанлыгының кыенлыкларыннан файдаланып, болгар-унногундорлар юлбашчысы Кубрат үзенең дипломатик сәләтләре белән күтәрелеп китә. 610 елда ул Византиягә бара, патрикий дәрәҗәсе ала, ләкин чукынудан баш тарта[38]. Кубрат көчсезләнгән түркүтләрдән котыла. Каһанлыкның үзәге ерак булудан файдаланып, Кубрат мөстәкыйль хөкемдар булып китә, 635 елда аварларны җиңә һәм Константинопольгә илчелек юнәлтә. Император Ираклий аңа бүләкләр җибәрә. Тиздән аварларга каршы кутургурлар баш күтәрә, аларны Кубрат яклый, ул Кара диңгез буйларындагы далаларның хуҗасы һәм кутургурларның да, унногундорларның да юлбашчысы булып китә.

Җиңелгән аварлар болгар-кутургурларга карата җиңелгән халык кебек карый. Кутургурлар аварларга каршы баш күтәрә, ләкин җиңелә, кутургурларның бер өлеше көнбатышка, Бавариягә таба китә, ләкин аларның юлы франк короле Дагобер тарафыннан киселә.

Шулай итеп, төрле болгар кабиләләре Кара Иртештән Кара диңгез буена килеп берләшә, зур болгар халкы барлыкка килә. Көнчыгышта Болгар дәүләте дошман хәзәрләр белән, көнбатышта аварлар белән, көньякта Византия белән чиктәш була. Кубрат Болгарны бөек держава дәрәҗәсенә кадәр күтәрә. Бөек Болгар 679 елга кадәр яши. Кубратның биш улы болгар җирләрен һәм кабиләләрен үзара бүлешә. Алар арасыннан иң билгелесе Аспарух, үз кабиләдәшләрен Дунай буена алып китеп, 679 елда Болгария дәүләтенә нигез сала. Азов буе болгарларының икенче бер зур төркеме VIII гасырда Идел — Кама тамагына килә һәм, анда электән яшәгән төрки һәм фин-угор кабиләләрен берләштереп, тарихи әдәбиятта «Идел Болгары» дип йөртелгән дәүләткә нигез сала.

Тан империясенең агрессиясе Көнбатыш Төрки каһанлыгына да җитә. 658 —659 елларда ул Кытай гаскәре тарафыннан оккупацияләнә. 704 елда ул Кытайга бәйлелектән котыла, ләкин Кытай, Иран, Византия кебек дәүләтләрнең якынлыгы, шулай ук эчке каршылыклар Көнбатыш Төрки каһанлыгын 740 елда һәлакәткә китерә[39].

Борынгы төркиләрнең дәүләт һәм иҗтимагый төзелеше

VI гасыр уртасында Бөек Төрки каһанлыгы беренче булып Евразия материгының Бөек даласында яшәгән барлык кабиләләрне берләштерә. Бөек Кытай стенасыннан, аннан соң Сары диңгездән Кара диңгезгә кадәр һәм Амударьядан Ишимның югары агымына кадәр арада төрки дәүләт төзелү төрки телнең киң таралуына китерә. Төркиләрнең идарә итүче канатына — Ашина ыругына, ягъни түркүтләргә, бу гаять зур дәүләтне төзү җиңел булмый, әмма аның яшәүгә сәләтле социаль-сәяси системасы тагын да кыенрак формалаша. Түркүтләр аны төзиләр һәм «ил» («эл») дип атыйлар. Дәүләт белән идарә итүнең бу системасының үзәгендә «урда» — гаиләсе, хезмәтчеләре һәм, әлбәттә, сугышчылары белән хан идарәсе торган.

Түркүтләрнең баш идарәчесе «каһан» дип аталган. Каһан төркиләрнең бердәнбер алласы — Тәңренең җирдәге вәкиле саналган. Каһанның хатыны (qatun) зур вәкаләтләргә ия булган. Ул шулай ук Умай алиһәнең җирдәге вәкиле дип танылган[40].

Дәүләттә ябгу каһаннан соң беренче зат санала. Ул идарәче ыругтан була. Ләкин һәр ябгу тәхет варисы булмаган. Тәхет варисы «тәгин» дип аталган. Шад вазифасын каһан уллары (ханзадәләр) били. Дәүләттәге барлык вазифаларны Ашина ыругы затлары биләгән. Һәр кабилә өстендә каһанга гына буйсынган бәкләр торган. Бәкләрнең күбесе шул кабиләдән милек дәрәҗәсенә карап сайланган[41]. Түбән чиндагы башлыклар төрле ыругтан куелган, аларның сугышчылары һәм гаскәр башлыклары белән үз урдасы булган. Каһанлык төзелгән чорда анда ыруглык җәмгыяте хөкем сөргән. Ул патриархаль булган, левират тәртибе сакланган, ягъни тол калган хатын үлгән иренең туганына тормышка чыгу хокукына ия була. Балалар ата ыругыныкы саналган. Плано Карпини яза: «Һәркем күпме хатын асрый алса, шулкадәр тота; кайсы йөз, кайсы илле, кайсы ун, кайсы күбрәк, кайсы азрак, һәм алар әниләреннән, кызларыннан, шул әнидән туган сеңелләреннән башка барлык туганнарына өйләнә ала. Әтисенең башка хатыннардан туган сеңелләренә, шулай ук әтисе үлгәч, аның тол калган хатыннарына



VIII—X гасырларда Хәзәр дәүләте. Чыганак: История татар с древнейших времен, 2002

өйләнә алганнар. Энесе үлгән абыйсының хатынына өйләнергә мәҗбүр булган, бертуган энесе юк икән, нәселдән башка кече ир туганы тол калган хатынга өйләнергә тиеш. Башка барлык хатын-кызларга алар бернинди чикләүләрсез өйләнә һәм аларны әти-әниләреннән бик кыйммәткә сатып ала»[42]. Ирнең һәр хатынының үз йорты (тирмәсе) була. Хатын-кыз җәмгыятьтә чагыштырмача югары урын тоткан.

Төркиләр дәүләтендә һәм җәмгыятендә каттый иерархик система хөкем сөрә. *Ябгу* һәм *шад* кабилә башлыклары булалар. Алардан башка тагын *боерык* вазифасы да яши — болары каһанга буйсынган төркем башлыклары, аларга кайвакыт йомышлар кушыла. Бу системада янә *тарканнар* — ясак җыючылар эшли. Каһанлыкка

кергән кабилә башлыгы «элтебер» дип аталган. Тотык — тагы да ваграк төркем башлыгы. Кабилә башлыгы бәк буйсынуында кадашлар — гади ватандашлар торган. Кадашлар бергәләп кара будунны тәшкил иткән. Олыдан кечегә кадәр дәрәҗәле кешеләр төркеме будунны — җәмгыятьне тәшкил иткән. Түркләр үз җәмгыятен «түрк будун» дип атаган, үзләренең аңа керүен югары бәяләгән. Түрк будунның барлык кешеләре — ябгудан алып гади кадашка кадәр — түрк будун каршында аерым бурычлы булган. Аристократлар берләшмәсе һәм кара будун берләшмәсе «эл» дип аталган. «Түрк эле» — коллардан башка һәр кешенең хокуклары һәм бурычлары анык билгеләнгән дәүләт. Шулай итеп, Төрки дәүләт Афина дәүләте сыйфатларына ия була, ләкин аерма бар: Афинада колбиләүчелек җәмгыяте, ә төркиләрдә патриархаль коллык сакланган примитив иртә феодаль җәмгыять яши.

Борынгы төрки җәмгыять тигез хокуклылар җәмгыяте түгел, анда катлаулы сәяси буйсыну системасы була, ләкин төрле фикерлелеккә юл куелмаган. Билгеле бер яшькә җиткән яшүсмер ир затына «ир-ат» дигән титул бирелгән, бу — «сугышчы ир» дигән сүз. Ир-ат титулы билгеле бер сынауларны, шартларны үткәч кенә бирелгән (мәсәлән, аудагы уңышы өчен), шуңарчы аның гомуми исеме булса да, ир-ат титулы белән бергә аңа яңа исем — ир-ат исеме бирелгән. Шуннан ул сугышчы була[43]. Ир-атның иҗтимагый дәрәҗәсе аның байлыгына, нәселенә бәйле була. Курганнар, каберлекләр каһанлыкта милек тигезсезлеге зур булуны раслый. Кардәшлекнең бик төгәл системасы яшәгән: огул — ул, кыз огул — кыз, эне — эне, ачи — абый, сеңел — сеңел, ана — өг, карендәш — кан-кардәш. Әсир балаларны һәм кәнизәк балаларын уллыкка, кызлыкка алып булган. Документларда «үз оглум» яки «казгакум оглум» (сатып алган улым), Орхон язуларында «адаш» (адаш), «йолдаш» (юлдаш), «кадаш» (ияргән кеше, иптәш) дигән терминнар очрый[44]. Әлеге сүзләрне хәзерге татар әдәби китабыннан алынган диярсең. Бу терминнарның барысының да диярлек мең ярым елдан соң да бүгенге татар әдәби телендә кулланылуы, беренчедән, аларның күп гасырлар актив кулланылышта булуын күрсәтсә, икенчедән, бүгенге татарларның нәсел башы кая барып тоташуын, этногенезыбыз тамырлары тирәнлеген раслый. Шул ук хәл Себер татарлары диалектларына да хас. Бу фактор үз нәүбәтендә бүгенге татарларның килеп чыгышын монголдан эзләүчеләрнең авызын томалаучы дәлил булып тора.

Каһанлыкта ирекле терлекчеләр, игенчеләр һәм һөнәрчеләрдән башка коллар да була. Ир колларны «кул» дип (бүгенге кеше кулы мәгънәсендә), хатын-кыз колларны «көн» дип атаганнар. Хәзерге

татар телендәге «көнлекче» сүзе шул заманнан сакланып калган булырга тиеш. Мәгънәсе дә үзеңә түгел, кешегә эшләүне аңлата. Колларның чыганагы сугыш әсирләре булган, бурыч коллыгы да яшәгән. Әгәр сөн җәмгыятендә коллар сату булмаса, төркләрдә исә мондый гадәт яшәгән, ләкин ил эчендә генә. Коллар хәрби һәм көнкүреш хезмәтләрен башкарган. Ләкин хәрби хезмәттә алар сирәк, ирекледәр күзәтүе астында гына файдаланылган. Аларны саклану корылмалары төзелешләрендә, игенчелектә һәм башка хезмәтләрдә файдаланганнар. Төп җитештерүче кол түгел, ә кара будун булган. Төрки җәмгыятьтә колбиләүчелекнең үзенчәлеге хатын-кыз колларның күп булуыннан гыйбарәт. Алар йорт эшләрен караган, көтү дә көткән, иҗтимагый статусы буенча кол хатын-кызлар ирекледәрдән аз аерылган. Алар гаиләдә, иҗтимагый тормышта ирекле хатын-кызлар кебек үк катнашкан. Ирләр арасында да коллар булган, ләкин алар күп түгел. Бу җәмгыятьнең куркынычсызлыгы өчен шулай эшләнгән, чөнки ирләр корал йөрткән, ә кораллы ир хәтәр кеше саналган.

Борынгы төрки җәмгыятьтә хатын-кызның роле зур була. Алар ирләргә караганда күбрәк эшләр башкарган. Бу — күчмә тормыштагы барлык халыклар өчен дә хас күренеш. Терлек көтү ирләр эше булса да, бу хезмәтне еш кына хатын-кызлар да башкарган. Алар күп санлы дөяләрне, бия һәм сыерларны, сарыкларны сауган, сөттән көндәлек һәм киләчәк өчен ризык әзерләгән, тиредән, күннән өс-баш һәм аяк киеме теккән, киез баскан, азык әзерләгән, балалар тәрбияләгән, күп санлы йорт эшләрен башкарган. Шуңа күрә хатын-кызның иҗтимагый роле дә зур булган. Борынгы төркиләрдәге левират тәртибе — ире үлгән хатынга энесе өйләнү, ягъни аны ялгыз калдырмау — моның ачык дәлиле. Сәяхәтче Плано Карпини һәм Гильом Рубрук язмалары, этнографик һәм археологик материаллар боларны ачык раслый[45].

Каһанның һәм боерыкларның төп вазифасы халыкның «тамагын туйдыру» булган. Орхон язмалары бу турыда күп тапкыр искә ала. Үлгән каһан турында «ул үз халкын яхшы туендырып торды» дигән сүзләр иң зур мактау булып яңгыраган. Төрк будунының үз каһанына төп таләбе Билге каһан язмасында күрсәтелә: ул «көндез эшсез утырмаска, төнлә йокламаска тиеш». Билге каһанның киңәшчесе акыллы Тоньюкук, эшлексез каһан халыкның бәласе дип саный. Йоллыг тәгин һәйкәлендә аның Беренче Төрки каһанлыгының җимерелү сәбәпләре турындагы уйлары китерелә: «Патшалыкка акылсыз каһаннар утырды, патшалыкка куркак каһаннар утырды! Ә аларның боерыклары акылсыз да, куркак та булды!»[46].

Дәүләтнең кереме бәкләр биргән натураль ясактан тупланган, алар аны үз ыругларыннан җыйган. Казнага сугышта алынган ганимәтнең бер өлеше кергән. Дәүләткә сәүдәдән дә керем килгән, ләкин ул күп булмаган. Илнең үз акчасы булмаган, илдә натураль алмашу хөкем сөргән[47]. Шулай да читтән кергән акчаларны да файдалану булган, ахры, чөнки казылма хәзинәләрдә гарәп, кытай тәңкәләре очрый.

Хәрби хезмәт ыругтагы сәламәт ирләрнең төп бурычы саналган. Игенчелек һәм йорт һөнәрчелеге белән берләшкән терлекчелек хуҗалыкның төп формасы булып торган. Һөнәрчелек белән нигездә кыш көне шөгыльләнгәннәр. Гаилә иң кечкенә икътисади берәмлек саналган. Һәр гаиләнең үз хосусый милке — җире һәм терлеге булган. Коллар һәм кәнизәкләр дә гаилә әгъзасы дип саналган. Үзенең икътисади хәле буенча ярлы (чигайлар) һәм бай гаиләләр булган.

Каршылыксыз буйсынган халыклар, үз ханнарын саклап, элекке тәртип белән яши. Алар ясак түләп кенә калмаган, төркиләрнең хәрби походларында да катнашырга тиеш була.

Феодаль Кытайның күрше булуы һәм ярты гасырлык аңа буйсыну (630—680) төркиләрнең иерархия системасына йогынты ясый.

Гаять зур илнең төрле почмакларыннан каһаннарга ясак формасында зур байлык керә. Л. Н. Гумилев Бөек Төрки каһанлыгында халыкка ясак салу системасы турында әрмән тарихчысы Моисей Каванкатваци сүзләрен китерә: «Төньяк кенәзе...алтын юу, көмеш, тимер чыгару һәм бакыр эшкәртү буенча белемнәре булган һөнәрчеләр янына тикшерүчеләр җибәрә, ул товарлардан һәм бөек елгалар булган Кура һәм Аракста балык тотучылардан пошлина, бер үк вакытта Персия патшалыгының гадәти халык санын алу нәтиҗәләре буенча акчалата ришвәт таләп итә»[48]. Аннан башка ике Кытай дәүләте Бөек Төрки каһанлыгына һәр елны ясак түли, Иран һәм Византия солых яки берлек өчен компенсация түли[49].

584 елда Көнбатыш Төрки каһанлыгына барган Византия илчесе Менандр Истәми каһанның гаять зур байлыкларын тасвирлый: «Каһан төрле ефәкләр белән бизәлгән чатырда утыра. Дизавулның (Менандр Истәмине шулай атый) тәхете бөтенләй алтыннан эшләнгән. Бу бинаның уртасында алтын савытлар, су фонтаннары һәм кисмәкләр була». Икенче көнне аларга алтын һәм көмеш әйберләр белән тулган башка бүлмәләрне күрсәтәләр[50]. Ыруг башлыклары да күп байлыклар туплый. Каһанның идарә урыны Алтайдан Орхон елгасына күчерелә. Каһанлыкта даими, хәрби демократия саклану белән бергә, иртә феодаль мөнәсәбәтләр

башлана. Байлыкның бәкләр кулында тупланыуы 582—603 елларда ыруг аристократиясенең көчәюенә һәм басып алынган территорияләр белән идарә итүгә омтылуга китерә, бу идарә итүче даирәләр һәм ыруг башлыклары арасында сәяси кризис һәм соңгылары арасында низаглар китереп чыгара.

Бөек Төрки каһанлыгының халкы

Бөек Төрки каһанлыгы этник яктан төрле кабиләләрне берләштерә. Аның үзәгендә Алтайның таулы районнарында урнашкан кабиләләр яши. 536 елда алар үз составына теле кабиләләрен ала. Теле кабиләләре үз нәүбәтендә Алтайдан көньяк-көнбатышта тардушлар коалициясе белән күрше булып яшәүче берничә кабилә коалициясен тәшкил итә. Соңрак теле кабиләсеннән уйгырлар, дубо, курыкан, теленгит, байырку һәм гяньгуньнәр (Енисей кыргызлары) аерылып чыга.

Бөек даланың башка регионнарында да төрки телле кабиләләр яши. Кара Иртеш һәм Урунгу бассейнында карлуклар (төркиләрнең бер өлеше) көн итә. Үзәк Тянь-Шаньдагы Или елгасында түргешләр, алардан көнбатышка карлуклар, Көньяк-Көнбатыш Джунгариядә нешетлар, Манас елгасында һәм алардан көнчыгышта хулушлар, Джунгариянең көнчыгышында басмаллар һәм шунда ук шатолар — Урта Азия сөннәре калдыклары яши[51]. Орхон язмаларында Урта Сырдәрьяда яшәүче кенгерес (бәҗәнәкләр) һәм түргешләр искә алына. Кара Иртештән Сырдәрьяга кадәр күп санлы кыпчак кабиләләре яши. Алар турында иң борынгы Кытай чыганаклары яза, һәм Кытай тарихчылары аларның килеп чыгышын динлиннар белән бәйли, ә кыпчакларның ватаны итеп Ордосны — Хуанхэның төньяк ярын күрсәтә[52].

Урта Азиядә борынгы заманнардан алып төрки кабиләләр яши. Төрки халыкларны тикшерүче галим Б. Х. Кармышева язуы буенча, моннан 1200 ел элек — VII—VIII гасырларда түркүтләр килгәнче хәзерге Үзбәкстан территориясендә төрки кабиләләр яшәгән, аларның варислары әле дә үзбәкләрдән аерымланып, үзләрен Көнчыгыш Татарстаннан чыккан дип ышанып яши[53].

Минуса казанлыгында кыргызлар көн күрә. Кыргызлардан төньяктарак, Көньяк һәм Көнбатыш Себернең урман-далаларында б.э. дан күп алда төрле халыклар яшәгән: б.э.к. VII—V гасырларда — скиф берлеге кабиләләре, б.э.к. III гасырдан б.э. ның IV гасырында — сармат берлеге кабиләләре. Археологларга сөнсармат чорында, б.э. чигендә, төрле чыгышлы, төрле антропологик типтагы һәм үзенчәлекле археологик мәдәниятка ия булган этник

кабиләләрнең төрки телле булуы якынча билгеле. Монда үзара яки башка телле этнослар белән аралашып көн күрүче конкрет төрки телле этник төркемнәр һәм халыклар яшәгән. Бу кабиләләр кушыла, аерыла, яңалары ясала. Мондый этник процесслар Бөек Төрки каһанлыгы чорында да барган. Ләкин, югарыда әйтелгәнчә, аларны берләштерүче «төрки» дигән гомуми исемнәре булмый. Барлык төрки телле кабиләләрне берләштерүче атама аларны Ашина ыругы тирәсенә туплагач барлыкка килә[54].

Олы төрки дөньяның якын булуы Көнбатыш Себергә төрле төрки кабиләләрнең үтеп керүенә китерә. Билгеле, бу регионда төрки кабиләләр генә яшәмәгән. Археолог А. П. Окладников болай дип яза: «VIII гасырда Себернең этник төрлелеге XVIII гасырга караганда күпкә зуррак иде. Моннан 2000 ел элегрәк интенсив үсеш юлында торган күп санлы халыкларның калдыклары бар иде»[55].

Кытай традицион тарихы ту-кюларны сөннәр белән бәйли. Төркиләрнең сөннәр белән турыдан-туры бәйләнешен күреп булмый. Төрки язма чыганакларда төркиләрнең сөннәр белән бәйләнеше турында искә алулар юк. Сөннәр белән түркүтләрнең тотемнары да туры килми. Сөннәрнең тотемы үгез, ә түркүтләрнеке бүре булган. Шулай булса да Кытай чыганаклары түркүтләр белән сөннәрнең элемтәләрен раслый.

Кайбер төрки кабиләләрне берләштерүче исем — угыз (үгез) аларны берләштерүче чылбыр булып тора. Шәркый Төркестанда һәм тирә-яктагы кайбер өлкәләрдә өч-угыз һәм тугыз-угыз кабиләләре яши. Өч һәм тугыз — кабиләдәге ыруглар санын күрсәтә. Угызлар үзләре теле кабилә конфедерациясендә булганнар. Төрки кабиләләрнең килеп чыгышы катлаулы, ул бер чорда гына бармаган, төрле чорларга сузылган. Кайбер төрки кабиләләр сөннәр заманында булган инде, ә кайберләре соңрак, сөннәрнең башка кабиләләр белән кушылуыннан ясалган. Төрки телле кабиләләрнең күп булуына карамастан, әйткәнебезчә, сөннәр заманында да, алардан соңрак та бу кабиләләрне берләштерүче берлек тә, гомуми исемнәре дә булмаган. Ашина ыругы төрки телле кабиләләрне берләштергәч кенә, «төрки» аларны берләштерүче гомуми этноним булып китә.

Бөек Төрки каһанлыгына кергән иң борынгы кабиләләр арасында билгесез телле үсүннәр һәм монгол телле сяньбиләр була. Алар сөн заманыннан ук билгеле кабиләләр. Жужаннар соңрак Кытай качкыннарыннан формалаша, алар монгол теле ала. Көнбатыш Монголиядә монгол төркеменнән булган киданнар яши. Төрки каһанлыгын түркүтләр төзи, аны турыдан-туры төзүчеләр эченә угызлар, карлуклар, гяньгуньнәр (Енисей кыргызлары),

тардушлар, толеслар, чиклар, түргешләр, уйгырлар һәм аз санлы тонгралар, басмаллар кергән.

Көнчыгышта Ашина ыругы вәкилләре — түркүтләр күбрәк яши, алар монда берләшкән этник төркем була. Көнбатышта башкачарак вазгыять күзәтелә. Төрки телле кабиләләрнең зур массасы арасында түркүтләр бик аз булган. Әмма үзләренең тупланган булулары белән түркүтләр Җидесу, Урта Азиянең, Каспий буе һәм Кавказ төркиләрен берләштерә ала. Каһанлыкның көнбатышында түркүтләрдән башка да бу чорда көчле төрки кабилә берлекләре яши. Көнбатыш Джунгариядәге һәм Җидесудагы дулу, Көнбатыш Тянь-Шаньдагы нушиби кабилә берлекләре әнә шундыйлардан санала. Икесе дә нык берләшкән, көчле була, шулай да алар түркүтләр җитәкчелеген таный[56]. Борынгы авторлар түркүтләрнең буйсындырылган халыклар белән уртак тел таба алу сәләтен билгеләп үтәләр. Каһанлыкка каршы сугыш белән килгән гарәпләр дә түркүтләрнең сугышып алынган җирләрдә яшәүче халыклар белән уртак тел табу осталыкларына сокланалар[57].

Түркүтләрнең Урта Азияне яулап алу чорында бердәм сәяси хакимиятнең булмавына карамастан, Согдиана икътисади яктан чәчәк ата, бигрәк тә игенчелек үсә.

Яңа җирләр басып алу һәм империянең мәйданын зурайту белән түркүтләр дәүләт язмышын хәтәр хәлгә куя. Андый зур дәүләт белән идарә итү һәм аның куркынычсызлыгын саклау җиңел булмый.

Үзәк Азиядә, Төньяк Кытайда, Көнчыгыш Европада һәм Якын Көнчыгышта тарихи вакыйгаларның барышын анализлаганнан соң, Л. Н. Гумилев, VI—VII гасыр чикләрендә бу регионнарда пассионар күтәрелеш күзәтелгән, дип яза. Кешеләрнең активлыгы үсә, алар иске социаль һәм этник киртәләрне җимерә, яңа этносларга оеша, яңа дәүләтләр барлыкка килә. Европаның, бигрәк тә Азиянең бу зур регионының сәяси картасы үзгәрә[58].

Борынгы төркиләрнең хуҗалыгы

Бөек Төрки каһанлыгы халыкларының хуҗалык тормышы күп тармаклы була. Ашина түркүтләренең төп эше тимер чыгару икәнен инде без беләбез. Көньяк Алтайның төрки телле халыклары Ашина ыругы килгәнче дә тимер чыгару, аннан төрле әйберләр эшләү, сугыш кирәк-яраклары һәм ат дирбияләре ясау белән шөгыльләнә. Болар беренче нәүбәттә жужан ханы таләбе белән эшләнә. Төркиләр даими рәвештә үз азатлыкларына әзерләнә. Аларның күпчелеге металлургия белән, билгеле бер өлеше терлекчелек белән көн күрә. Бераз ныгып киткәннән соң, төркиләр тимер әйберләрне

кытайлардан ризыкка алмаштыра. Ә йөз еллык әзерлектән соң баш күтәрәләр һәм жужаннарны җиңәләр.

Каһанлык чорында да металлургия Алтайда яшәгән төркиләрнең төп шөгыле булып кала, әмма терлекчелек, игенчелек, йорт һөнәрчелеге һәм сәүдәнең үсүе нәтиҗәсендә тимердән әйберләр эшләү бераз кими. Тимер Минуса казанлыгында да чыгарыла. Металлургия үсү нәтиҗәсендә каһанлык куәтле атлы гаскәр тота[59]. Алтайда, Минуса казанлыгында һәм тирә-як регионнарда яшәгән төркиләр бик оста металлурглар булган. Алар бик югары сыйфатлы чистартылган тимер коя. Аннан бик күп әйберләр, җиһазлар, беренче нәүбәттә сугыш, эш һәм аучылык кораллары ясыйлар. Күбә киемнәр эшлиләр. Башлыкларның күбәсе алтын һәм көмеш белән бизәлә. Металлургия үсү аркасында, төркиләр армиясе Евразиядә беренче урынга чыга. VI—VIII гасыр каберлекләрен казып тикшерү Орхон төркиләрендә тимерчелекнең һәм металлургиягә бәйле башка һөнәрләрнең югары дәрәҗәдә булуын раслый. Югары сыйфатлы корал — сызгыра торган уклар, сөңгеләр, кылычлар, хәнҗәрләр, ат япмалары һәм дирбияләре — барысы да шул заман дала техникасының югары үрнәкләре булып тора. Археологлар тапкан сука төрәннәре сөрүле игенчелек үсүне раслый.

Алмашу өчен тимер әйберләр ышанычлы валютага әверелә. Аларны күрше дәүләтләрдә дә кирәкле әйберләргә, бигрәк тә икмәккә алмаштыралар. Алтын эшләнмәләр әзерләү югары дәрәҗәгә күтәрелә. Каһаннарда, бәкләрдә һәм башка өстен катлауда бу кыйммәтле металл күп була. Алтын Алтайда табылган, ул ясак өчен һәм Бөек ефәк юлында пошлина өчен алынган[60].

Хәрби хезмәт төркиләрнең барлык катлауларының да төп эше була. Походларда алар якынча елга ике-өч тапкыр катнашкан. Калган вакытта хуҗалык эшләре, ягъни күчмә һәм ярым күчмә терлекчелек белән шөгыльләнгәннәр. Күбрәк ат, сарык асраганнар. Мөгезле эре терлек күченү өчен уңайсыз булган, чөнки ул кышын кар астыннан азык таба алмаган. Кар аз яткан урыннарда терлекләрне күп асраганнар. Ләкин һәр җирдә беркадәр сыер терлеге тотканнар, чөнки кыйммәтле продукт — сөт кирәк булган. Дөя дә асраганнар. Төркиләр өчен ат транспорт чарасы гына булмаган, ул туклыклы ит һәм сөт биргән, ат сөтеннән кымыз ясаганнар.

Кытай тарихчылары төркиләрне тик күчмә терлекчеләр итеп кенә белә, алар көнкүрешенең башка яклары Кытай елъязмачыларын кызыксындырмаган диярлек. Башка шөгыльләр турында елъязмачылар күчмә тормышны тасвирлаганда гына мәгълүмат бирә. Кытай елъязмаларында терлек, күчмә киез өйләр, күчмә тормыш

рәвеше турында мәгълүматлар урын алган. Төркиләрнең күчмә тормышта яшәүләрен археологик материаллар да раслый. Аларда иярләгән ат белән җирләү йоласы яшәгән. Теге дөньяга төркиләр ат белән китәргә тиеш була.

Җәен терлек болыннарда көтелгән, кышын кышлауларга китерелгән. Археологлар Минуса казанлыгыннан башка урыннарда терлек азыгы әзерләү кораллары тапмадылар. Хуҗалыкта әһәмияте буенча беренче урында, әйткәнебезчә, ат тора. Сарык терлеге дә төркиләрдә әһәмияте ягыннан әллә ни калышмый. Төркиләрдә нигездә күчмә терлекчелекнең аил системасы кулланылган, һәр гаиләнең үз җирләре булган, һәм ул анда гаиләсе белән күчеп йөргән. Чик буендагы хәтәррәк урыннарда күчмә терлекчелекнең стан системасы кулланылган: берничә гаилә, берләшеп, терлекне бергә көтә, тирмәләрне һәм терлекне төнлә арбалар белән әйләндереп алалар һәм сакчылар куялар.

Без Пазырык чорында Алтайда игенчелек булган һәм кырларны сугару өчен ирригация системалары төзелгән дип әйткән идек. Һичшиксез, игенчелек каһанлыкта билгеле бер роль уйнаган. Игенчелекнең үсүенә кабиләләрнең Пазырык чорыннан калган мирасы булыша.

Кытайдан бәйсезлекне саклау өчен, каһаннар элекке китмәнле игенчелекне Кытайдагы кебек сөрүле итәргә тырыша. Мәсәлән, Мочжо каһан чәчү өчен кытайлардан 100 000 ху тары һәм 3000 җир эшкәртү кораллары таләп итә. Байкал артында һәм Енисейда кытайларның чуен сука калаклары табылуы каһанлыкның иң төньяк районнарында да Кытайның җир эшкәртү техникасы кулланылуы турында сөйли. Эшкәртелә торган җирләр беренче нәүбәттә кышлаклар тирәсендә булган дип уйларга нигез бар. Моны, сирәк булса да, утрак тораклык эзләре күрсәтә[61].

Аучылык әһәмиятле урын тоткан. Археологик табылдыклар төркиләрнең эре һәм кыйммәтле тиреле җәнлекләр аулавын күрсәтә. Әлеге җәнлекләр аларны ит һәм тире белән тәэмин иткән. Кыйммәтле тиреләр товар алмашу өчен дә кирәк була. Кытайлар белән төркиләр алмаш сәүдә алып барган, тире һәм итне икмәккә, көнкүреш әйберләренә алмашкан.

Аучылык ысуллары бик күп төрле була: ук ату, капкыннар, алдавычлар, үзаткычлар куллану. Төркиләр Азия далаларында күмәк ау белән шөгыльләнә.

Минуса казанлыгының һәм Харәземнең буйсындырылган кабиләләрендә игенчелек, шул исәптән сугарулы игенчелек алга киткән була. Кудыргэ курганында табылган балык сурәте төшерелгән ияр төркиләрнең балык тоту белән шөгыльләнүен раслый.

Төсле металлардан: бронза, көмеш, алтын эшкәртү югары дәрәҗәдә була. Алардан затлы бизәнү әйберләре һәм ат дирбияләре өчен бизәкләр эшләнә. Археологлар шулай ук таштан һәм сөяктән ясалган бизәнү әйберләре таба[62].

Каһанлык аша Бөек ефәк юлы узган, ул дәүләт күзәтүе астында торган. Ефәкне төркиләр Кытайдан алган. Беренче Төрки каһанлыгына ике Кытай дәүләте — Бей-Чжоу һәм Бей-Ци бик теләп хәрби ярдәм өчен яки хәтта нейтралитет өчен ясак түли. VI гасырда ефәк валюта була һәм алтын кыйммәтле ташлар белән бер дәрәҗәдә бәяләнә[63].

Бөек ефәк юлы — б.э.к. II гасырда ачылган, Кытайдан Урта һәм Алгы Азия илләренә илтүче кәрван юлы була. Ул Көнбатыш белән Көнчыгышны тоташтырган, Чаньаньнан башланган һәм Наньшан тау итәкләреннән Турфанга, аннан Гаочанга алып барган. Гаочаннан ефәк юлы икегә аерыла. Төньяк юл Турфан аша китә, Памирны үтеп, Фирганәгә һәм Казакъ далаларына килә, Яркенд аша Бактриягә килә. Көньяк юл — Гаочаннан Көньяк Джунгария буенча Урумчи аша Урта Азиягә — Или елгасы үзәненә, аннан Хорасанга, Сүриягә һәм Константинопольгә килгән. Сары диңгездән юл Гератка кадәр 150 көнгә сузылган, аннан Рим чигенә кадәр 80 көн барылган. Бөек ефәк юлы төрле дәүләтләрнең икътисади һәм мәдәни үсешендә зур урын тоткан[64].

Бөек Төрки каһанлыгы чорында халык бик байый. Байлык әрәм ителми, бүлгәләнми, зур гаиләләрдә туплана.

Бөек Төрки каһанлыгында халыкның бер өлеше утрак авылларда сөрүле игенчелек һәм көтүле терлекчелек белән шөгыльләнеп яши. Алар бодай, арпа, тары, киндер, арыш игәләр[65].

Күлтәгин, Билге каһан, Тонъюкук һәйкәлләрендә шундый терминнар кулланылган: балык — шәһәр, балыкдакы — шәһәр кешесе, барк — бина. Шулай ук башкала һәм гыйбадәт йорты төзү турында да язылган[66].

Йорт һөнәрчелеге үскән. Агач эшкәртү белән шөгыльләнәләр: савыт-саба, тирмә араталары ясыйлар. Шулай ук керамик әйберләр дә эшләгәннәр. Хуҗалык натураль була, ләкин товар алмашу киң таралган. Кытай, Иран, Византия һ.б. илләр белән тышкы сәүдә нык үскән.

Утрак авыллардан башка урыннарда төркиләр йортлар төземәгән, тирмә һәм күчмә киез өйләрдә яшәгән. Урманлы районнарда яшәүче ярлы кабиләләр киез урынына каен тузы кулланган[67].

Төркиләрнең төп байлыгы терлек була, алар я эш өчен, я ризык өчен асралган, барысы да хосусый милек булган. Төп җитештерү

чарасы булган җирнең баш хуҗасы һәм бүлүчесе (каһан) илнең төрле төбәкләренә үз вәкилләрен билгеләгән. Сөрү җирләре аерым гаиләләргә бирелгән, башта вакытлыча, аннан бөтенләйгә, җирнең хосусый милеккә әверелүе әкренлек белән барган. Гаилә тора-бара моногамиялегә әверелә, аерым гаилә җәмгыятьнең бер кисәге булып китә. Зурлыклары һәм мәет янына куелган мөлкәтнең күләме белән бер-берсеннән аерылып торучы курганнар милек тигезсезлеге күрсәткече булып тора.

Сугышлар элек саклану өчен яки территорияне киңәйтү өчен алып барылган, ә Төрки каһанлыгы чорында талау чарасына һәм даими күренешкә әверелә[68].

Төркиләрнең төп ризыгы җәй көне сөт һәм сөт ризыклары булган. Аны кыш өчен дә әзерләп куйганнар. Кыш көне күбесенчә ит кулланылган. Утрак районнарда төп ризык икмәк булган. Ит һәм тирене күчмәннәр еш кына ярма һәм онга алмаштырганнар.

Борынгы төркиләр азык өчен ашарга яраклы кыргый үсемлекләрне һәм аларның тамыр һәм җимешләрен, орлыкларын киң файдалана. Мондыйлар арасында иң киң таралганы кандык була. Яз ахыры — җәй башында махсус тимер казыгыч белән аның тамырларын казып алганнар, аны чи килеш тә, пешереп, сөт белән дә ашаганнар, алдагы көн өчен киптергәннәр. Чыганаклар бу кыргый азыкның тәмле булуын хәбәр итә. Шулай ук сары һәм ак сарана суганчаларын җыйганнар, аны чи килеш, көлдә яки суда пешереп, сөт яки сыер мае белән ашаганнар. Азык өчен кырлык яки кыргый карабодай файдаланылган. Аны чәчеп тә үстергәннәр, кырлыктан он, ярма ясаганнар, аш яки ботка пешергәннәр. Урманлы, болынлы җирләрдә шомырт, чикләвек, төрле җиләкләр җыйганнар. Эчемлекләрдән сөт һәм кымыз, үлән кайнатмалары кулланылган. Төркиләр арпа һәм сөт аракысы ясаганнар.

Тарихи әдәбиятта борынгы төркиләрнең физик кыяфәтенең аерым аспектлары, чәч, сакал-мыек йөртү, кием, бизәнү әйберләре проблемасы еш кузгатыла. Ләкин фикерләр каршылыклы булып кала. Палеоантропологик тикшеренүләр көнчыгыштагы (Монголия, Байкал буе, Тыва) төркиләргә күбесенчә монголоид раса тибы, ә көнбатышта аларга европеоид кушылма хас булуны күрсәтә. Борынгы төрки таш скульптураларга катнаш физик тип чалымнары характерлы. Алар арасында без монголоидка караганда европеоид типны күбрәк күрәбез[69]. Тикшерүче галимнәрнең күпчелегенең фикере буенча, алар чәчне үреп йөрткән, аерым тикшерүчеләр төркиләр чәчне җилкәгә таратып йөрткән дигән фикерне куәтли. Таш сыннарның күбесе төркиләрнең сакал һәм мыек йөртүләренең шаһиты булып тора.

Сыннарның купчелегендә баш киемнәре төрле: мех бүрек, киселгән конус рәвешендәге баш киеме, колакчын бүрек, шулай ук арты җилкәгә төшеп торган бүрек.

Төркиләр күннән һәм киездән эшләнгән кием кигән. Аяк киеме дә күн булган. Тукучылыкны белгәннәр, урыны белән табигый сүстән (кычыткан сүсеннән) һ.б. әзерләнгән кием кигәннәр. Кием уңнан сулга төймәләнгән. Бронза, көмеш, алтын тәңкәләр, каптырмалар белән бизәлгән бил каешы төркиләр киеменең әһәмиятле өлеше булып торган. Бил каешы аны йөртүченең социаль хәлен күрсәткән. Аларның итекләре, мөгаен, Алтай төркиләре әле XIX гасырда кигән итектән әллә ни аерылмагандыр. Хатын-кызлар да, ирләр дә бронза, көмеш, алтын алка такканнар. Ир кешенең киеме билгә тагылган корал — хәнҗәр яки кылыч белән тулыландырылган[70].

Тирмә төзү өчен, агач конструкция һәм киез кулланылган. Урманлы районнарда яшәүче ярлы кабиләләр, тирмә ясау өчен, кайнар суда пешекләнгән каен тузын файдаланган.

Төркиләр тауда һәм далада сугышуга сәләтле даими атлы армия тоткан. Югары Енисей буе кыяларындагы рәсемнәргә караганда, төрки сугышчысы түбәндәгечә күзаллана: «Муеннан ботына кадәр тәңкәле көбә кигән авыр коралланган җайдак, көбәнең җиңе терсәк белән кулбаш уртасына кадәр җиткән, күкрәгендә түгәрәк калкан, путасында кылыч һәм ук садагы, уң кулында сугыш гөрзие»[71].

Чаа-таска төшерелгән бер сурәт С. В. Киселевның казу вакытында тапкан археологик материалны тагы да тулыландыра: «Баш киемсез җайдак... җилән бил каешы белән буылган. Үкчәсез йомшак итекләр. Уң ягыннан аска таба киңәюче ук садагы асылынып тора. М хәрефенә охшаш ук. Киң күкрәкле, күтәрелгән яллы, төенләнгән койрыклы ат. Ат өстендә дирбияле каты ияр. Сугышчының киемендәге тәңкәсе VIII гасырныкы»[72].

Төркиләр корал белән камил эш иткән, орышны, җитезлек һәм батырлык күрсәтеп, кул сугышына кадәр җиткергән. Сугыш эшенә мускулларның көчен һәм ук-җәя, сөңге белән эш итүдә җитезлекне арттырып, һәркем яшьтән әзерләнә. Гадәтләр кырыс, законнар катгый була. Халыкны кузгалышларга өндәү, хыянәт, үтерү, тышаулаган атны урлаган өчен үлем җәзасы бирелгән. Ирле хатынны көчләүдә гаепле кешене башта печкәннәр, аннан соң гәүдәсен урталай кискәннәр. Кызны көчләгән яки алдаган кеше аңа өйләнгән яки зур хак биреп котылган. Үзара сугышта зыян күрүче кеше каршы якның милкен яки хатыннарын һәм кызларын алган.

Төркиләрдә катлаулы иҗтимагый бүленеш күзәтелгән: ак һәм кара сөякләр. Ә сөннәрдә бу булмаган. Барлык идарә вазифалары нәселдән килгән. Гади нәселдән булган хатын-кызның өстен катлау

ир кешесе белән никахы рөхсәт ителмәгән[73]. Суй династиясеннән булган Кытай императоры төркиләргә шундый характеристика биргән: «Ту-кюның көче атта йөрүдә һәм ук белән атуда. Алар давыл һәм яшен кебек давыллыйлар, төпле хәрби тәртипне белмиләр. Ук һәм җәя — аларның тырнагы һәм теше, көбә һәм очлы тимер башлык — аларның көндәлек киемнәре. Алар кайда су һәм үлән таба, шунда туктый, сарык һәм атлары — аларның азыклары».

Борынгы төркиләрнең дине

Борынгы төркиләрнең дини тормышы турында Кытайның «Вэй-шу» һәм «Сэй-шу» (Вэй һәм Суй династияләре) елъязмалары хәбәр итә. Кытай елъязмачылары, мөгаен, төркиләрнең дини ышанулары турында аз белгәндер, шунлыктан аларның мәгълүматлары каршылыклы.

Бик борынгы заманнарда төркиләр, башка барлык халыклар кебек, мәҗүсилек чорын үтә. Каһанлыклар чорында аларның дине сөннәрнекеннән әллә ни аерылмаган. Төркиләрнең язма чыганаклары сөннәр турында бөтенләй искә алмый. Сөннәрдән соң да, һичшиксез, төрки җәмгыяте интенсив үсештә булган. Төрки каһанлыгының Кытай, Тибет, Иран, Кавказ, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Рим белән халыкара элемтәләре югары дәрәҗәгә күтәрелгән.

Төрки сәүдәгәрләре күрше илләргә сәүдә белән барган. Чиктәш дәүләтләр шулай ук каһанлык белән интенсив сәүдә иткән. Бу хәлләр төрки халыклар мәдәниятенә һәм диненә йогынты ясамый калмаган.

Төркиләрнең төп алласы Тәңре булган, ул Кояш культына, Күк культына нигезләнгән. Тәңре Орхон-Енисей язмаларында да күрсәтелә: «Башта зәңгәр күк булган, аста кара җир; алар арасында кеше уллары туган». Төркиләр үз аллаларын Күк Тәңре (Зәңгәр күк) дип атаган. Аңа һәр ел корбан итеп хайван чалганнар. Алга таба Күк рухы фарсыча Кудай (Ходай) исеме ала. Мәҗүсилектән аермалы буларак, тәңречелек бераллалыкка якын, ләкин ул тулысынча бер аллалы дин түгел. Тәңре белән беррәттән төркиләр алиһә (хатын-кыз алла) Умайга да ышанганнар. Әмма Тәңре барлык төркиләрнең баш алласы булган[74].

Олы алла борынгы төрки текстларында күренми торган һәм кешеләрнең көндәлек гадәти тормышына катнашмый торган Күк итеп тасвирлана. Умай кайвакыт уңыш алласы итеп тә күрсәтелә, ул тууны, хатын-кыз башлангычын гәүдәләндерә. Бу төркиләрнең чагыштыруларында да күренә: каһан — ата, Күк кебек; хатын — ана, Умай кебек.

Тәңредән башка төркиләр Ыдук Йер-Су (Изге Җир-Су) көченә ышана. Аңа мондый атрибутлар характерлы: а) игелеклелек функциясе: «...төркинең изге Җир-Суы болай диде: «Түрк халкы бетмәсен! Ул халык булып калсын!»; б) хөкем итү функциясе: «Күк, Умай, изге Җир-Су безне каһәрләр...»[75]. Борынгы төркиләр ышануынча, Җир асты дөньясына Эрклиг хан хуҗа була, ул үлем хәбәрчеләре җибәрә, кешеләрне аера. Шулай итеп, без борынгы төркиләрдә 4 төп олы алла барлыгын беләбез: Тәңре, Умай, Ыдук Йер-Су һәм Эрклиг. Тәңре баш алла саналган.

Аерым ыругларның Тәңре белән бергә җирле яклаучысы, ыруг алласы була, анысы мәҗүси дин йолаларына барып тоташа. Түркләр җанның үлемсезлегенә һәм үлгәннән соң яшәүгә ышанган. Ата-баба культы яшәгән. Дин башлыгын «кам» дип атаганнар. Бөек Төрки каһанлыгы чорында түркләрдә шаманлык булмый, Себер түркләренә ул күпкә соңрак — түрк дәүләтләре таркалганнан соң килеп керә.

Түркләрнең күмү йоласы үзенең катлаулылыгы белән аерылып торган. Мәетнең тәнен бәлзәмләп, чатырда саклаганнар, яз үлгәннәрне көз, көз үлгәннәрне яз күмгәннәр. Үлгән кешенең туганнары чатыр алдына аның атларын күмә һәм, чатырны җиде мәртәбә әйләнеп, кайгыларын белдерү өчен, кан чыкканчы йөзләрен тырнап, төркем булып җыела. Кайгы белдерү җиде көнгә сузылган. Күмү көнен кам билгеләгән. Мәетне аның яраткан аты өстенә урнаштырып, атны корбан итәләр һәм яраткан әйберләре белән мәетне дә, атны да яндырганнар, көлен күмгәннәр. Күренекле кешеләрнең кабере өстенә бина корганнар, анда аның сурәтен һәм шулай ук хезмәтләрен, сугышларын тасвирлаган таш плитә куйганнар. Кабер янына әлеге кеше тарафыннан үтерелгән дошманнары санынча таш плитәләр утыртып чыкканнар, аларны «балбал» дип атаганнар[76]. Бер аллалы дингә якын булган Тәңре динен тоткан түркләр ислам дине таралган чорда түрк булмаган мәҗүси күршеләренә караганда исламны җиңелрәк кабул итә. Түркләр үзләренең ыру башы итеп ак яки соры (күк) бүрене санаган.

Мәдәният

Бөек Төрки каһанлыгы төзелгәнче түркләр таркау була. Изоляциядән чыгып, берләшеп һәм үзләренең хәлләрен ныгытып, алар күп гасырлык мирас нигезендә үз цивилизацияләрен булдыра. Һәр түрк кабиләсе бу цивилизациягә — дәүләт төзелешенә, җәмгыять төзелешенә, хәрби төзелешкә, җисми һәм рухи мәдәнияткә үз өлешен кертә. Борынгы түркләр цивилизациясе дала тормышы таләпләренә яраклашкан һәм Кытай, Иран, Якын Көнчыгыш һәм

Борынгы таш балбал. Монголия. С. Г. Кляшторный фотосы

Европа цивилизациясеннән нык аерылган. Шул ук вакытта бу цивилизация даланың кырыс шартларында яшәүче кеше тормышының барлык таләпләренә дә яраклашкан була.

Кыска гына вакыт эчендә төркләр үз язуларын булдыралар. Урта Азиянең, Иранның, Византиянең һәм Кытайның борынгы цивилизацияләре белән һәртөрле мөнәсәбәтләргә кереп, тормыш тәҗрибәләрен баеталар, шул ук вакытта бу цивилизацияләр үсешенә дә йогынты ясыйлар. Лингвистикада һәм иҗтимагый фәннәрдә төрк цивилизациясенә карата сәеррәк караш хакимлек итә. Бу теория төркләрне үз ватаннарында автохтон түгел дип карый, аларның җисми һәм рухи мәдәнияте казанышларын чит цивилизацияләрдән (Ираннан, Европадан) алынган дип исәпли. Шактый гына тикшеренүчеләр төрк цивилизациясе чыганакларын төрк булмаган халыклар һәм кабиләләр арасыннан эзләде.

Борынгы төркләр мәдәниятенең иң югары күрсәткече — аларның язуы. Бөек Төрки каһанлыгында язу таралу дәрәҗәсен Орхон-Енисей язмалары күрсәтә. Күлтәгин һәм Билге каһан һәйкәлләре берсе икенчесеннән бер километрга якын ераклыкта урнашкан. Алар күмү корылмаларының бердәм комплексын тәшкил иткән. Анда әрвахлар рухына багышлап гыйбадәт кылу храмы да кергән, хәзер аның хәрабәләре генә калган. Әлеге храм һәм Күлтәгин стеласы (вертикаль куелган язулы таш плитә), Күлтәгин үлгәннән соң, Билге каһан соравы буенча кытайлар тарафыннан төзелгән. Күлтәгин 47 яшьтә 731 елның 27 февралендә үлә.

Күлтәгин һәйкәле 67,25 x 28,85 метрлы мәйданда урнашкан, канау белән әйләндереп алынган. Анда башка сыннар да куелган. Күлтәгин стеласы очы киселгән пирамида формасында, биеклеге — 3,15 м, нигез киңлеге — 1,24 м, калынлыгы — 0,41 м. Стеланың бер ягына кытай телендә текст уеп язылган, шунда ук һәйкәлне төзү датасы күрсәтелгән — 732 елның 1 августы, ә вакыйгалар 721 елга кадәр тасвирланган. Стеланың калган 3 ягына рун язулы текст уелган.

Борынгы төрки рун алфавиты

Язылышы	Мәгънәсе		Язылышы	Мәгънәсе	
	рус.	лат.		рус.	лат.
	а, ä	a, ä		н̆	ñ
	$б^{1}$	b^{1}		ңт	nt
	$б^{2}$, ä	b^{2}, ä		нч	nč
	ҕ	γ		о, у	o, u
	г	g		ö, ÿ	ö, ü
	$д^{1}$	d^{1}		п	p
	$д^{2}$	d^{2}		$р^{1}$	r^{1}
	з	z		$р^{2}$	r^{2}
	ы, i	y, i		$с^{1}$	s^{1}
	j^{1}	j^{1}, ĭ		$с^{2}$	s^{2}
	j^{2}	j^{2}, ĭ		$т^{1}$	t^{1}
	k	q		$т^{2}$	t^{2}
	к	k		ч	č
	$л^{1}$	l^{1}		ш	š
	l^{2}	l^{2}			
		lt			
		m			
		n^{1}			
		n^{2}			
		ŋ			

Күлтәгин һәйкәле язмасының бер кисәге

Кече язма



Билге каһан һәйкәле шундый ук зурлыкта булып, шул ук мәйданга куелган. Билге каһан «эт елында, тугызынчы айда, 26 нчы көндә, ягъни 734 елның 25 нче ноябрендә үлгән, дуңгыз елында, бишенче айда, 27 нче көндә, ягъни 735 елның 22 нче июнендә күмелгән»[77].

Стелалардагы язмалар гади каберташ язулары гына түгел, аларда түрк халкының үткәне тасвирлана, стелланың икенче ягында шул ук мәгълүматлар кытай телендә дә язылган. Алар Кытай елъязмалары хәбәрләре белән раслана. Аннан соң түрк халкының үсеше бәян ителә һәм монда күмелгән кешенең әлеге үсешкә керткән өлеше әйтеп үтелә. Текст ул катнашкан походларны санап чыгу белән тәмамлана. Күмелгән кешенең көче һәм куәте аны җирләргә килгән халыкны санап чыгу белән раслана. Аннан соң текстны төзүченең имзасы куелган, һәйкәлне төзү датасы күрсәтелгән.

Шулай итеп, бу һәйкәлләрдәге язмалар түркләрнең дәвамлы тарихын сурәтли һәм күмелгән шәхес яшәгән еллардан да күпкә алда узган чорларны колачлый.

Гыйбадәт бинасы 10,25 x 10,25 м зурлыкта төзелгән, анда Күлтәгин сыннары куелган булган, ләкин вакытлар дәвамында алар ватылган. Һәйкәлдән соң 3 км буена балбаллар чылбыры сузылып китә, безнең көннәргә кадәр 169 балбал сакланган[78].

Күлтәгиннең кече язмасы тексты каһанның ыруг аристократиясенә һәм халыкка мөрәҗәгатеннән башланып китә. Аннан соң текст түркләрнең Кытай хакимияте астындагы чорын искә ала. Дәүләтнең таркалу сәбәпләре күрсәтелә.

Бу турыда сөйләүче бүлек болай яңгырый:

Табгач будунка бәглек оглун кул болду,
Силик кыз оглуң кюң болду.
Түрк бәгләр Түрк атын уту
Табгачку бәгләр табгач атын тутупан,
Табгач каһанка көрмиш.

Өзекнең татарчага тәрҗемәсе түбәндәгечә:

Кытай халкына синең батыр улларың кол булды,
Сылу кызларың кол кызлар булды.
Түрк бәкләре Кытай исемнәре алды,
Кытай бәкләренең, Кытай каһанының күзенә карап тордылар[79].

Күлтәгиннең зур язмасы үзенең тарихи эчтәлеге ягыннан күпкә баерак. Анда сәяси кризис сәбәпләре киң итеп күрсәтелә, түркләрне Кытай хакимиятеннән коткару тарихы тасвирлана. Эльтерес каһанның, Гудулу каһанның, Капаган каһанның, Могилянның, Күлтәгиннең, Тоньюкукның хезмәтләре һәм башка вакыйгалар санап үтелә.

Дәрәҗәле түрк кешесе. XII гасыр. М. В. Горелик реконструкциясе

Тоньюкук һәйкәлен 1897 елда Е. Н. Клеменц ача. Ул Баин Цокто дигән урында, Улан-Батордан 66 км көньяк-көнчыгышка таба, Тола елгасының уң ярында урнашкан.

Онгин ташы, яки Гудулу хан һәйкәле, Кули-чур һәйкәле тексты, Монголиядәге һәм Көньяк Себердәге кече язмалар кыйммәтле тарихи ядкярләр булып тора. Орхон-Енисей язмаларының барлыгы 7 төркеме билгеле: Лена—Байкал буе, Енисей, Монголия, Алтай, Шәркый Төркестан, Урта Азия һәм Көнчыгыш Европа төркемнәре. Көнчыгыш Төрки каһанлыгы ядкярләре тарихи планда иң бае санала. Енисей буенда, Тывада һәм Хакасиядә рун язулы 150 дән артык ядкяр табылган. Аларның күбесе VIII—XII гасырларда яшәгән борынгы төрки түрәләрнең каберләре өстенә куелган. Барысы да Бөек Төрки каһанлыгы чорындагы әдәби телдә язылган.

Орхон-Енисей язмалары аерым чорның тарихын гына чагылдырып калмый, Көнчыгыш Төрки каһанлыгының идеологиясен дә яктырта.

Борынгы төрки язуы шактый күп төрле булган, әмма нигездә аның ике төре киң кулланылган: Орхон һәм Енисей төрләре.

Алфавитның төрлелеге каһанлыкта һәм аннан соң төзелгән төрки дәүләтләрдә язма мәдәният үсешен күрсәтә[80].

Хәрефле рун язуы, күп галимнәрнең фикерләвенчә, борынгы төркиләр тарафыннан үзләренең көнбатыш күршеләре — арамей чыгышлы алфавитлары булган согдиялеләрдән алынган. Борынгы төркиләрнең рун язуын кайчан файдалана башлавы төгәл билгеле түгел. Бу язуга ихтыяҗ төркиләрдә дәүләт төзелгәч туган дип уйларга нигез бар. Бөек Төрки каһанлыгының зур территориясе, ерак аралар, аның Кытай, Иран, Византия белән сәяси, хуҗалык һәм мәдәни бәйләнешләре язу булдыру ихтыяҗы тудыра. Менандрның, түрк илчесе Византия императоры Юстинга «скиф язуы» белән язылган хат китерде, дигән хәбәре дә моны раслый[81]. С. Г. Кляшторный согд алфавитын төрки телгә җайлаштыру бик иртә — V гасырда, Ашина ыругының Гаочанда һәм Шәркый Төркестанның башка оазисларында яшәгән чорда башланган дип фаразлый[82].

Һәйкәлләрдә, кабер ташларында, тау кыяларында гына түгел, көнкүреш әйберләрендә дә рун язуының бик күп булуы югары катлау кешеләре арасында грамоталылыкның киң таралуы турында сөйли. Төрки җәмгыятьнең төрле катлауларында грамоталылык дәрәҗәсен күрсәтүче чыганаклар әлегә җитәрлек түгел. Көнкүреш әйберләрендәге язмалар төрки җәмгыятьнең гади әгъзалары арасында да грамоталы кешеләр булуын күрсәтә.

Ташка, һичшиксез, аерым очракларда гына язганнар. X гасыр гарәп географы Әбу Дулаф мәгълүматлары буенча, төркләр камыш каләм белән каен тузына, тирегә, кәгазьгә, тактага язганнар. «Тузга язмаганны сөйләмә» дигән гыйбарә әнә шул заманнардан калган булса кирәк[83].

VI гасырның 60 нчы елларында кайбер Будда дине китаплары төрк теленә тәрҗемә ителә. Соңрак кытай-төрки сүзлеге төзелә, кызганыч, ул сакланмаган[84].

Грамоталылыкның киң таралуы төркиләрнең үз мәгариф системасы булу турында фаразларга нигез бирә. Төркиләр рун язуына Кытайга яки башка дәүләтләргә барып өйрәнмәгәннәрдер бит, шундый куәтле дәүләттә белем бирү системасы булуына шик юк.

Галимнәрне төрки рун язмаларның жанр төрлелеге җәлеп итте. Л. Р. Кызласов аларны түбәндәге төркемнәргә бүлә: кабер таш язмалары, межа язмалары, урын, объект исемнәре, тәүбә, хурлау язмалары, дога, мактау, килем-китем язмалары, иминлек теләү, аңлатма язмалары[85].

Уку-язуның таралуы төркиләрдә үзләренең оригиналь һәм тәрҗемә әдәбиятлары таралу мөмкинлеге турында да сөйли. Әлегә фән мондый чыганакларны белми. Л. Р. Кызласов үз хезмәтләрендә Енисей кыргызлары арасында X—XI гасырларда язма әдәбият таралуга, күрше дәүләтләрдә белем алган кешеләр булуга мисаллар китерә[86].

Борынгы төрки рун текстларын өйрәнүгә нигез салучыларның берсе В. В. Радлов бу текстларның телен борынгы төрки телнең «төньяк диалекты» дип саный. И. А. Батманов Орхон-Енисей һәйкәлләренең теленә ыругара характер хас дип раслый. Шулай итеп, галимнәр Бөек Төрки каһанлыгында бердәм әдәби тел булуны таный. С. Г. Кляшторный бу әдәби телнең нигезендә Ашина ыругы диалекты ята, ул соңыннан каһанлыкның дәүләт теле булып киткән дип фаразлый[87].

Төрки каһанлыклар чорындагы төрки мәдәният күрше халыклар, бигрәк тә Кытай мәдәниятенә нык йогынты ясаган. Төркиләрнең киемнәре һәм гадәтләре Кытай югары катлавын җәлеп иткән. Бигрәк тә чалбарлар, каеш белән буылган җиләннәр Кытайның Тан

9*

эпохасында көндәлек киемгә әверелә. Төрки ризыклар да абруйлы була. Кытай императоры сараенда төрки пентатоник музыка яңгырап торган[88].

Язулы таш һәйкәлләрдән башка төркиләр күп санда бүтән таш ядкярләр — балбаллар да калдыра. Алар Алтайдан Днепрга кадәр гаять зур территориядә таралган. Борынгы төркиләрнең бай халык иҗаты булган. Күп вакытлар узуга карамастан, аларның кайбер үрнәкләре безнең көннәргә кадәр килеп җиткән. Алар арасында борынгы түрк тормышы һәм көнкүреше детальләрен саклаучы «Сай-Солонг» эпосын күрсәтергә мөмкин. Хәзерге заманда барлык төркиләргә билгеле Алпамыш турындагы дастан Бөек Төрки каһанлыгы тарихы сюжетларын саклаган[89].

Борынгы төркиләр сынлы сәнгате байлыгын хәзерге төрки халыклар сәнгатенең борынгы түрк мотивлары: бай үсемлек орнаменты, бигрәк тә *лалә* сурәте, татар, башкорт, казакъ һәм башка халыкларның декоратив сәнгатендә Кояш символы — Тәңре сурәте күрсәтә. Татар, башкорт һ.б. төрки халыкларның борынгы төрки чорыннан килгән пентатоник музыкасы һаман да үсеш кичерә. Казакъ, кыргыз, татар, башкортларның һ.б. ат чабышы, атлы уеннарының нигезләре борынгы түркләрдән килә.

* * *

VI—VIII гасырлардагы төрки каһанлыклары чоры төрки халыкларның консолидациясендә, үсешендә һәм этник тарихында иң әһәмиятле этап булып тора. Төркиләр күрше дәүләтләр экспансиясеннән һәм агрессиясеннән саклана. Бөек Төрки каһанлыгы ике гасырга якын яшәү дәверендә күтәрелү, көчәю һәм таркаулык чорлары кичерә. Бу дәүләттә һөнәрчелек алга китә, бигрәк тә металл табу һәм эшкәртү һәм аннан төрле әйберләр ясаучы осталар арта, күчмә терлекчелек үсә, ярым утрак һәм урыны белән утрак игенчелек барлыкка килә. Бу факторлар Төрки дәүләтенә югары җисми һәм рухи мәдәният, хәрби эш осталыгы булдырырга мөмкинлек бирә. Рун язуы һәм аның җәмгыятьнең төрле сфераларына үтеп керүе Бөек Төрки каһанлыгының иң зур казанышларыннан берсе булып тора. Төрки каһанлыклары составында түрк кабиләләре халыкара тормыш тәҗрибәсе алуга һәм танылуга ирешәләр. Нәкъ менә шушы чорда тугандаш төрки халыклар формалашуга нигез салына. Ул заманның этник берләшмәләрендә Евразиянең күп төрки халыкларының ерак бабалары яшәгән.

Көнбатыш Төрки каһанлыгы эчендә Хәзәр каһанлыгы һәм Азов буенда Бөек Болгар дәүләтләре оеша. X гасырда Идел буе болгар

дәүләте төзелә. Соңгарак Бөек Төрки каһанлыгы мирасы нигезендә аның элекке территориясендә күп төрки дәүләтләр барлыкка килә. Төрки каһанлыклар Көнбатыш Себернең «Себер татарлары» исеме белән берләшкән төрки телле кабиләләре язмышында зур роль уйный.

Бөек Төрки каһанлыгы «түрк» термины формалашуда нигез була, ул сәяси терминга әверелә.

Төрки кабиләләрнең консолидациясендә, Түрк дәүләтен төзүдә, аның икътисади, рухи һәм халыкара үсешендә түркүтләр — күк түркләр бик зур роль уйный, кызганыч, алар каһанлык белән бергә һәлак була.

Ассызыклап шуны әйтергә кирәк: Бөек Төрки каһанлыгының ике гасырга якын яшәү чорында җитештерүче көчләр һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләр җитәрлек темплар белән үсми. Суй һәм Тан Кытай империяләре белән, Иран, Гарәп хәлифәлеге белән туктаусыз барган сугышлар, буйсындырылган, ләкин бәйсезлеккә омтылучы халыклар, бигрәк тә тугыз-угызлар белән көрәш моның төп сәбәбе була. Бу фактор Бөек Төрки каһанлыгы дәүләтенең язмышын хәл итә — һәлакәткә китерә.

Бөек Төрки каһанлыгы төзегән цивилизацияне кыпчаклар, кимәкләр, уйгырлар, бәҗәнәкләр, угызлар, карлуклар, кыргызлар, түргешләр, хәзәрләр, болгарлар һ.б халыклар кабул итә һәм каһанлык һәлакәтеннән соң да саклый.

Бөек Төрки каһанлыгы Бөек далада борынгы төркиләр төзегән дәүләтләрнең иң зурысы һәм куәтлесе була. Аннан соң төзелгән бер генә борынгы төрки дәүләт тә мәйданы буенча да, куәте буенча да ул ирешкән дәрәҗәгә җитә алмый. Күп кенә төрки кабиләләр бу дәүләтләр территориясеннән читтә кала.

---

[1] *Гумилев Л. Н.* Хунны в Китае.— СПб., 1994.— С. 116; Древние тюрки.— М., 1993.— С. 13.

[2] *Гумилев Л. Н.* Хунны в Китае.— СПб., 1994.— С. 202.

[3] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II. Исторический очерк этих стран в связи с историей Средней Азии.— Л., 1926.— С. 210.

[4] *Гумилев Л. Н.* Древние тюрки.— СПб., 1993.— С. 63.

[5] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II.— Л., 1926.— С. 211.

[6] *Гумилев Л. Н.* Три исчезнувших народа // Страны и народы Востока.— М., 1961.— С. 104—118.

[7] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II.— Л., 1926.— С. 220.

[8] *Гумилев Л. Н.* Древние тюрки.— СПб., 1993.— С. 23—24.

[9] *Абульгази.* Родословное древо тюрков.— Казань, 1914.— С. 8.

[10] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край.— Л., 1926.— С. 223.

[11] *Абульгази.* Родословное древо тюрков.— Казань, 1914.— С. 8.

[12] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край.— Л., 1926.— С. 225.

[13] *Кляшторный С. Г.* Первый Тюркский каганат и его значение для истории Восточной Европы // Татарская археология.— 1997.— № 1.— С. 23.

[14] Византийские историки / Пер. с греческого С. Дестуниса.— СПб., 1861.— С. 376.

[15] *Кляшторный С. Г.* Формирование тюркской государственности: от племенного союза до Первого Тюркского каганата // Панорама-форум.— 1997.— № 1.— С. 20.

[16] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М.; Л., 1950.— С. 228.

[17] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— Л., 1926.— С. 73.

[18] *Кызласов Л. Р.* Первый Тюркский каганат и его значение для истории Восточной Европы // Татарская археология.— 1997.— № 1.— С. 23.

[19] Византийские историки / Пер. с греческого С. Дестуниса.— СПб., 1861.— С. 422—423.

[20] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— Л., 1926.— С. 228.

[21] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т.II.— Л., 1926.— С. 224.

[22] *Бернштам А.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI—VIII веков.— М.; Л., 1946.— С. 131.

[23] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М., 1950.— С. 283.

[24] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 193.

[25] *Гумилев Л. Н.* Күрсәтелгән хезмәт, 148 б.

[26] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 279 б.

[27] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт. Т. II.— М.; Л., 1953.— 272—274 б.

[28] H. Cordier Histoire generale de la Cine. Vol I.— Paris, 1920, p. 397.

[29] *Кляшторный С. Г.* Степная империя тюрков и ее наследники// История татар с древнейших времен в семи томах.— Казань, 2002.— С. 236.

[30] *Кляшторный С. Г.* Күрсәтелгән хезмәт, 230 б.

[31] *Кляшторный С. Г.* Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии.— М., 1964.

[32] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М.; Л. 1950.— С. 322.

[33] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 324—325 б.

[34] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 161.

[35] *Малов С. Е.* Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии.— М.; Л., 1959.— С. 20.

[36] *Бернштам А.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI—VIII веков.— М.; Л., 1946.— С. 184.

[37] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II.— Л., 1926.— С. 288, 289.

[38] *Артамонов М. И.* История хазар.— М., 1962.— С. 146—156.

[39] *Артамонов М. И.* Күрсәтелгән хезмәт, 162 б.

[40] *Мелиоранский П.* Об орхонских и енисейских надгробных памятниках с надписями // Журнал Министерства народного просвещения.— 1938.— № 6.— С. 266.

[41] *Мелиоранский П.* Күрсәтелгән хезмәт, 270—271 б.

[42] *Плано Карпини.* История монголов / Пер. С. Малеина.— СПб., 1911.— С. 5.

[43] *Кляшторный С. Г.* Степная империя тюрков и ее наследники// История татар с древнейших времен в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности.— Казань, 2002.— С. 254.

[44] *Бернштам А.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI—VIII веков.— М.; Л., 1946.— С. 97—101.

[45] *Кляшторный С. Г.* Күрсәтелгән хезмәт, 257 б.

[46] *Бартольд В. В.* Новые исследования об орхонских памятниках // Журнал Министерства народного просвещения.— 1899.— С. 235.

[47] *Бернштам А.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI—VIII веков.— М.; Л., 1946.— С. 121—124.

[48] История агван Моисея Каванкатваци, писателя X в. / Пер. с армянского К. Патканова.— СПб., 1861 // Цитата приводится по книге Гумилева Л. Н. Древние тюрки.— М., 1993.— С. 55.

[49] *Гумилев Л. Н.* Древние тюрки.— М., 1993.— С. 56.

[50] Византийские историки / Пер. С. Дестуниса.— СПб., 1861.— С. 378—379.

[51] *Гумилев Л. Н.* Древние тюрки.— М., 1993.— С. 265.

[52] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. I.— Л., 1926.— С. 314.

[53] *Кармышева Б. Х.* Этнографическая группа «тюрки» в составе узбеков // Советская этнография.— 1960.— № 4 — С. 12.

[54] *Кызласов Л. Р.* Первый Тюркский каганат и его значение для истории Восточной Европы // Татарская археология.— Казань, 1997.— № 1.— С. 23.

[55] *Окладников А. П.* Неолит и бронзовый век Прибайкалья. Т. III.— М.; Л., 1955.— С. 9.

[56] *Гумилев Л. Н.* Древние тюрки.— М., 1993.— С. 150.

[57] *Умняков И.* История Фахретдина Мубаракшаха // Вестник древней истории.— 1938.— № 1.— С. 10.

[58] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 153.

[59] *Киселев С. В.* Древняя история Южной Сибири.— М., 1951.— С. 515.

[60] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т.І.— Л., 1926.— С. 230; Liu Mai tsai. Die chinesischen Nachsrichten zur Geschichte der ost Turken. Buch I—II.— Wiesbaden, 1958.— S. 10.

[61] *Киселев С. В.* Древняя история Южной Сибири.— М., 1951.— С. 509.

[62] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 520—524 б.

[63] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.—-Баку, 1991.— С. 147.

[64] *Диль Ш.* Юстиниан и византийская цивилизация в VI в.— СПб., 1908.— С. 542.

[65] *Кызласов Л. Р.* Первый Тюркский каганат и его значение для истории Восточной Европы // Татарская археология.— 1997.— № 1.— С. 25.

[66] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Красноярск, 1992.— С. 83.

[67] *Моргулан А. Х.* Казахская юрта и ее убранство // VII Международный конгресс антропологических и этнографических наук.— М., 1964.— С. 9.

[68] *Гумилев Л. Н.* Древние тюрки.— М., 1993.— С. 64.

[69] *Вайнштейн С. И., Крюков М. В.* Об облике древних тюрков // Тюркологический сборник.— М., 1966.— С. 177.

[70] *Вайнштейн С. И., Крюков М. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 182 б.

[71] *Aspelin J. R.* Tupes des penles de l'ancienne Asie Centrale.— Helsingfors, 1890.— P. 12.

[72] *Евтюхова Л. А., Киселев С. В.* Чаа-тас у села Копены // Труды исторического музея. Т. XI.— М., 1940.

[73] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т.II.— Л., 1926.— С. 215.

[74] *Банзаров Д.* Черная вера.— СПб., 1891.

[75] *Стеблева И. В.* К реконструкции древнетюркской религиозно-мифологической системы // Тюркологический сборник.— М., 1971.— С. 215.

[76] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II.— Л., 1926.— С. 213—214.

[77] *Кляшторный С. Г.* Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии.— М., 1964.— С. 68—69.

[78] *Бернштам А.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI—VIII веков.— М.; Л., 1946.— С. 34.

[79] *Бернштам А.* Күрсәтелгән хезмәт, 33 б.

[80] *Бернштам А.* Күрсәтелгән хезмәт, 34—43 б.

[81] Византийские историки / Пер. С. Дестуниса— СПб., 1861.— С. 374.

[82] *Кляшторный С. Г.* Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии.— М., 1964.— С. 49.

[83] *Григорьев В.* Об арабском путешественнике Абу-Дулафе, странствованиях его по Средней Азии.— СПб., 1872.

[84] Liu mai tsai ...— S. 34, 37, 38, 43, 469, 470.

[85] *Кызласов Л. Р.* Рунические письменности Евразийских степей.— М., 1994.— С. 280—208.

[86] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Красноярск, 1992.— С. 110.

[87] *Кляшторный С. Г.* Древнетюркские рунические памятники как источник по истории Средней Азии.— М., 1964.— С. 51.

[88] Liu Mai tsai. Die chinesischen Nachsrichten zur Geschichte der ost Turken. Buch I—II. Wiesbaden. —1958.— S. 469, 470.

[89] *Мальчи-Мерген.* Алтайский героический эпос.— Ойротское нац. изд., 1947.— С. 227—228; *Жирмунский В. М.* Сказание об Алпамыше и богатырская сказка.— М., 1960.— С. 90.

IV бүлек

УЙГЫР КАҺАНЛЫГЫ

Көнчыгыш һәм Көнбатыш Төрки каһанлыклары таркалганнан соң, Бөек далада этник һәм сәяси процесслар дәвам итә һәм үсә бара. Яшәү өчен көрәш барышында аерым этнослар көчәя, кайберләре көчсезләнә. Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгының таркалу чорында көчле кабиләләрнең берсе уйгырлар була, алар бу каһанлыкның һәлакәтендә хәлиткеч роль уйный. Уйгырлар төрки телле теле төркеменнән чыккан борынгы халык булган. IV гасыр ахырында ук инде телеларның бабалары терлекче буларак билгеле була. Зур тәгәрмәчле биек арбаларда йөргәнгә күрә, кытайлар аларны «биек арбалылар» дип атый. Алар Гоби чүленең төньягындагы далаларда таркау төркемнәр булып яшәгән.

IV гасырда уйгырлар жужаннар кул астында кала. 536 елда алар жужаннарга каршы чыгалар, ләкин оешканлыклары начар була. Ул вакытта аларны түркүтләр хөкемдары Бумын буйсындыра һәм жужаннарга каршы көрәштә файдалана. 552 елда уйгырлар Бөек Төрки каһанлыгы составында кала. Алар бу бәйлелек белән риза булмый һәм мөстәкыйльлеккә омтыла. 606 елдан башлап алар күп мәртәбә түркүтләр хакимиятеннән котылырга һәм мөстәкыйль дәүләт төзергә тырыша. Бу көрәшнең башында Яглакар ыругы тора.

Билге каһан үлгәннән соң, уйгырлар Үзәк Азиянең мөстәкыйльлеккә омтылган кабиләләре берләшмәсе башында тора. Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгы каһаны үтерелгәннән һәм 745 елда бу дәүләт таркалганнан соң, әлеге көрәш уйгырларның җиңүе белән тәмамлана. Шул ук елны алар үзләренең дәүләтен — Уйгыр каһанлыгын төзи һәм Үзәк Азиянең хуҗалары булып китә. Шулай итеп, Бөек Төрки каһанлыгы җирләрендә яңа держава — Уйгыр каһанлыгы оеша[1].

Нәтиҗәдә Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгы җирләрендә VIII гасыр уртасыннан өч төрки дәүләт яши башлый. Аннан башка, төньякта, Минуса казанлыгында Енисей кыргызлары үз дәүләтләрен — Кыргыз каһанлыгын торгыза, ләкин 750 елда аны Уйгыр каһанлыгы үзенә буйсындыра.

Уйгыр каһанлыгы тугыз-угыз ыругыннан тора, шуңа күрә аларны «тугыз-угыз» дип йөртәләр. Алардан башка яңа каһанлык составына буйсындырылган басмаллар һәм көнчыгыш карлуклар, шулай ук теле кабиләләренең алты ыругы — бугу, хунь, байырку, тонга, сыге һәм кибо ыруглары кергән. Хокуклары һәм бурычлары буенча алар тугыз-угызларга тиңләштерелә.

Уйгыр дәүләтенең беренче каһаны уйгыр чыганаклары буенча Кюль-Билге каһан, Кытай чыганаклары буенча Хан-Пэйло була, ул Кытай императорыннан Гудулу-Бигя-Кюэ-Хуайжень хан дигән титул ала һәм, Тан империясенең агрессиясеннән саклану өчен, үзен аның вассалы дип таный. Аның улы Моюн-чур вакытында Тан империясе белән якын мөнәсәбәтләр урнашкан.

1909 елда фин лингвисты, Хельсинки университеты профессоры Густав Йон Рамстедт тарафыннан Селенга елгасы буенда берничә һәйкәл табыла. Аларның берсе «Селенга ташы» исеме астында билгеле, һәм ул Уйгыр каһанлыгының икенче каһаны Моюн-чур хөрмәтенә куелган булган. Һәйкәлдәге язмада Уйгыр каһанлыгының баштагы тарихы сөйләнә, 745 елда Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгы каһаны Озмишның үтерелүеннән башлап, Моюн-чур үлгәнче, ягъни 759 елга кадәр булган вакыйгалар яктыртыла. 756—759 елларда Кытайда антифеодаль күтәрелеш була. Уйгыр каһанлыгында Моюн-чурдан риза булмаган кенәзләр аз булмаган, алар аның эшчәнлегенә каршы чыга. Күрәсең, халыкны баш күтәрүгә китергән башка сәбәпләр дә булгандыр, бу баш күтәрү ватандашлар сугышына әверелә. Баш күтәрүчеләр башында Тай-Билге тутук тора, аны каһан итеп күтәрәләр. Баш күтәрүчеләргә киданнар һәм татарлар кушыла, ләкин тиздән алар чигенергә мәҗбүр була[2]. Үз хәленең хәтәрлеген аңлап, Моюн-чур халык белән компромисска омтыла. «Мин гаскәр җыйдым һәм походка чыктым. Ләкин аларның гади кара халкын (qara igil budun) мин үтермәдем, аларның йортларын, терлекләрен алмадым. Мин аларга җәза гына бирдем һәм, искечә яшәргә кушып, үзләрен калдырдым»[3].

Шулай итеп, Моюн-чур, гади халык яклы булып, үзенең югары катлаудан булган дошманнарын юк итә һәм халык яклавына ирешә.

Үзәк Азия төркиләренең тарихын өйрәнүче А.Бернштам Уйгыр каһанлыгы төзелүне яңа дәүләт төзү түгел, ә фәкать түркүт династиясен уйгырныкы белән алыштыру гына дип саный. Ул, уйгыр династиясе турыдан-туры түрк династиясеннән үсеп чыкты, дип яза. Моюн-чурның этисе Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгында шад булган, чыгышы буенча ул түрк була һәм түркләргә

каршы баш күтәрә. Баш күтәрүдә тугыз-угызлар да катнаша, Моюн-чур аларны «үз халкым» дип атый. Һәйкәлдәге язмада Моюн-чур үзе, Озмиш ханны әсир итеп алганнан соң: «Шул вакыттан башлап түркләр династиясе юк ителде»,— дип яза[4]. Түркүтләр династиясе бетерелә, ә иҗтимагый мөнәсәбәтләр сакланып кала.

Күтәрелеш бастырылганнан соң, Моюн-чур Тан императоры тарафыннан танылу таба һәм Кытай императоры белән «дуслык һәм туганлык» шартнамәсе төзи, император аңа үз кызын бирә. Хезмәтләре өчен уйгырлар Кытайдан ел саен берничә дистә мең кисәк ефәк һәм башка зиннәтле әйберләр ала[5]. Уйгыр державасы, үзен Тан империясе вассалы итеп танудан башта отса да, соңыннан күп нәрсә оттыра — Кытайга дәүләт эчендә корткычлыклар ясарга юл ачыла.

Уйгырлар ирек алырга күптән омтыла һәм көрәшә, ләкин алгач, аннан файдалана алмый. Беренчедән, үзәк хакимият бик йомшак була. Уйгыр каһаннары үз дәүләтләрен киңәйтергә омтылып, күршеләренә карата агрессив сәясәт алып бара, бу аларның дошманлык мөнәсәбәтен китереп чыгара. Түркүтләр Төрки каһанлыгында дәүләт һәлакәтенә кадәр, оешканлык һәм тупланганлык күрсәтеп, барлык кабиләләр башында тора. 780 елда ук тугыз-угызлар башка халыклар каршында өстенлекләрен югалта, аларда тупланганлык җитми.

Кабилә башлыклары даими рәвештә хакимиятне үз кулларында туплый бара, бу каһанның үзәк хакимиятен йомшарта. Ханнар алмашуның нәсел системасы йомшара, аларны сайлап кую принцибы көчәя[6].

Көнчыгышта һәркайда эзәрлекләнә торган манихей динен кабул итү уйгыр хөкемдарларының зур ялгышы була. Идигань каһан манихей динен дәүләт дине итеп кабул итә һәм шуның белән дәүләтнең һәлакәтен тизләтә. Бу дин Халдей-Вавилон, фарсы һәм христиан диннәре мифлары һәм йолалары кушылмасыннан гыйбарәт була. Манихейлыкның төп эчтәлеге явызлыкның беренчел булуы турында пессимистик тәгълиматтан гыйбарәт, ул җисми дөньяга каршы көрәшә, яшәешне, шәфкатьлелекне, кызгануны яратмаска өнди, сексуаль оргияләр кертә, аскетизм, җенси азгынлык, рәхимсезлек урнаштыра. Бу дин уйгырларны барлык күршеләре белән диярлек ызгыштыра[7].

Каһанлыкның төньяк чиге Байкал буенча үтә, көнчыгыш чиге Амурның югары агымына һәм хәзерге Маньчжуриягә, Төньяк Кытайга кадәр, көнбатыш чиге монгол Алтаена кадәр җитә.

Уйгыр каһанлыгы чорында Үзәк Азиядә һәм Көньяк Себердә Төрки каһанлыклары чорында башланган феодаллашу процессы

дәвам итә. Каһан иң яхшы җирләрне үзенең феодалларына өләшә. Төп җитештерү чаралары — терлек һәм җир инде феодаль хокукка нигезләнгән милек санала.

Уйгырлар Орхонда башкала — Орду-Балыкны, аннары Хатун-Балык, Бай-Балык һ.б. шәһәрләр һәм кальгаларны төзиләр. Үзәк Азияне тикшерүче археолог Л. Р. Кызласов фәкать Тывада гына да уйгырлар төзегән 17 кальга өйрәнелүен хәбәр итә. Алар барысы да үзара канаулы балчык стена кисентеләре белән тоташкан. Дошман булган Кыргыз каһанлыгы һөҗүменнән саклану системасы әнә шулай төзелгән. Саклану системалары төзү зур байлык һәм күп кеше көчләре таләп иткән. Шул ук вакытта шәһәр мәдәнияте дә үскән[8].

Уйгыр каһанлыгының хуҗалыгы комплекслы булган. Тугыз-угызлар күбесенчә утрак игенчелек белән шөгыльләнгән. Тары, арпа, солы, бодай иккәннәр. Сугару системасы киң җәелгән. Аларның игенчелеге сөрүле булган, тарту көче итеп хайваннарны файдаланганнар. Җирне агач сука һәм тимер төрәнле сабан белән сукалаганнар. Игенне урак һәм кәкре чалгы белән урып-җыйганнар. Ашлыкны кул тегермәнендә он итеп тартканнар һәм ярма ярганнар. Утрак игенчеләр күтүле терлекчелек белән дә шөгыльләнгән.

Башка кабиләләрнең төп шөгыле күчмә терлекчелек булган. Сарык, мөгезле эре терлек һәм дөя асраганнар. Кайбер кабиләләр күмәк аучылык белән шөгыльләнгән.

Тывада металлургия үскән. Металлурглар тимер эреткән, алтын һәм көмеш чыгарган. Кара металлдан җир эшкәртү кораллары, көнкүреш, сугыш кораллары, ат дирбияләре эшләгәннәр. Һөнәрчеләр агачтан да әйберләр эшләгән. Йорт терлеге тиреләре һәм кыйммәтле җәнлек тиреләре эшкәртү киң таралган. Кытай чыганаклары уйгырларның утрак тормышка һәм шәһәр мәдәниятенә омтылышын хәбәр итә.

Халыкара сәүдә үсә. Уйгыр каһанлыгы Бөек ефәк юлының бер тармагын үз кулында тоткан. Каһанлыкка Кытай сәүдәгәрләреннән башка тукыма сатучы гарәп сәүдәгәрләре дә килгән. Минуса казанлыгында Кытай тәңкәләре күп табыла. Уйгыр сәүдәгәрләре ат һәм башка терлек, коллар, кыйммәтле мех, үзләре эшләгән ак тукыма белән сәүдә иткән[9]. 1909 елда Рамстедт тарафыннан табылган һәйкәлләрнең берсе Селенга елгасыннан ерак түгел, Суджи дигән урында куелган. Текстына караганда ул кыргыз югары катлау вәкиленә багышланган. Һәйкәл хакимлек итүче югары катлау вәкиле һәм дәүләт хезмәтендәге кешенең хуҗалык итү характерын күзалларга мөмкинлек бирә. Ул Уйгыр каһанлыгын кыргызлар

басып алганнан соңгы чорга, ягъни аның һәлакәте вакытына карый. «Минем (терлекләрем өчен) ун утарым һәм хисапсыз санда терлекләрем бар иде»,— диелә анда.

Җисми мәдәният ныгу белән рухи мәдәният тә үсә. Уйгырлар VIII гасырда Орхон алфавитыннан файдаланган, аннан соң Якын Көнчыгыштан яңа алфавит алалар, ул «уйгыр алфавиты» дип атала. Аның язуы вертикаль, югарыдан түбәнгә, сулга күчә барып языла. Бу язу, рун язуыннан камилрәк булып, IX гасырда бөтен Шәркый Төркестанга тарала. Уйгырларның яңа алфавитлы язмаларының теле Орхон язмалары теленнән дә, Енисей кыргызлары язмалары теленнән дә аерылмый. Димәк, уйгыр язуы борынгы төрки язуы традицияләрен дәвам иткән, һәм бу язулар да, бу алфавитлар белән язылган текстлар да бүгенге барлык төрки халыкларның уртак мирасы булып тора. Шулай да уйгыр язуының куллану даирәсе киңрәк була. Бу язу белән тәрҗемә дини әдәбият һәм көнкүреш юридик документлар шактый күп язылган. Уйгыр язуы уйгырларның гына түгел, ә Үзәк Азиянең башка халыкларының да грамоталылыгын үстерүгә ярдәм итә. Ул Урта Азиядә дә, Казакъстанда да кулланыла. Бу алфавитта фәнни хезмәтләр дә языла. Мәсәлән, М. Кашгарыйның «Диване лөгатет-төрк» исемле мәшһүр хезмәте уйгыр язуы белән язылган. Алтын Урдада бу язудан озак файдаланалар. Аның күп кенә әһәмиятле документлары, шул исәптән дипломатик язмалар уйгыр язуы белән теркәлгән.

Грамоталылыкның таралуы һәм уйгырларның тормыш тәртипләре турында XIX гасыр башында Урумчи шәһәрендә табылган, кәгазьгә язылган рун тексты хәбәр итә. Алар арасында кол кызны 100 кисәк алтынга алмашу турында кызыклы документлар бар. Документның датасы VIII гасыр дип билгеләнә[10].

Тыва территориясе Уйгыр каһанлыгы тарафыннан 750—751 елларда яулап алына. Уйгыр гаскәрләренә Тыва кабиләләре — чиклар белән каты сугышлар алып барырга туры килә, алар үз җирләрен аяусыз яклый. Чиклар гына түгел, ә Уйгыр каһанлыгына буйсындырылган башка кабиләләр дә, Саян-Алтай яссытаулыгы кабиләләре берлеге төзеп, үз азатлыклары өчен нык көрәшә. Чик буе проблемалары буенча Уйгыр каһанлыгына каршы аларның элекке союздашы — карлуклар чыга.

Уйгыр каһанлыгы яшәгән бөтен чор буенча Тыва иң буйсынмас регион булып кала. Шунлыктан Тыва белән идарә итү өчен «тутук» титулы белән махсус хәрби наместник билгеләнә. Аңа каһан тарафыннан билгеләнгән кешеләр — «ышбар» һәм «тархан» титулы йөрткән регион идарәчеләре буйсына. Шунда ук гаскәрләр дә була[11].

Уйгыр каһанлыгының көнчыгыш күршеләре киданнар булган. Кытай белән дошман булганлыктан, алар уйгырлар белән тыныч мөнәсәбәттә яши. Амурда киданнардан төньяктарак татарлар яши, алар балык тоту белән шөгыльләнгән. Алар белән мөнәсәбәтләр тыныч булмаган. Төньяктан Уйгыр каһанлыгына Себер кабиләләре: йеделәр — шорларның бабалары, кучугур, ку-кижи, Саян-Алтай уйгырлары куркыныч тудырып тора. Джунгариядә байырку һәм түргешләр яши[12].

Енисей кыргызларын буйсындырып тоту каһаннардан зур көч таләп иткән. Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгы таркалганнан соң, Кыргыз каһанлыгы 4 кенә ел мөстәкыйль дәүләт булып яши, аннан соң аны уйгыр каһаннары буйсындыра, әмма алар автономияләрен саклап кала. Кыргызлар үзләренең вассал хәле белән килешми, Шәркый Төркестан, Җидесу һәм Урта Азия белән ирекле элемтәгә омтыла, ләкин аларга юлны Уйгыр каһанлыгы кисеп тора[13].

VIII гасыр башына кыргыз хөкемдарлары көчәя, бу уйгыр каһаннарын борчый. 820 еллар тирәсендә уйгыр каһаны Бао-и Енисей кыргызлары белән сугыш башлый. Башта көрәш уңышлы бара. Ләкин кыргызлар үз дәүләтен саклый.

Кыргызларның Уйгыр каһанлыгына каршы көрәшен башка кабиләләр дә яклый. 818 ел тирәсендә кыргыз кенәзе үзен хан итеп игълан итә, 835 елда каһанлыктан татаблар китә. Манихейлыктан туйган халык массалары үз югары катлавын танымый да, тыңламый да. Идарәчеләр халык яклавын югалта. Кыргызлар, Уйгыр каһанлыгындагы эчке низаглардан файдаланып, 840 елда аңа каршы көрәш башлый. Уйгыр каһанына каршы уйгыр гаскәр башлыгы Кюлюг Баг тархан баш күтәрә. Баш күтәрүчеләрнең һәм кыргыз армиясенең берләшкән көчләре 100 000 сугышчы тәшкил иткән. Орду-Балык шәһәре алына, талана һәм яндырыла, уйгыр каһаны да үтерелә. Уйгыр державасы яшәүдән туктый[14].

Сугышка Кытай хөкүмәте кушыла, ул уйгыр армиясенең калдыкларын тар-мар итә. Уйгырларның шактые Тывада кала. Аларның бер өлеше бөтен Үзәк Азиядә, хәтта Маньчжуриядә урнаша. Алар бу урыннарда компактлы яши[15].

Уйгырларның шактый өлеше министр Пан тәгин җитәкчелегендә Шәркый Төркестанга күчеп утыра, анда яңа Турфан уйгыр кенәзлеген төзи. Уйгырларның бер өлеше Кытайга күчә[16].

Тагын бер борынгы төрки дәүләтенең тарихы әнә шулай тәмамлана. Уйгыр каһанлыгы чорында төркиләр икътисады һәм рухи мәдәнияте тагы да югарырак баскычка күтәрелә.

Ләкин Уйгыр каһанлыгы Бөек Төрки каһанлыгы территориясендә барлыкка килгән берданбер дәүләт булмый. Уйгыр каһанлыгы төзелгән вакытта ук түргешләр үз дәүләтен төзи. Түргешләр турында беренче мәгълүматлар VIII гасырның икенче чирегенә карый. Алар Көнбатыш Джунгариядә һәм Җидесуда яшәүче төрки халык була. Алар «абар» һәм «мукрин» исемле кабиләләрнең кушылуыннан барлыкка килә, «кара» һәм «сары» ыругка бүленгән булалар, Көнбатыш Төрки каһанлыгы составында яшиләр. Түргешләр, төрки кабиләдән булсалар да, төркиләрнең теле төркеменә дә, чуй төркеменә дә, түркүт төркеменә дә кермәгән. Мөстәкыйльлеккә омтыла башлагач,. VIII гасырда Күлтәгин тарафыннан тармар ителәләр. Түргешләрне кабилә башлыгы Учжило берләштерә, ул бага-тархан титулы йөртә. Ул вакытта аның 140 меңлек гаскәре була, бу сан түргешләрнең күп санлы булуын күрсәтә, чөнки төркиләрдә сугышчылар халыкның өчтән берен тәшкил иткән[17].

Түргешләр 707 елда гарәпләр һөҗүменә каршы тора, аларны Бохарадан куып чыгара. Шуннан соң түргешләрнең каһаны Согэ барлык Урта Азиягә хуҗа булып кала. 708 елда ул Кытай белән берлек төзи, ләкин үзенең гаскәр башлыгы Кули-чур белән низаглаша, һәм алар бер-берсенә каршы сугыша. 710 елда Тоньюкук, түргешләргә һөҗүм итеп, аларны җиңә, Түргеш дәүләте таркала[18].

Әле 657 елда ук карлуклар түркүтләр хакимиятен танымый башлый һәм Тан империясе составына керә. Шул ук вакытта алар үзләренең чагыштырмача мөстәкыйльлеген дә саклап кала һәм шул чорда уйгырларның союздашы була. Карлуклар Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгын таркатуда билгеле бер роль уйный[19]. Карлуклар өч ыругтан торган төрки кабилә була. Күчмә терлекчелек, аучылык һәм утрак игенчелек белән шөгыльләнәләр. Алар Җидесуда Урта Азиядән Кытайга бара торган кәрван юлын били. 751 елда карлуклар белән гарәпләр, Тан империясен җиңеп, кытайларны куа. Ләкин алар, кытайлар белән уртак тел табып һәм килешеп, уйгырлар белән сугышлар алып баралар. 757—766 елларда түргешләр дәүләтенең барлык җирләрен басып алалар. Идарәчеләре Орхон язулары буенча башта «элтебер» (илтабар) дип аталган, соңга таба ябгу титулын йөртә, башкала итеп Чу елгасындагы Суяб шәһәрен сайлыйлар, аннары дәүләт идарәсе Или буедагы Койлык шәһәренә күчерелә. Уйгыр каһанлыгының 840 елдагы һәлакәтеннән соң, карлуклар төркиләрнең хуҗасы булып кала. Шул чорда карлук ябгулары үз кардәшләре — төркиләрне Сырдәрья базарларында Габбасилар армиясе өчен коллыкка сатып байыйлар, ләкин төр-

киләргә зур зыян салалар. Карлуклар 861 елда Кашгарияне басып алалар. X гасырда Караханилар дәүләте составына керәләр. 960 елда ислам кабул итәләр[20].

Маньчжуриядән Кара диңгезгә кадәр арада яшәгән барлык төрки кабиләләрне берләштереп тоткан Бөек Төрки каһанлыгы таркалгач, күп төрки кабиләләр берара каушап калган кебек була. Шул вакытта тугыз-угызлар Көнбатыш Ганьсу һәм Шәркый Төркестанга тартыла, VIII гасыр уртасында алар Тарим бассейнын үзләштерә. 744 елда сәяси гарасат кичергән һәм Үзәк Азия ватаннарын югалткан көнчыгыш төркиләр Кашгариягә һәм Җидесуга туктала. Алар анда ислам кабул итә һәм, электән шунда яшәгән карлуклар белән кушылып, Караханилар дәүләте төзи, бу дәүләт беренче дәүләт башлыгы Абд әл-Кәрим Сатук Карахан исеме белән шулай аталып китә (955—956 елларда үлә)[21]. Бу Урта Азия дәүләте 927—1212 елларда яши.

Бу дәүләттә төп рольне карлук, чигили һәм ягма кабиләләре уйный. Ханнар династиясе соңгыларыннан була. X гасыр уртасында бу кабиләләр барысы да ислам кабул итә. Ислам дине монда ниндидер вакыйгалар белән бәйләнешле рәвештә керми, ул халык арасында ислам идеяләренең эзлекле таралу нәтиҗәсе булса кирәк. 992 елда Караханилар дәүләте җитәкчесе Харун Богра хан Бохараны, 996 — 999 елларда аның варисы Наср I Мавәраэннәһерне ала. Бу кабиләләр ислам диненә күчәргә әзер була. 955 елда хакимияткә килгән Караханилар каһаны Сатук Богра хан Базыр улы, ислам дине кабул итеп, яңа Абд әл-Кәрим исеме ала. Ислам шуннан дәүләт дине булып китә. Бу дәүләт төркиләренең Мавәраэннәһерне басып алуы Саманилар дәүләтен тиз таркалуга китерә.

Әлеге дәүләт өлкәләргә бүленә, алар белән Кара хан ыругыннан илек ханнар идарә итә, үзәк хакимият көчсез була. Феодаль җирбиләүнең төп формасы икъта булып, бу система буенча җир салымнары турыдан-туры дәүләт кулына түгел, аерым эре феодаллар кулына кергән. Караханилар дәүләтенең башкаласы булып төрле чорларда Кашгар, Баласагун, Узген, яңадан Кашгар шәһәрләре торган.

Караханилар дәүләте баштагы чорда Бөек Төрки каһанлыгы традицияләрен саклап эш итсә дә, аның гамәлләре үзгә була, чөнки чор башка. Утрак цивилизациягә күчкән Караханилар дәүләтендә икътисади һәм социаль мөнәсәбәтләрнең яңа, югарырак системасы урнаша. Бу дәүләт Тәңре диненә нигезләнгән борынгы төрки идеологиядән күпкә өстен торган ислам цивилизациясе системасына



Бөек дала кабиләләре (VIII—X гасырлар). Чыганак: *Вайнштейн С. И.* Восточно-Тюркский каганат и кыргызы, 1946

килеп керә. Моның гүзәл мисалы булып Караханилар дәүләтендә шагыйрь, хан идарәсенең баш вәзире Йосыф Баласагунлының (1016 һәм 1021 еллар арасы — 1070 елдан соң) «Котадгу белек» («Файдалы белем») поэмасы тора. Шул дәүләтнең югары дәрәҗәле дәүләт җитәкчесе бу этик-дидактик әсәрдә иҗтимагый һәм сәяси корылышның идеаль формаларын сурәтли. Шагыйрь карашынча, мактауга лаек шәхес ниндидер индивидуаль сыйфатлары белән түгел, ә үз катлавының функцияләрен аңлавы белән аерылып тора. Караханилар дәүләтендә филолог Мәхмүд Кашгарый 1072—1074 елларда «Диване лөгатет-төрк» («Төрки сүзләр диваны») дигән мәшһүр сүзлеген яза, бу хезмәт бүген дә филологлар өчен генә түгел, тарихчылар өчен дә кыйммәтле фәнни чыганак булып тора.

Арал буенда төзелгән угызлар дәүләте зурая, көчәя, Төрекмәнстаннан Кече Азиягә кадәр җирләрне били. Ләкин Үзәк Азиядә башка төрки дәүләтләр дә төзелә, алар арасында иң зурысы Кимәк каһанлыгы була.

---

[1] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М.; Л., 1950.— С. 49.

[2] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 49 б.

[3] *Бернштам А.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI—VIII веков.— М.; Л., 1946.— С. 189, 191.

[4] *Бернштам А.* Күрсәтелгән хезмәт, 192 б.

[5] *Кызласов Л. Р.* История Южной Сибири в средние века.— М., 1984.— С. 477.

[6] *Васильев В. П.* Китайские надписи на орхонских памятниках в Кошо-Цайдаме и Карабалгасуне // Сб. трудов Орхонской экспедиции. Вып. III.— СПб., 1897.— С. 24.

[7] *Гумилев Л. Н.* Древние тюрки.— М., 1993.— С. 423.

[8] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Красноярск, 1992.— С. 83.

[9] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 353 б.

[10] *Бернштам А.* Күрсәтелгән хезмәт, 54 б.

[11] *Кызласов Л. Р.* История Южной Сибири.— М., 1984.— С. 50.

[12] *Гумилев Л. Н.* Древние тюрки.— М., 1993.— С. 374.

[13] *Бартольд В. В.* Соч. Т. II. Ч. 1.— М., 1963.— С. 487.

[14] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 334 б.

[15] Материалы по истории уйгур в XII в. Прилож. 484—486.— Новосибирск, 1975.— С. 81, 82; *Лун-ли.* История государства киданей / Пер. В. С. Таскина.— М., 1979.— С. 499.

[16] *Якубовский А. Ю.* Арабские и персидские источники об уйгурском Турфанском княжестве в IX—X в. // Труды отдела Востока Государственного Эрмитажа.— Л., 1947; *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 334, 337, 338, 356 б.

[17] Шул ук хезмәт, 296—297 б.

[18] *Кляшторный С. Г.* Степная империя тюрков и ее наследники/ История татар в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности.— Казань, 2002.— С. 242.

[19] *Файзрахманов Г. Л.* Древние тюрки в Сибири и Центральной Азии.— Казань; 2002.— С. 129—130.

[20] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II.— Л., 1926.— С. 261.

[21] *Кляшторный С. Г.* Күрсәтелгән хезмәт, 248 б.

V бүлек

КИМӘК КАҺАНЛЫГЫ
ҺӘМ БОРЫНГЫ ТӨРКИЛӘР ЯЗМЫШЫ

Кимәк каһанлыгы

Уйгыр каһанлыгын җимергән Енисей кыргызлары элек бу державага кергән кабиләләр белән җитәкчелек итә алмый. Бу каһанлык җимерелгәннән соң, Үзәк Азия кабиләләре җитәкчесез, таркау хәлдә кала. Күп санлы кабиләләр арасыннан кимәкләр яңа сәяси берлекне җитәкләргә һәм яңа дәүләт төзергә әзер була. Бу дәүләт «Кимәк каһанлыгы» дип атала, һәм ул җиде кабиләнең, җиде ханлыкның федерациясе буларак төзелә.

Гардизи мәгълүматы буенча, Кимәк федерациясе кимәк (имак, имәк, йемәк), ими, татар, баяндур, кыпчак, ланиказ һәм аҗлад кабиләләреннән торган.

Кимәк федерациясе Тубыл һәм Иртештән Каспийга һәм Сырдәрьяга кадәр, тайгадан Казакъстан ярымчүлләренә кадәр бик зур территорияне биләгән. Кимәк дәүләтенең чикләре табигатьнең үзе тарафыннан сакланган. Аның төньяк чиге булып Себер тайгасы торган, көнчыгышта аны Алтай таулары, көньякта Бетпак дала саклаган. Шуңа күрә кимәкләр тыныч яшәгән. Мөселман авторлары Кимәк каһанлыгының төньяк чиге итеп мифик Йәэҗүҗ-Мәэҗүҗ илен күрсәтә[1]. IX гасыр ахыры — X гасыр башы гарәп чыганакларында, аерым алганда Әл-Йакуб хезмәтләрендә, кимәкләр дәүләте турында беренче хәбәрләр күренә. Төрки каһанлыгы хөкемдарларыннан аермалы буларак, гарәп чыганаклары Кимәк каһанлыгы хөкемдарын «хакан» дип атый. Бу дәүләтнең 11 хөкемдары була. Хаканның һәм кабиләләр ханының хакимлеге нәсел буенча күчкән[2].

Кимәкләрдә хәрби демократия саклана. Хаканнар һәм ханнар шулай ук гаскәр башлыклары да булган. Ханлыклар үзләренең хәрби контингентыннан хакан гаскәренә сугышчылар биргән. Җиде ханлыкта унбер хөкемдар булу кайбер ханлыкларда бер генә идарәче булмауны күрсәтә.



Үзәк Азия (XII гасыр). Чыганак: *Гумилев Л. Н.* В поисках вымышленного царства, 1992



Кимаклар иле (Әл-Идриси картасы буенча). Чыганак: *Кумеков Б. Е.* Государство кимаков от X—XI веков по арабским источникам, 1972

Элеккеге төрки дәүләтләрнең һәм Кимәк каһанлыгының дәүләт төзелешендәге уртак сыйфатлар идарә итү системасының дәвамчанлыгын күрсәтә.

Кимәк дәүләтендә 16 шәһәр була, аларның 11е Иртештә урнашкан. Башкала булган Имакия (Йәмәк) шәһәренең урыны билгеле түгел, аның да Иртеш буенда урнашуы гына билгеле. Идарәчеләр үзләренең кешеләре һәм гаскәрләре белән стена белән әйләндерелгән һәм ныгытылган башка шәһәрләрдә яшәгән. Чыганаклар салымнарның бер өлешенең хаканга килүе турында яза. Хаканның дәүләт аппараты булган[3].

Чыганаклар кимәк җәмгыятендә сыйнфый катлауларга бүленеш турында да хәбәр итә. Катлауларның аермасы киемнәрдә (байлар ефәктән киенгән), ризыкта, атлы һәм җәяүле ярышларда катнашуда күренә. Боларның шаһиты булып каберләр тора.

Кимәк каһанлыгы халкы

Кимәкләр

Борынгы төркиләр тарихын өйрәнүче тарихчылар өчен Кимәк дәүләте төзелү көтелмәгән вакыйга кебек күренә, чөнки аңа кадәр я Кытай тарихчылары, я гарәп яки фарсы географлары, сәяхәтчеләре һәм тарихчылары «кимәк» исемле халык яки кабилә турында бер мәгълүмат та бирми. Алар турында Византия тарихчыларында да бернинди хәбәр юк, ә башка төрки кабиләләр турында алар аз мәгълүмат калдырмый. Моның сәбәбе шунда: кимәкләр халык буларак үзләренең күршеләреннән соңрак оеша. Яшәп килүче гипотеза буенча, алар 93 елны Тарбагатай һәм Саура тауларына, Җидесу һәм Джунгариягә киткән «аз көчле» сөннәрдән килеп чыга. Бу сөннәр II—III гасырларда Эчке Азияне Тышкы Азиядән аерып торган тау сыртларыннан көнбатыштарак яши һәм үзләренең «Юебань» исемле дәүләтен төзи. VI—VIII гасырларда алар «чуй кабиләләре» дип атала. Аларның бер өлеше — түрк-шатолар 808 елда Кытайга китә һәм Тан династиясен яклый. «Аз көчле» сөннәрнең калган өлешен кытайлар «чумугунь» дип атый, кытайларның хәбәре буенча алар Тарбагатайдан һәм Алтайдан көнбатышта мөстәкыйльлекләрен саклап яши. Нәкь шунда инде кимәкләр барлыкка килә. Шулай итеп, кимәкләр, сөннәрнең варислары буларак, аларның тарихын барысыннан да озаграк дәвам итә. VII гасыр уртасында кимәкләр Алтайдан төньяктарак, Иртеш буенда урнаша һәм Көнбатыш Төрки каһанлыгына керә. Аның таркалуыннан соң, кимәкләрнең бер өлеше Уйгыр каһанлыгында була, икенче өлеше



Кыпчак сугышчысы сыннары

аннан читтә кала. Бу чорда кимәк кабиләләренең үзәге барлыкка килә. Кабилә башлыгы «шад тутук» дип атала[4].

Кимәкләр турында гарәп һәм фарсы географлары, сәяхәтчеләре һәм тарихчылары күп мәгълүмат бирә, ләкин аларның хәбәрләре нигездә X гасырдан башлана. Бу авторлар, хәлифәлекнең һәм Персиянең ераклыгына карамастан, Кимәк каһанлыгы кабиләләре, аларның хуҗалыгы турында тарихи мәгълүмат калдыра. Кимәкләр турында иң беренче хәбәрләрне фарсы сәяхәтчесе Гардизи бирә, ул аларны кытайлар сөннәрнең «чумугунь» дип атаган калдыклары яшәгән җирдә күрсәтә[5]. Кимәкләр турында IX гасырның беренче яртысына караган беренче искә алулар Тамим ибн Бахр хезмәтләрендә дә бар[6].

Башта кимәкләр Иртешгә — Алтай белән Тарбагатай арасында яши. VIII гасырның икенче яртысында — IX гасыр башында аларның ике юнәлештә хәрәкәте башлана: төньяк-көнбатышка Уралга таба һәм көньяк-көнбатышка Төньяк Җидесуга таба. Аларның төп массасы Иртеш буенда кала. 840 елда Уйгыр каһанлыгы таркалганнан соң, кимәк кабиләләре үзәгенә төрки кабиләләрнең бер өлеше: эймюр, баяндур һәм татар кабиләләре килеп кушыла. Кимәкләр каһанлыкның көнбатышында урнаша, Иртеш буенда да җирләр били. Кимәк каһанлыгын төзегәндә, татарлар да катнаша.

Мәхмүд Кашгарый гарәп, фарсы чыганакларында «кимәк» дип исемләнгән халыкны «йемәк» дип атый, ул кимәк, угыз һ.б. төрки кабиләләренең телләре якын булу турында яза[7].

Кыпчаклар

Чыганакларда күбесенчә кыпчаклар турында хәбәрләр сакланган, алар кимәкләрдән соң иң күп санлы булган. Кытай чыганаклары аларны б.э.к. III гасырдан башлап «цюйше» исеме белән белә. «Кыпчак» атамасы Моюн-чур һәйкәлендә дә бар (VII гасыр). Кыпчаклар турында мөселман авторлары күп яза. Ибн Хордадбех «Китаб әл-мәсәлик әл-мәмәлик» исемле хезмәтендә төркиләр илендә яшәүче тугыз-угызларны, кимәкләрдән соң кыпчакларны атап китә. Аларның борынгы бабалары булып безнең эрадан күп элек Минуса казанлыгында яшәгән динлиннар санала. Бронза чорында ук алар югары мәдәнияткә ия була, бу турыда Минуса һәм Алтай каберлекләре хәбәр итә. Кыпчаклар Сөн каһанлыгы, Бөек Төрки һәм Уйгыр каһанлыгы составына кергәннәр. 630 елда кыпчакларның бер өлеше кытайлар һәм түркүтләр тарафыннан юк ителә. Грумм-Гржимайло, исән калган кыпчаклар бүленде, бер өлеше канглар белән кушылып, «коман» яки «кыпчак» (половец) исеме белән билгеле булган халык ясалды, дип яза. Төрки дөньядагы олы кырылышлар вакытында кыпчакларның ата-бабалары бай мәдәни мирасының зур өлеше югала[8]. Кыпчаклар, кимәкләрнең якын туганнары булса да, алардан аерым урнашалар. Кимәк каһанлыгына кергән һәр зур кабиләнең үз ханлыгы була. Кыпчакларның да үз ханлыгы була, ләкин алар сәяси яктан кимәкләргә бәйле кала. Аерым кабиләләрнең ханнары хакан тарафыннан билгеләнә яки раслана[9]. Мәхмүд Кашгарый, кимәкләр һәм кыпчаклар бер үк телдә сөйләшә, дип яза. Кыпчаклар үзләрен кимәкләр белән бер күрмәгән, кимәкләрне алар үзләренең бер тармагы дип санаган. Кыпчакларның кабилә составы катлаулы булган, ул 9 кабиләдән торган. С. Г. Кляшторный, бернигә дә нигезләмичә, мөселман авторларына кадәр кыпчаклар турында беркем бер хәбәр дә калдырмады, дип яза[10]. Ул кытайларның борынгы кыпчакларны «цюйше» дип атап йөртүләрен дә инкяр итә. Моңарчы бу этноним бик күп галимнәр тарафыннан таныла иде, бернинди бәхәсләр тудырмады.

Татар кабиләләре

Гардизи әсәрендә китерелгән риваять кимәк берләшмәсенең төзелүен татар кабиләләре белән бәйли. И. Маркварт һәм Б. Е. Кумеков татар кабиләләре Кимәк каһанлыгын төзүдә генә түгел,

ә кимәкләрнең этногенезында да катнашкан дип раслый[11]. «Татар» термины беренче мәртәбә Кошо-Цайдамдагы Күлтәгин һәм Билге каһан хөрмәтенә куелган һәйкәлләрдә искә алына. Күлтәгиннең олы язмасында беренче түрк каһаннары Бумын һәм Истәмине күмүгә (VI гасыр уртасы) үз илчеләрен җибәргән халыклар арасында утыз-татарлар да бар. Шул ук язмада утыз-татарлар Күлтәгиннең һәм Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгына нигез салучы Илтереш каһанның дошманнары арасында күрсәтелә[12].

Дәрәҗәле татар кешесе. XII гасыр. М. Горелик реконструкциясе

Билге каһан язмасында тугыз-татарлар — 723—724 елларда Билге каһанга каршы баш күтәргән тугыз-угызларның союздашлары беренче мәртәбә күрсәтелә. Уйгыр каһаны Моюн-чур язмасында тагын тугыз-татарлар — каһанга каршы баш күтәргән угыз кабиләләренең союздашлары теркәлгән[13].

Шулай итеп, татарлар беренче мәртәбә рун язмаларында VI гасыр уртасындагы вакыйгалар белән бәйле рәвештә искә алына. VIII гасырда татарлар Монголиянең төньяк-көнчыгыш өлешен били. 740—840 елларда татарлар Уйгыр каһанлыгы составына керә. Татарлар Кытай чыганакларында беренче мәртәбә «да-да», «да-дань», «татань» исеме белән 842 елгы вакыйгаларга бәйле рәвештә соңгы Уйгыр каһанының союздашлары сыйфатында искә алына[14].

Уйгыр каһанлыгы җимерелгәннән соң, татарлар уйгырлар белән бергә Шәркый Төркестанга китә. IX гасырда алар тангутларның күршесе була. Тангут дәүләтендә татарлар Ганьсу далаларында һәм Алашань (Тянь-Шань) тауларында яши[15]. «Татар» атамасы IX—X гасыр хотан-сак документларында да бар. «Худуд ал-алам» татарларны турыдан-туры тугыз-угызлардан исәпли[16]. Мәхмүд Кашгарый татарларны төркичә сөйләшүче кабиләләр арасында искә ала. Кимәк федерациясе территориясенә татарлар, мөгаен, 840 елдан соң килгәндер[17].

Кытай чыганаклары хәбәр итүе буенча, татар кабиләләре IX гасыр башында Иньшань тауларына таба килә һәм Керуленнан көнбатышка тарала. Бу чорда Кытай авторлары татарларны «шивэй»

дип атый. 966 елда алар, киданнарга каршы көрәшү өчен, Сун империясе белән союз төзи[18]. Ләкин бу союз аларга ярдәм итми һәм 984—985 елларда татарлар киданнардан җиңелә. Кытайларда халыкларның һәм кабиләләрнең исемнәрен алмаштыру гадәте була, һәм алар татарларны «цзюбу» дип атый башлый. «Татар» этнонимы аларның үз атамалары була. XII гасырда беркадәр вакыт татарлар далада гегемонияне үз кулларына ала, һәм Бөек Кытай стенасыннан алып тайгага кадәр арада яшәгән барлык халыкларны «татар» дип атый башлыйлар. «Татар» этнонимына Кытай тарихчылары бик зур буталыш кертә. XII гасырга кадәр алар монголларны татарларның бер өлеше дип карый, ә XIII гасырда, киресенчә, Кытай тарих фәне татарларны монголларның бер тармагы дип саный. XIII гасырда татар һәм монгол этнонимнары синоним булып китә. Менә шуннан татар белән монголны бутау китә дә инде. Кытай тарихчылары татарларны өч төркемгә бүлә: ак татарлар, кара татарлар һәм кыргый татарлар[19].

Ак татарларга алар Гоби чүленнән көньяктарак яшәгән чын татарларны, онгутларны (шатоларның варисларын) нисбәт итә. Алар цивилизацияле булган, ефәк кием кигән, фарфор һәм көмеш савыттан ашаган, аларның башлыклары грамоталы булган һәм Конфуций тәгълиматын белгән[20].

Кара татарлар, шул исәптән кераитлар, күчмә терлекче булган, мәдәният үзәкләреннән читтә яшәгән. Алар бәйсезлекне югары бәяләгән. Төнлә алар дошман һөҗүменнән арбаларны боҗра итеп тезеп, аның тирә-ягына сакчылар куеп сакланган. Алар ак татарларны күрә алмаган һәм кызганганнар, чөнки аларны ефәк чүпрәкләр өчен һәм чит цивилизация җимешләре өчен үзләренең бәйсезлекләрен сатты дип исәпләгәннәр.

«Кыргый татар» дип кытайлар Көньяк Себернең күчмән терлекчеләрен, аучыларын һәм балыкчыларын санаган, алар үз ыруг башлыкларыннан тыш бернинди хакимиятне дә танымаган, ә үз башлыкларына ирекле рәвештә буйсынган. Алар даими рәвештә ачлыктан һәм мохтаҗлыктан җәфаланган, ләкин физик хезмәтне яратмаган, чит күргән. Терлек көтеп, кәҗә, сыер савып йөргән кара татарларны кызганганнар[21]. Кытайларның «кара татар» һәм «кыргый татар» дигәне төрки кабиләләр булмаган, күрәсең, алар бу кабиләләрне кытайча яки монголча сөйләшмәгәнгә күрә «татар» дип санаганнар.

Рәшид әд-дин язуы буенча, татарларның төп иле Көнчыгыш Монголиядәге Буир-нур күле буенда урнаша. Ул татарларның төрле төркемнәренең бер-берсе белән дошманлашып торуы турында яза. Шулай булса да алар бик борынгы заманнарда ук бик күп кабилә-

ләрне буйсындырып, хакимлек итеп килгән, үзләренең дәрәҗәләре, куәтләре белән башкалардан аерылып торганнар[22]. Аларның гадәттән тыш бөеклеге һәм дәрәҗәле булуы сәбәпле, башка төрки ыруглар үзләрен «татар» дип йөртә башлый. С. Г. Кляшторный, Рәшид әд-дингә һәм башка чыганакларга таянып, алты татар дәүләте булган, татарларның барлык төркемнәре дә төрки булган, дип яза. Рәшид әд-дин алты татар дәүләтеннән берсенең генә урынын күрсәтә — Буир-нур күл буе, ә калганнары кайда? С. Г. Кляшторный, төрле чыганакларга таянып, үзеге Сучжоуда, ягъни Ганьсу белән Шәркый Төркестан чигендә булган татар дәүләтен күрсәтә[23]. Гардизи Югары Иртештә тагын бер татар дәүләте булу турында язып калдыра[24]. Димәк, чыганаклар әлегә безгә алты татар дәүләтеннән тик өчесенең генә урынын күрсәтә, калганнарын табу — киләчәк эше.

С. Г. Кляшторный Рәшид әд-диннең Үзәк Азиянең этносәяси тарихын өч хронологик этапка бүлүен күрсәтә. Беренче этап — дала төрки кабиләләренең хакимлек итү чоры, моның вакыт чикләре билгеләнмәгән. Икенче этап — төрки кабиләләрне татарларның буйсындыру чоры — бик борынгы заманнардан татар-монгол сугышларына кадәр. Бу чорда «татар» этнонимы гомуми политноним була. Өченче этап — монголларның күтәрелү чоры, бу чорда «монгол» этнонимы гомуми политнонимга әйләнә: чоры — XII—XIII гасырлар[25].

1161 елда татарлар Буир-нур күле янында монголларны җиңеп тар-мар итә, шуның нәтиҗәсендә борынгы монгол ханлыгы таркала. Ләкин монголлар көрәшне дәвам итә. Хабул хан улы Есугей баһадир татарларны җиңүгә ирешә. Ул татар баһадиры Темучинны әсир итеп ала һәм бу җиңү хөрмәтенә үзенең яңа туган улына Темучин дип исем бирә. Ул киләчәктә Чыңгыз хан була[26]. Көнбатышка булган походларда монголлар татарларны алгы төркемнәргә куйган, шул сәбәпле монгол гаскәре «татар гаскәре» дип аталган. Ул чорда татарларның гайрәтле сугышчы дигән даны еракларга таралган булган. Шул заман тарихчылары арасында, әйткәнебезчә, татар белән монголны бутау башлана. XIII гасыр Кытай тарихи һәм сәяси документларында монголларны «татар» дип атау гадәткә керә, бу хәл дә татар белән монголны бутауны көчәйтә. Төрле илләрнең тарихчылары бу буталудан әле дә котыла алмый.

XIII гасырдан Үзәк Азиядә «татар» атамасы кулланылмый, ул Алтын Урда халкының этнонимы булып китә.

Башка кабиләләр

Кимәкләр, Иртештән хәрәкәт итеп, Урал һәм Эмба арасында һәм Арал, Каспий буйларында зур территория били. VIII гасыр уртасына кадәр аларның көньяк күршеләре карлуклар булган, көнчыгышта — Енисей кыргызлары. Тугыз-угызлар иле кимәкләрдән көньяктарак булган. Хаканның резиденциясе Иртеш буендагы Имакия шәһәрендә була[27]. Кимәкләр әкренләп федерациянең башка җирләрен дә били, алар Җидесуда күп була.

Мөгаен, башта кыпчаклар кимәкләр белән бергә яшәгән, ләкин ниндидер сәбәп белән IX гасыр азагында алардан аерылган һәм каһанлыкның көнбатышына утырган. Көньякта кыпчаклар бәҗәнәкләр белән күрше булган, алар VIII гасырда — IX гасыр башында Сырдәрья бассейнында һәм Арал буенда яшәгән[28]. VII—XII гасырларда кыпчакларның һәм кимәкләрнең мәдәнияте тәңгәл булган[29].

IX гасыр уртасында кимәкләр көнбатышка таба хәрәкәт итә башлый. Алар бәҗәнәкләр җирен ала. Бәҗәнәкләрнең үзәге булып Кангюй сәяси берлеге кабиләләре торган, бәҗәнәк кабилә берлеген төзүдә төрки кабиләләрдән башка сарматлар һәм угорлар торган. Алар терлекчелек белән шөгыльләнгән, ыруглык җәмгыяте белән яшәгән. Ләкин IX гасыр уртасында бәҗәнәкләрнең хәле авырая, аларның берлеге кимәкләр, угызлар һәм карлуклар тарафыннан җиңелә. Кимәкләр угызлар белән бәҗәнәкләрнең Сырдәрья һәм Арал буендагы җирләренә хуҗа була, Көньяк Уралда күченеп йөри башлый. Кимәкләр басымы астында бәҗәнәкләр Түбән Идел далаларына, аннан венгрларны көнбатышка кысрыклап, Дон, Днепр елгалары арасына килә. IX гасыр ахырында Көнчыгыш Европа далаларының көньягында бәҗәнәкләрнең яңа күчмә союзы оеша. Византиялеләр бәҗәнәкләрне «пазинакитлар» яки «пацинаклар», гарәпләр «бәҗәнәкләр» дип атый. Бәҗәнәк этносының яңа сәяси берлеге оеша башлый. Аларның күршеләре булып көчлерәк һәм билгеле кабиләләр — угыз, кыпчак, мадьярлар һәм Хәзәр каһанлыгы торган. Хәзәр каһанлыгының йомшаклыгыннан файдаланып, алар аның җирләре аша көнбатышка китә. Угызлар, хәзәрләр белән берлектә булып, IX гасыр азагы — X гасырда, ашыгып, көнбатышка китүче бәҗәнәкләрне кысрыклый. Алар күчү вакытында талау һәм яндырулар белән шөгыльләнә. Бәҗәнәкләрнең бер өлеше Дон-Днепр арасына утырса, икенчесе Кавказ алдына килә[30]. X гасыр уртасына бәҗәнәкләр Иделдән Дунайга кадәр зур территорияне били. Күрше халыкларның тормышында шактый роль уйныйлар. Хәзәр каһанлыгын җимерәләр. Византия бәҗәнәкләрне Русь белән

бәрелештерергә омтыла. Рус җирләре 915, 920 һәм 968 елларда бәҗәнәкләр һөҗүменә дучар була[31].

Бәҗәнәкләр русларга һәм аларның күршеләренә зур зыян сала: әсирләрне коллыкка сата, өлешчә басып алынган җирләргә утырта, күпләрен акча түләү хисабына иреккә җибәрә. Рус кенәзләре бәҗәнәкләрне күрше дәүләтләрне талауда файдалана. Мәсәлән, 941 һәм 971 елларда рус кенәзләре Игорь һәм Святослав Игоревич бәҗәнәк төркемнәрен Византия һәм Дунай Болгариясенә алып бара. 1036 елда Ярослав Мудрый аларга җимергеч һөҗүм ясый. XI—XII гасырларда күп бәҗәнәкләр Киев Русена аның чикләрен саклау өчен күчереп утыртыла. X—XII гасырларда алар Венгриягә үтеп керә, аларны чик буйларына һәм ил эченә утырталар. Аерым төркемнәре Византиягә китә. XIII—XIV гасырларда алар аерым этнос буларак яшәүдән туктый, кыпчаклар, торклар, венгрлар, славяннар һәм монголлар белән кушыла[32].

Кимәкләр, үзләренең яшәү регионнарын киңәйтеп, карлуклар, огузлар һәм кыргызлар арасында кала[33].

Кимәкләрнең көньяк күршеләре — карлуклар, Көнбатыш Төрки каһанлыгы мөстәкыйльлеген югалткач, үзләренең бәйсезлеген саклап кала. 200 ел алар Җидесуда, Урта Азиядән Кытайга бара торган кәрван юлында яши. 657 елда алар Тан империясе составына керә[34]. Бу империя составында аларга җиңелрәк була, чөнки алар үзләренең чагыштырмача мөстәкыйльлеген югалтмый һәм Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгына каршы көрәшә. Икенче Көнчыгыш Төрки каһанлыгы җимерелгәч, аларның бердәнбер көндәше булып Түргеш ханлыгы кала. 756 елда бу ханлыкта ыруглар арасында ызгыш чыга, 759 елда түргешләр карлукларга буйсына, аларның беразы көнчыгышка, уйгырлар арасына китә. Карлук дәүләтенең башкаласы 766—940 елларда Чу елгасындагы Суяб шәһәре була, аннан соң хан резиденциясе Или елгасындагы Койнаклы шәһәренә күчерелә. Карлуклар 200 ел үзләренең мөстәкыйльлекләрен саклый. Исламга озак каршы торалар, әмма 960 елда ирекле рәвештә бу динне кабул итәләр һәм аннан соң Кытай белән бернинди мөнәсәбәткә кермиләр. X гасыр ахырында Караханилар дәүләте составына керә. Кытай көнбатыш җирләрдә үзенең позицияләрен югалта, тик дүрт кальганы: Куча, Кашгар, Хотан һәм Карашар кальгаларын гына саклап кала. Чыганаклар карлуклар һәм кимәкләр арасында мөнәсәбәтләр турында бернинди дә хәбәр бирми, чөнки алар арасында җансыз Бетпак дала яткан[35].

IX гасыр ахырында Арал һәм Каспий буйларында угызлар дәүләте төзелә, аның үзәге Янгикенд шәһәрендә була. Угыз кабиләләренең бер өлеше монда Уйгыр каһанлыгы тугыз-угызла-

рының Енисей кыргызлары тарафыннан җиңелүеннән соң килә. Угызлар IX—X гасырларда кимәкләр белән берлектә тора. Алар, күрәсең, Каспий буеның зур булмаган өлешен биләгәндер, чөнки гарәп сәяхәтчеләре, кимәкләрнең дәүләте Иртештән Каспийга кадәр җирдә, дип яза. Фирдәүсинең «Шаһнамә»сендә Каспий диңгезе «Кимәк диңгезе» дип язылган. XI гасырда, кыпчакларның көнбатышка интенсив хәрәкәте башлангач, Угыз дәүләте кыпчаклар тарафыннан җимерелә. Угызларның төньяк тармагы Дон—Днепр буе далаларына китә, элек бәҗәнәкләр яшәгән җирләргә урнаша. Угызлар рус кенәзләре белән мөнәсәбәткә керә, аларны руслар «торклар» дип атый. 985 елда Владимир Святославич белән берлек төзи һәм 990 елларда аның белән ике мәртәбә Идел Болгарына каршы походка бара. Идел Болгары бу чорда көчле дәүләт була, һәм Владимир угызлар ярдәменнән башка аларга каршы походка барырга курка[36].

1055 елда Византия рус кенәзе Всеволод Ярославичны торкларга каршы походка котырта, һәм торклар җиңелә. Торкларның калдыклары Русь чикләренә күчеп утыра һәм XI гасырда Дон — Кара диңгез арасына урнаша, утрак тормыш белән яши, игенчелеккә күчә башлый. Алар каракалпаклар һәм гагаузлар составына керәләр, беразы славянлаша. Бәҗәнәкләр, торклар һәм соңыннан кыпчаклар рус казаклары һәм украиннар оешуда әһәмиятле урын тота.

Угызларның Арал буенда күчеп йөрүче икенче тармагы сәлҗүк кабиләсе җитәкчелеге астында Урта Азия аша Алгы Азиягә китә һәм анда Сәлҗүк дәүләте, Кония солтанлыгы һәм башка дәүләтләр төзи. Угызлар төрекмәннәр, азәрбайҗаннар, каракалпаклар һәм төрекләр этногенезында әһәмиятле роль уйный[37].

Кимәкләр, кыпчаклар, угызлар, бәҗәнәкләр, угорлар һәм башка этник төркемнәр дәүләт эчендә тыныч яши. Кимәк каһанлыгы чәчәк ата. Аның турында бөтен Көнчыгышта беләләр. Кимәкиягә мөселман илләреннән географлар, сәяхәтчеләр, тарихчылар килә, алар бу бай ил турында әсәрләр иҗат итәләр.

Икътисади үсеш нәтиҗәсендә аерым ханлыклар көчәя, үзәк хакимият йомшара. Көчәеп киткән кимәкләр һәм кыпчаклар угызларны көньякка, бәҗәнәкләрне көнбатышка, карлукларны көньяк-көнчыгышка, угорларны төньякка, Себер тайгасына кысрыклый һәм шуның белән үзләрен көчсезләндерә.

Кимәк каһанлыгы яшәү чорында Урта Иделдә һәм Түбән Камада әһәмиятле тарихи процесслар бара. Һуннарның һәм алар белән бергә әлегә исемнәре анык билгеле булмаган төрки кабиләләрнең килүе бу регионның этник картасын үзгәртә. Бу кабиләләр Имән-

кискә археологик мәдәниятен калдыра. Имәнкискә керамикасы, археологлар билгеләве буенча, болгарныкы белән тәңгәл.

VIII гасырда һуннар заманыннан ук төркиләр яшәгән Урта Иделгә болгарлар килеп утыра. Алар X гасырда үз дәүләтләрен төзи, бу дәүләт «Идел Болгары» дип атала. Көнчыгыш авторлары бу дәүләтнең күп кабиләле булуы турында яза. Ул дәүләт Багдад хәлифәлеге идарәчеләренең игътибарын җәлеп итә, һәм аннан болгар ханы Алмушның чакыруы буенча 922 елда махсус илчелек килә. Аның составында мөселман руханилары да була. Безнең көннәргә бу илчелекнең сәркатибе Ибн Фадланның китабы килеп җитә, анда Болгар дәүләте турында әһәмиятле мәгълүматлар сакланган. Ибн Фадлан, алар килгәнче үк болгарлар ислам дине тоткан, дип яза. Бу миссиядән файдаланып, Алмуш исламны дәүләт диненә әверелдерә. Хәзергә кадәр Кимәк каһанлыгы һәм Идел Болгары дәүләте арасындагы мөнәсәбәтләр өйрәнелмичә кала[38].

Кимәк каһанлыгының хуҗалыгы һәм мәдәнияте

Кимәкләрнең хуҗалыгы комплекслы булган. IX гасырның икенче яртысында каһанлык кабиләләренең төп шөгыле күчмә терлекчелек була. Алар ат, сарык, кәҗә, мөгезле эре терлек һәм дөя асраганнар. Бөлгенлеккә төшкән күчмә терлекчеләр ярым утрак тормышка күчә. Бу процесс кимәкләрдә башка кабиләләргә караганда интенсиврак бара. Язма һәм археологик чыганаклар комплексы X гасырда кимәкләрнең хуҗалыгы ярым утрак характерда булган дип расларга мөмкинлек бирә. Утрак торулыклар да була. Кимәкләрдән ирригацион корылмалар калдыклары, феодаль замоклар хәрабәләре калган[39].

Б. Е. Кумеков кимәкләр һәм кыпчаклар хуҗалыгында түбәндәге хуҗалык-мәдәни типларны билгели: ясалма сугару кулланa торган утрак хуҗалык; игенчелекне көтүле терлекчелек белән бәйләп алып бара торган ярым утрак хуҗалык, күчмә терлекчелек хуҗалыгы[40].

Хуҗалык итүнең Б. Е. Кумеков сурәтләгән баштагы ике тибы нигездә кимәкләрдә булган. Игенчеләр тары, арпа, бодай, кузаклылар һәм хәтта күп хезмәт таләп иткән дөгене дә игкәннәр. Йөзем үстергәннәр, умартачылык белән шөгыльләнгәннәр. Кимәк каһанлыгы халкының яраткан хайваны ат булган. Ул, атланып һәм җигеп йөрү өчен, шулай ук җир эшкәртүдә файдаланылган, ат ите иң яхшыдан саналган. Утрак һәм ярым утрак хуҗалыкларда күбесенчә ат һәм мөгезле терлек, кимрәк күләмдә сарык асраганнар. Гарәп авторлары меңәр атлы көтүләр турында яза[41]. Күчмәннәрдә төп терлек шулай ук ат булган, аннан башка алар күп сарык асраган.

Күчмәннәрдә мөгезле терлек аз була, чөнки алар өчен кышка печән әзерләргә кирәк булган.

Кимәк шәһәрләре күбесенчә сәүдә юлларында барлыкка килгән. Сәүдә алмашу характерында була. Игенчеләр ашлыкны һәм онны сарыкка һәм тирегә алмашкан. Акчалы сәүдә дә була[42].

Кимәк хуҗалыгында төрле һөнәрләр дә тарала. Алар арасында беренче урынны тире эшкәртү, киез ясау, өс һәм аяк киеме тегү, күннән һәм киездән ат дирбияләре әзерләү торган. Кимәкләр һәм каһанлыкның башка кабиләләре сугыш коралын, көнкүреш әйберләрен, игенчелек коралларын үзләре эшләгән. Агачтан савыт-саба, тирмә терәкләре һ.б. ясаганнар. Каһанлыкта тимер чыгаралар һәм эшкәртәләр, аннан күп төрле әйберләр ясыйлар. Алтын һәм көмеш чыгаралар. Археологик тикшеренүләр вакытында Иртеш буеның курганнарында тимер әйберләр, алтыннан, көмештән һәм бронзадан бизәнү җиһазлары, ефәк тукыма, киез, күн, агач савыт, корал, ат дирбиясе, сугыш коралы, керамика калдыклары табыла. Кимәк дәүләтендә һөнәрчелек ярдәмче характерда булган, шулай ук профессиональ һөнәрчеләр дә була[43].

Каһанлыкның халкы нигездә киез тирмәләрдә яшәгән. Шәһәрләрдә балчык стеналы җир асты һәм ярым җир асты тораклары да була. Кимәкләр ныгытылган шәһәрләр төзегән, аларда һөнәрчелек чәчәк ата. Хакан идарәсе урнашкан шәһәрдә кимәк аристократиясе туплана. Әл-Идриси аларда булган базарларны һәм храмнарны җентекләп сурәтли. Илдә булган 16 шәһәр арасында ул түбәндәгеләрне күрсәтә: башкала Имакия, Карантия, Гаган, Дамурия, Сараус, Банҗар, Халауш һ.б.[44].

Кимәк кабиләләре төркүтләр һәм уйгырлар кебек күп санда язма ядкярләр калдырмаган. Илдә уку-язу булган, бу турыда Әбу Дулаф болай дип яза: аларда камыш үсә, ул камыш белән алар язалар. Ф. А. Арсланова X—XI гасырларда ясалган язулы көзгеләр таба[45].

Кимәкләрнең дине башка төркләрнеке кебек булган — алар Тәңрегә ышанганнар. Ата-баба культы, Тәңре диненә кадәр булган дин калдыклары да яшәгән. Утны, Иртеш елгасын олылаганнар. Уйгырлар белән чиктәш урыннарда манихей дине дә булган. Таш сыннар кую гадәте киң таралган була, кимәкләр һәм кыпчаклар аларга табынган[46]. Бу таш сыннар монголлар килгәнче даланың характерлы билгесе булган. Түбән Днепрда, Төньяк Донецның уң ярында һәм Донда күп санлы таш сыннар торган. Болардан башка алар Кавказ алдында, Дон белән Идел арасында очрый. Йөзләре белән алар көнчыгышка карап тора, узучы юлчылар аларга баш ия, корбан китерә торган була[47].

Кимәк дәүләтенең һәлакәте

XI гасырда Кимәк каһанлыгының үзәк хакимияте деградация кичерә. Хакан фәкать ирекләрнең хәрби юлбашчысы булып калган. Бердәм армия булмый. Һәр ханның бераз ирекле сугышчылары булган. Законнарны үтәргә мәҗбүр итүче булмаган. Каһанлыкта коллар белән сәүдә итү үсә. Үзләренең «уңайсыз» кешеләрен, хәтта туганнарын да коллыкка сатканнар. Бу сәүдә күпләрнең язмышын билгели — аларны киданнар бертуктаусыз эзәрлекли, аулый, сата. Бу трагедия бик озак — 200 ел буе дәвам итә.

Кимәк каһанлыгы XI гасыр уртасына кадәр яши. Аның җимерелүенең төп сәбәбе булып тышкы фактор — Үзәк Азия күчмәннәренең миграциясе санала. Үзәк Азия кабиләләрен миграциягә 916 елда Төньяк Кытайда монгол телле киданнар дәүләте — Ляо төзелү этәрә. IV гасырдан алып X гасырга кадәр бу монгол телле киданнар хәзерге Монголиянең көнчыгышында һәм төньяк-көнчыгышында, Амурның көньяк ярлары буйлап һәм хәзер Кытай Халык Республикасына керә торган Эчке Монголиядә көн иткән. Алардан көнбатышта Үзәк Азиянең барлык территориясендә (Шәркый Төркестан, Джунгария, Монголия, Эчке Монголия) төрки телле этник группалар: түрк-шатолар, түргешләр, карлуклар, угызлар, Енисей кыргызлары, азлар, чиклар, дуболар, чигилилар, кимәкләр, кыпчаклар, курыканнар, уйгырлар һ.б. яшәгән.

Төрки телле халыкларның шактые: уйгырлар, куннар, каилар, түрк-шатолар, ак татарлар (онгутлар), түркүтләрнең варислары, угызларның варислары Бөек Кытай стенасы буенда һәм аннан көньякта — Ордоста, Маньчжурия тигезлекләрендә тормыш алып барган[48].

Күренгәнчә, X гасырга кадәр Шәркый Төркестаннан алып (Джунгарияне дә кертеп) бөтен Монголия территориясендә, Маньчжурия далаларында тоташ масса булып югарыда саналган төрки кабиләләр көн күргән. Бу кабиләләрнең кайберләре Сөн дәүләте заманыннан шунда яшәгән, кайберләре исә сөннәрдән соң оешкан. Бөек Төрки каһанлыгы яшәгән чор бу төрки кабиләләр өчен иң бәхетле заман була. Бу Бөек дәүләт таркалганнан соң, аларның күбесе Уйгыр каһанлыгы составына да, Енисей кыргызлары дәүләте составына да кермәгән. Кимәк каһанлыгының чикләре дә, күргәнебезчә, Көнбатыш Алтайдан көнчыгышка узмаган. Өч гасыр буена бу күп санлы төрки кабиләләрне берләштерүче көчле дәүләт булмый. Дөрес, вакытлыча кабилә берлекләре, кабиләара берләшмәләр төзелергә мөмкин, ләкин болар

төркиләрне берләштерерлек көч булып үсә алмаган. Кытайдан башка бу төркиләргә куркыныч янарлык тышкы көчләр дә булмый. Шушы хәл төрки кабиләләрен һәм Кимәк каһанлыгын һәлакәткә китерә дә инде. Афәтнең башы монгол телле киданнардан чыга.

907 елда киданнарның юлбашчысы Ила Абуги үзен император дип игълан итә, күрше төркиләрне буйсындырып, дәүләтен киңәйтә. 947 елдан бу дәүләт «Ляо» дип атала башлый. XI гасыр уртасында Ляо дәүләте Япон диңгезеннән алып Шәркый Төркестанга кадәр территорияне били.

Киданнарның 924 елда Үзәк Азия далаларына башланган беренче һөҗүме төркиләр өчен чын һәлакәткә әверелә. Ул Үзәк Азиянең этник картасын үзгәртә. X—XI гасырлардагы кидан һөҗүме күп кабилә берләшмәләренең Кытай чигеннән көнбатышка качуына китерә, монгол телле кабиләләрнең Үзәк Азиягә һөҗүмен китереп чыгара. 1010 һәм 1017 елларда кидан гаскәрләре Җидесуга ыргыла, ләкин җиңелә[49].

XI гасырның 30 нчы елларында киданнар һөҗүме сәбәпле, Бөек Кытай стенасы буенда яшәгән төрки телле каилар төрки телле куннар җирен биләп ала. Куннар шарлар (сары кыпчаклар) җиренә күчеп утыра, ә шарлар төрекмәннәр җиренә күчә. Төрекмәннәр угызларның көнчыгыш җирләрен ала, угызлар, бу чорда Кара диңгезгә якын җирләрдә яшәгән бәҗәнәкләрне кысрыклап, алар территориясенә килеп утыра[50].

Киданнарның һөҗүме сәбәпле килеп чыккан бу миграция төркиләрне Иртештән көнбатыштагы җирләргә китерә, Кимәк каһанлыгын җимерелүгә, ә төркиләрне коточкыч трагедиягә дучар итә[51].

Киданнар артыннан килүче башка монгол телле кабиләләр — найманнар XI—XII гасырларда кыпчакларның һәм кимәкләрнең калдыкларын Иртешнең югары агымыннан һәм Алтайдан кысрыклап чыгара. Кимәкләрнең һәм кыпчакларның бер өлеше Көнбатыш Себергә китә. Найманнар Енисей кыргызларының дәүләтен дә җимерә.

Кимәк каһанлыгының иң зур өлкәсе Кыпчак ханлыгы булган. X гасыр ахырына үзәк хакимият көчсезләнә, һәм кыпчаклар мөстәкыйльлек ала. Алар барлык күршеләрен кысрыклап, борынгы Кангюйның хуҗасы булып ала. XI гасыр башында кыпчаклар көнбатышка ыргыла, элегрәк угызлар яшәгән җирләрне басып ала. Угыз җирләрен басып алгач, кыпчаклар шактый көчәя, кимәкләр кыпчакларга бәйле булып кала. Чама белән XI гасыр уртасында фарсы авторы Байхани кыпчакларны Харәзем чигендә күрсәтә,

XI гасыр уртасында Көнчыгыш авторлары Арал буе далаларын элеккечә угыз даласы дип түгел, ә кыпчак даласы дип раслый. Шулай итеп, галәмәт зур кыпчак урдасы XI гасыр башында утырган урыныннан кузгала. Бу гадәттәге күченү генә түгел, баерак көтүлекләрне басып алу өчен максатчан һөҗүм була. Кимәкләрнең бер өлеше үзләренең борынгы җире — Иртеш буенда кала, икенчесе кыпчаклар белән көнбатышка юнәлә. Иртеш буенда кыпчакларның да беразы кала.

Кыпчак урдалары башта бәҗәнәкләр, ә аннан соң угызлар киткән юлдан уза, Иделне, Донны, Днестрны, Днепрны кичеп, Дунайга җитә. Юлда кыпчакларга бәҗәнәкләрнең һәм угызларның калдыклары кушыла. Бу чорда әле Азов буенда хәзәрләр, болгарлар, аланнар калган була. Шундый давыллы этник вакыйгалар чорында тирән этникара процесслар бара, аерым этнослар югала, яңалары ясала. Иделдән алып Дунайга кадәр киң далаларга килгән кыпчаклар Кимәк каһанлыгы составында Кыпчак ханлыгында яшәгән кыпчаклар булмый инде. Бәҗәнәкләр, угызлар, хәзәр, болгарларның калдыклары һәм аланнар белән кушылып, алар бирегә яңа этнос сыйфатында килә. Руслар аларны «половецлар» дип атый. Аларны чәч төсе буенча шулай атаганнар дигән фикер бар. Имеш, аларның чәче ашлык кибәге сыман (русча «полова») сары төстә булган. Ихтимал, аларның ниндидер төркемнәре сары чәчле булгандыр, ләкин төп массасы кара чәчле була. Днепрдан көнбатыштарак утырган кыпчакларны византиялеләр һ.б Көнбатыш халыклары «кыпчак» дип тә, «половец» дип тә түгел, ә бөтенләй башкача — «команнар» дип атый. Күп галимнәрнең XI—XII гасырларда Идел белән Дунай арасындагы далаларда яңа ике этнос — кыпчак һәм команнар барлыкка килгән дигән гипотезасын кире кагучы чыганаклар табылмады. Шулай итеп, кыпчак, половец һәм команнар кайбер авторлар расларга тырышканча бер этнос түгел. *Кыпчаклар — б.э.к. II гасырдан билгеле борынгы этнос, динлиннарның варислары, половецлар — Иделдән Днепрга кадәр арада кыпчакларның берничә төрки кабилә белән кушылуыннан оешкан, команнар — шулай ук кыпчакларның башка төрки этнослары белән кушылуыннан килеп чыккан яңа этнос.* Якын кардәшлек, бердәм төрки тел бу этник процессны тизләтергә ярдәм итә. «Половец» һәм «коман» этнонимнарын бер үк халыкның Европада һәм Русьта ике төрле исеме дип санаучылар да бар[52]. Кыпчакларның үзатамасы «сорочин» булган[53].

Половец һәм коман күмү йолаларының кыпчакныкыннан беркадәр аерылуы көньяк далаларда XI—XII гасырларда барган катлаулы этник процессларның шаһиты булып тора. Кыпчак

курганнары таштан өелә һәм таш белән әйләндереп алына, мәет башы белән көнчыгышка каратып куела. Аның белән янәшә ат яки аның карачкысы күмелә, тик аның аяклары булырга тиеш. Половец һәм команнарның күмү йоласы бәҗәнәкләр һәм угызлар күмү йоласының күп сыйфатларын үзенә алган. Борынгы кыпчакларда ир һәм хатын-кыз элгәрләре культына багышланган изге корылмалар төзү киң үсеш ала[54].

Бронза эпохасында кыпчаклар Минуса казанлыгында яши. Бөек Төрки каһанлыгы чорында — Алтайда, IX гасырның икенче яртысыннан Иртештән Харәзем чикләренә кадәр булган далаларда көн күрә. Гарәп һәм фарсы авторлары бу җирләрне «Дәшт-и-Кыпчак» дип атый. Дәшт-и-Кыпчак составына алар Сырдәрьяның түбән агымыннан алып, Арал буйларын һәм Җаекның көньягындагы һәм төньягындагы җирләрне дә кертә. Беренче булып «Дәшт-и-Кыпчак» термины фарсы авторы Насри Хөсрәүдә XI гасырда очрый. 1030 елдан Иртеш буеннан килеп, кыпчаклар һәм аларның варислары булган половецлар, команнар Харәземнең күршеләренә әверелә һәм хәзерге Казакъстанны басып ала. XIII гасырда алар Дунайга кадәр җирләргә хуҗа була. Шуннан соң Сырдәрьяның түбән агымыннан алып Дунайга кадәр булган далалар «Дәшт-и-Кыпчак» дип атала.

Барлык кыпчаклар да Кимәк каһанлыгы территориясен ташлап китми. Кыпчакларның шактый массалары Иртеш буенда кала. Кимәкләр белән бергәләп алар Көнбатыш Себернең борынгы халкы составына керә[55]. Нәтиҗәдә алар Себер татарлары һәм башка төрки халыклар ясалуда катнаша. Күп кыпчак урдалары XIII гасырның 20—30 нчы елларында монгол армиясе составына кушыла. Идел арты һәм Днепр буе далаларында алар үзләренең XI гасырдан башлап бу якларга киткән кардәшләре — половецлар һәм команнар белән очраша. Киләчәктә Кырым, Казан, Әстерхан, Себер татарлары, башкортлар, нугайлар, казакълар һәм башка төрки халыклар ясалуга китерүче этногенетик процесслар дәвам итә. XI гасыр уртасында половецлар рус кенәзләре белән очраша һәм аларны берничә мәртәбә җиңелүгә дучар итә. 1115 елда аларны Владимир Мономах җиңә, һәм половецлар рус кенәзләренә зур куркыныч булудан туктый, шулай да алар һөҗүмнәрен туктатмый[56].

Кимәк дәүләтенең һәлакәтеннән соң борынгы төркиләрнең язмышы

Кимәк каһанлыгының таркалуы төркиләр өчен чын трагедиягә әверелә. Үз дәүләтләре булмаганлыктан, күп төрки кабиләләр ялгыз кала, таркаулана. Азия төркиләренә әкренләп сүнү һәм рәхимсез күршеләр тарафыннан юк ителү куркынычы барлыкка килә.

Төркиләр Кимәк каһанлыгы таркалгач та үзләренең намуслылык, кыюлык, тугрылык, чыдамлык, самимилек, интригаларга сәләтсезлек, ялагайлыкка бирелмәү кебек табигый сыйфатларын саклап калалар. Аларда талау, көч күрсәтүгә омтылу, артык горур кылану гадәте дә булмый. Нәкъ менә шул сыйфатлар төркиләрне харап итә дә[57].

Элекке монголлар — Ляо дәүләте киданнары һәрвакыт далага һөҗүм итеп тора, ирләрне һәм картларны үтерә, хатын-кызларны һәм балаларны, Төньяк Кытай плантацияләрендә эшләтү өчен, коллыкка сата. 200 ел буе төрки коллар Кытай икътисадын күтәрүдә эшли. 200 ел буена Якын Көнчыгыш базарларында кол төркиләрне: команнарны, половецларны, угызларны һәм төрекмәннәрне саталар. Коръәннең катгый тыюына карамастан, мөселман кол сатучылар кол мөселманнар белән сату итә. Кол төркиләр мөселман илләрендә дә үзләренең табигый күркәм сыйфатларын саклаган. Шул ук вакытта гарәпләр кол төркиләрнең «арысланга тиң» сыйфатларын югары бәяли. Гарәпләргә төркиләрнең гайре табигый бозыклыклары булмау, горурлык, өй эшен эшләүдән баш тарту, командалык урыннарына омтылу кебек сыйфатлары ошый[58]. Себердән һәм Үзәк Азиядән алып килеп, Көнчыгыш базарларында күп төркиләр: түргешләр, кимәкләр, карлуклар, тугыз-угызлар, угызлар, кыргызлар, кыпчаклар кол итеп сатыла. Түбән Иделдән, Доннан һәм Днестрдан сату өчен половецларны, хәзәр һәм болгарларны алып киләләр. Аларны үз сәүдәгәрләре үк сата. Алтайдан Днепрга кадәр булган даладан Якын Көнчыгышка ике гасырдан артык вакыт дәвамында төркиләр сатылуга килеп тора. Аларны төрле эшләрдә файдаланганнар, әмма кимсетүдән дә чирканмаганнар. Бигрәк тә төрки колларга шигый фарсылар кансыз була, чөнки төркиләр исламның сөнни мәзһәбен тоткан.

Төрки ташкыны өч тарафка юнәлә: Кытайга, Мисырны да кертеп, Якын Көнчыгышка һәм Көнбатыш Европага — христиан дөньясына. Византия төркиләрне сатып алмый, алар бирегә һәм Паннониягә (Паннония — хәзерге Венгриянең төньяк өлеше, Сербиянең төньягы һәм Австриянең бер өлеше кергән Рим провинциясе) урдалары белән үзләре килгән. Чит дөньяга төркиләр

бик күп булып килсәләр дә, берләшергә омтылмый һәм кечерәк төркемнәр яки зур булмаган субэтнослар төзи[59]. Төркиләрнең үз илләреннән еракта, төрле илләрдә таралу вакытында аларның бай тарихы инде онытылган була. Аны беркем дә хәтерләми дә, белми дә. Төркиләрнең үткәндә куәтле дәүләтләре, данлы тарихы, үзенчәлекле цивилизациясе булуны белмәгәннәр. Кытай, гарәп-фарсы тарихи чыганаклары онытылган. Шуңа күрә базарларда сатып алынган төркиләрне кыргый, ватансыз, үткәне булмаган кешегә санаганнар. Төркиләр үз язмышларына битараф булган шовинистик Кытай тарихында бәяләнмәгән тирән эз калдырган.

Төрки, славян, эфиоп һәм тау халыкларыннан торган коллар Мисыр армиясе сафларын тулыландырган. 1259 елда кол төрки Бибарс җитәкчелегендә Мисырда властьны кол төркиләр үз кулларына ала һәм ил белән 258 ел буе, ягъни 1517 елга кадәр идарә итә. Аларны «мәмлүкләр» дип атыйлар. XVII гасыр ахырында мәмлүкләр яңадан властьны яулап ала һәм 1805 елга кадәр Мисыр белән идарә итә. Мәмлүкләр идарә иткән озын тарихи чорда Мисырда төрки тел дәүләт теле булган, әдәби әсәрләрнең күбесе төрки телдә язылган. Мисырның төрки телле мәмлүкләр чорындагы Алтын Урда, Казан, Кырым һәм башка татар дәүләтләре белән элемтәләре, багланышлары тарихы тиешенчә өйрәнелмәгән.

1312 елдан кол төркиләрне сату туктатыла, чөнки Алтын Урда ханы Үзбәк ислам динен дәүләт дине итеп игълан итә, коллык тыела, Алтын Урда мөселманнарын мөселман илләре базарларында сату туктатыла.

200 елга сузылган төрки коллар белән сәүдә итү нәтиҗәсендә Үзәк Азия далаларында төркиләр калмаган диярлек. Төрки кабиләләр аерым утрау булып Минуса казанлыгында, Алтайда һәм Тывада гына кала. Борынгы заманнардан алып төркиләрнең шактый тыныч яшәү регионы булып Бараба даласы, Түбән Иртеш, Тубыл, Тура, Обь һәм аның кушылдыклары — Чулым, Омь, Томь елгалары буендагы урман-дала торган. Әле б.э.к. үк Көнбатыш Себернең көньягында Скиф берлегенең, соңрак Сармат берлегенең төрки телле кабиләләре яшәгән. Сөннәр турындагы бүлектә 93 елда Кытай, сяньбиләр һәм динлиннарның берләшкән көчләре тарафыннан Сөннү дәүләте җимерелгәч һәм II гасырда Таншихай сөннәрне Үзәк Азиядән кугач, сөннәрнең бер өлеше Бараба далаларына, Көнбатыш Себернең урман-далаларына килүе турында белгән идек. Шул чордан алып Көнбатыш Себергә төрки кабиләләрнең килүе тукталмый. Себер татарларының бабалары составы шулай гасырлар буе туплана.

Кимәк каһанлыгы таркалганнан соң, Үзәк Азия далаларының хуҗасы булып монголлар кала. Башта IV—IX гасырларда монгол кабиләләре утрак була, алар Маньчжурия чигендә салкын урманнарда, нык торакларда яшәгән, күбесенчә аучылык һәм балык тоту белән шөгыльләнгән. Ат һәм дуңгыз асраганнар. IX гасыр ахыры — X гасыр башында монгол кабиләләренең әкренләп көнбатышка күчеп утыру процессы башлана. Бу төркиләрне кысрыклауга китерә. 200 ел дәверендә монгол кабиләләре җәяүледән, нигездә аучыдан һәм ат асраучыдан күчмәнгә һәм терлекчегә әверелә. Төркиләрдән алар даланың бар төр терлеген, күчмән тәҗрибәсен һәм гадәтләрен, шулай ук күчмә өй һәм күчмәннәрнең җисми мәдәнияте формаларын күреп ала. Шул ук вакытта алар утрак тормышларының күп формаларын саклап кала[60]. Монголларның көнбатышка хәрәкәт итүче найман кабиләсе XI—XII гасырларда кимәкләрне, кыпчакларны монгол Алтаеннан һәм Югары Иртештән куып чыгара, XII гасыр уртасыннан хәзерге Монголиянең барлык территориясендә монгол кабиләләре хакимлек итә.

Монголлар килү белән, далада төркиләргә яшәү мөмкинлеге калмый. Монголларның яшәү рәвеше башкаларны талау, терлекләрен куып алып китү, кызларын урлаудан гыйбарәт була. XII гасырда Монголия чүлләре яшәрә — яңгырлар башлана. Яңадан Керулен, Селенга буйларында терлек көтүләре белән кешеләр пәйда була. Монголлар килгәнче бу җирләрдә татарлар яшәгән[61].

Кытай чыганаклары буенча монголлар, татарлардан аермалы буларак, озын буйлы, сары чәчле, зәңгәр күзле булган. Аларның хәзерге кыяфәте кыска буйлы, кара чәчле кабиләләр белән катнаш никахтан килеп чыга[62].

1206 елда монгол Темучин бөтенмонгол корылтаенда Чыңгыз хан (Бөек хан) дип игълан ителә. Монголларның беренче корбаннары Көньяк Себернең төрки телле кабиләләре була[63].

* * *

VIII—X гасырларда баштарак Алтайда, Иртеш буенда, Көнчыгыш Казакъстанда, соңрак Урал буенда һәм Үзәк Казакъстанда кимәк һәм кыпчакларның күпчелекне тәшкил итүе хәлиткеч нәтиҗәгә — Кимәк каһанлыгы төзелүгә китерә. Чыганаклар VI гасыр уртасында — VIII гасырның беренче чирегендә татарларның 30 ыругы булуы, VIII гасыр уртасыннан соң 9 татар ыругы булуына ишарә ясый. Күрәсең, соңга таба татар ыруглары берләшеп, көчәеп киткәндер. Кимәк федерациясен төзүдә татар кабиләләренең дә роле зур була. Татар кабиләләре Кимәк дәүләтендә генә түгел,

борынгы заманнардан алып төркиләр дөньясында да зур тарихи роль уйнасалар да, аларның тарихы бик аз өйрәнелгән. Борынгы татарлар тарихы махсус өйрәнүне сорый.

Кимәк каһанлыгын 840 елда төзелгән диярга нигез бар. Бу дәүләтнең төзелүендә һәм ныгуында ике кабилә берләшмәсе — кимәк һәм кыпчаклар берлеге төп терәк булып тора. Шулай да гегемонлык кимәкләр кулында була. Кимәкләр башта дәүләт эчендә яшәгән халыклар, кабиләләр белән татулык саклый, аларны берләштереп тота ала. Кимәк дәүләтенең чикләре көнчыгышта Алтайны үз эченә ала, көнбатышта Сырдәрья һәм Аралга җитә. Ләкин кимәкләр үз дәүләтендә Бөек Төрки каһанлыгында түркүтләр тоткан дәрәҗәгә ирешә алмый. Гарәп-фарсы авторларының Кимәк каһанлыгында малтуарның күп, азык-төлекнең мул булуы турындагы язмалары бу дәүләттә икътисадның шактый үскәнлегенә, халыкның тормышы шактый бай икәнлегенә шаһит булып тора. Рухи мәдәният тә үсештә булган.

Кимәк каһанлыгында күп төрле төрки халыклар, кабиләләр яшәгән, анда этногенетик процесслар кайнап торган. Ил эчендә барган миграциягә киданнар басымы астында көнчыгыштан килгән миграция кушыла, бу хәл Кимәк дәүләтен җимерелүгә китерә. X гасырда Кыпчак ханлыгының көчәеп китүе вакытлы гына күренеш була, ул гына дәүләтне һәлакәттән коткара алмый.

Көнчыгышта монголлар күтәрелеше башлангач, Көньяк Себердә һәм Үзәк Азиянең Алтайга кадәр территориясендә төркиләр бик аз, аерым утраулар гына булып кала. XI гасырда төркиләрне коллыкка сату киң тарала һәм бу хәл XIII гасырның беренче чирегенә кадәр дәвам иткән. Бу төркиләр өчен зур фаҗига була.

Кимәкләр һәм кыпчаклар киләчәктә Идел, Урал буе һәм Себер татарлары, шулай ук кайбер башка төрки халыклар этногенезында төп компонентларның берсе була.

---

[1] *Хеннинг Р.* Неведомые земли. Т. II.— М., 1961.

[2] *Бартольд В. В.* Худуд ал-алам. Рукопись Туманского с введением и указателем.— Л., 1930.— С. 100.

[3] *Minorsky Y.* Hudud al-alam.— L., 1937.— S. 103.

[4] *Бартольд В. В.* Отчет о поездке в Среднюю Азию с научной целью. 1893—1894 г.— СПб, 1897/Заметки Императорской академии наук. Сер.VIII. Т. I.— № 4.— С. 83, 106.

[5] *Бартольд В. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 82, 83 б.

[6] *Кумеков Б. Е.* Государство кимаков IX—XI в. по арабским источникам.— Алма-Ата: Изд. «Наука» АН Каз. ССР, 1972.— С. 53.

[7] *Махмуд Кашгари.* Диван лугат ат-турк. Факсимиле.— Анкара, 1941.— С. 1.

[8] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II.— Л., 1926.— С. 57, 58.

[9] *Бартольд В. В.* Худуд ал-алам. Рукопись Туманского с введением и указателем.— Л., 1930.— С. 19.

[10] *Кляшторный С. Г.* Кимаки, кипчаки, половцы//История татар с древнейших времен в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии в древности.— Казань, 2002.— С. 331.

[11] *Кумеков Б. Е.* Күрсәтелгән хезмәт, 45 б.

[12] *Рамстедт Г.* Перевод надписи Селенгинского камня // Труды Троицко-Кяхтинского императорского Русского географического общества. Т. V. Ч.1.— СПб., 1912.— С. 65.

[13] *Кюнер Н. В.* Китайские известия о народах Южной Сибири и Дальнего Востока.— М., 1961.— С. 35, 89.

[14] *Кляшторный С. Г.* Древнетюркские рунические памятники.— М., 1964.— С. 162—169.

[15] *Кычанов Е. И.* Очерк истории Тангутского государства.— М., 1968.— С. 134.

[16] *Бартольд В. В.* Худуд ал-алам. Рукопись Туманского с введением и указателем.— Л., 1930.— С. 174.

[17] *Кумеков Б. Е.* Күрсәтелгән хезмәт, 42 б.

[18] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. II.— Л., 1926.— С. 376—377.

[19] *Васильев В. П.* История и древности восточной части Средней Азии от X до XIII в.— СПб., 1891.— С. 216.

[20] *Гумилев Л. Н.* В поисках вымышленного царства.— М., 1992.— С. 78.

[21] *Гумилев Л. Н.* Күрсәтелгән хезмәт, 78 б.

[22] *Рашид ад-дин.* Сборник летописей: в 3-т.— Т. I.— М.; Л., 1946.— С. 101.

[23] *Кляшторный С. Г.* Күрсәтелгән хезмәт, 350 б.

[24] *Бартольд В. В.* Сочинения. Т. V.— М., 1968.— С. 43—44.

[25] *Рәшид әд-дин.* Күрсәтелгән хезмәт, 103 б.; *Кляшторный С. Г.* Татары в Центральной Азии // История татар в семи томах. Т. I. Народы степной Евразии с древности.— Казань: Изд. «Рухият», 2002.— С. 348.

[26] *Гумилев Л. Н.* Күрсәтелгән хезмәт, 115 б.

[27] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. III.— М., 1953.— С. 303.

[28] *Бартольд В. В.* Худуд ал-алам. Рукопись Туманского с введением и указателем.— Л., 1930.— С. 303.

[29] *Моргулан А. Х.* Археологические разведки в долине реки Сарысу // Вестник АН Каз. ССР.— 1947.— № 7.— С. 17—22.

[30] *Minorsky Y.* Hudud al-alam.— L., 1937.— S. 160.

[31] *Багрянородный Константин.* Об управлении империей: текст, перевод и комментарий.—М., 1989.— С. 155, 159.

[32] *Голубовский П. В.* Печенеги, торки и половцы до нашествия татар.—Казань, 1884.— С. 123.

[33] *Кумеков Б. Е.* Государство кимаков IX—XI в. по арабским источникам.— Алма-Ата: Изд. «Наука» АН Каз. ССР, 1972.— С. 5.

[34] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт. Т. I.— М., 1950.— 347 б.

[35] *Грумм-Гржимайло Г. Е.* Западная Монголия и Урянхайский край. Т. II.— Л., 1926.— С. 331.

[36] Повесть временных лет. Ч. I.— М., 1950.— С. 59.

[37] *Гордлевский В. А.* Государство сельджукидов в Малой Азии.— М.; Л., 1950.

[38] *Фәхретдинов Р. Г.* Татар тарихы (кыскача басма).— Казан: Мәгариф, 1999.— 25—27 б.

[39] *Маргулан А. Х.* Археологические разведки в долине реки Сары-су // Вестник АН Каз. ССР.— 1947.— № 7.— С. 21; *Маргулан А. Х.* Из истории городов и строительное искусство древнего Казахстана.— Алма-Ата, 1950.— С. 95—106.

[40] *Кумеков Б. Е.* Государство кимаков IX—XI в. по арабским источникам.— Алма-Ата, 1972.— С. 90.

[41] *Бартольд В. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 83, 107 б.

[42] *Бартольд В. В.* История культурной жизни Туркестана // *Бартольд В. В.* Соч. Т. II. Ч. 1.— С. 239.

[43] *Кумеков Б. Е.* Күрсәтелгән хезмәт, 97 б.

[44] *Кумеков Б. Е.* Күрсәтелгән хезмәт, 106, 107 б.

[45] *Кумеков Б. Е.* Күрсәтелгән хезмәт, 108 б.

[46] *Бартольд В. В.* Отчет о поездке в Среднюю Азию с научной целью. 1893—1894 г. // Записки Императорской Академии наук, сер. VIII, Т. I.— СПб., 1897— № 4.— С. 20.

[47] *Дәүләтшин Г. М.* Төрки-татар рухи мәдәнияте тарихы.— Казан: Татар. кит. нәшр., 1999.— 117 б.

[48] *Кызласов Л. Р.* Күрсәтелгән хезмәт, 135 б.

[49] *Бартольд В. В.* Сочинения. Т. 5. —М., 1968.— С. 394—396.

[50] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Изд. Краснояр. ун-та, 1992.— С. 137.

[51] *Агаджанов С. Г.* Очерки истории огузов и туркмен Средней Азии IX—XIII в.— Ашхабад, 1969.— С. 158.

[52] *Плетнева С. А.* Половцы.— М., 1990.— С. 40.

[53] *Добродомов И. Г.* О половецких этнонимах в древнерусской литературе // Тюркологический сборник.— М., 1978.— С. 111.

[54] *Плетнева С. А.* Күрсәтелгән хезмәт, 39 б.

[55] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт. Т. I.— М.; Л., 1950.— С. 296—297; *Небольсин Н. И.* Покорение Сибири // Отечественные записки. Т. 60.— СПб., 1848.— С. 256.

[56] *Гумилев Л. Н.* В поисках вымышленного царства.—М., 1992.— С. 73.

[57] *Босворт К. Э.* Нашествие варваров//Мусульманский мир. 950—1150.— М., 1980.— С. 24—25.

[58] *Босворт К. Э.* Күрсәтелгән хезмәт, 27 б.

[59] *Гумилев Л. Н.* Тысячелетие вокруг Каспия.— Баку, 1991.— С. 210.

[60] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Изд. Краснояр. ун-та, 1992.— С. 137.

[61] История стран зарубежного Востока в средние века.— М., 1970.— С. 205.

[62] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т.I.— Л., 1926.— С. 376—377.

[63] *Кызласов Л. Р.* История Тувы в средние века.— М., 1968.— С. 138—460.

VI бүлек

ЕНИСЕЙ КЫРГЫЗЛАРЫ ДӘҮЛӘТЕ

Минуса казанлыгының борынгы халкы

Минуса казанлыгы халкы турындагы беренче язма чыганаклар б.э.к. IV—III гасырларга туры килә. Бу чыганаклар Минуса казанлыгының борынгы халкы — динлиннар турында хәбәр итә. Динлиннар шулай ук Обьтан Байкалга кадәр яшәгән, аларга Тагар мәдәнияте кешеләре белән бер итеп карыйлар.

Динлиннар турында борынгырак ·мәгълүматлар да бар, ләкин алар легендалар характерында. Легендаларның берсе динлиннарны атларына берегеп үскән мәңгелек җайдак, үзенчәлекле кентавр итеп күрсәтә. Икенче бер легенда аларны тездән түбән йон белән капланган, ат тояклы итеп сурәтли[1].

Соңгырак чыганаклар хәбәр итүенчә, динлиннар б.э.к. III гасырдан алып б.э. III гасырында Көньяк Себердә Байкалдан Урта Енисейга һәм Чулым кушылдыкларына кадәр булган җирләрне биләгән.

Чыганаклар динлиннарның тышкы кыяфәтен күрсәтми, шунлыктан аларны европеоидлар итеп күрсәтүнең нигезе юк, бу уйдырма булып тора. Таштык эпохасына караган берничә күмү битлегенә таянып кына динлиннарны зәңгәр күзле, аксыл чәчле дип исәпләүне Л. Р. Кызласов нигезсез дип саный[2]. Кытай чыганаклары динлиннарның төрки телле булуын хәбәр итә[3].

Археологик тикшеренүләр язма чыганакларның динлиннар турындагы мәгълүматларын раслый. 1954—1956 елларда археолог С. В. Киселев Минуса казанлыгындагы, аның ачыклавы буенча, б.э.к. IV—III гасырга нисбәтле Олы Салбык исемле галәмәт зур курганны казый. Курганның нигезе төньяктан көньякка 100 адым, киңлеге 80 адым һәм биеклеге 10 сажин була. Шул искитәрлек зур курганда нибары бер кабер табыла, күрәсең, анда бары бер яки ике кеше күмелгәндер. Анда табылган әйләнмә кул тегермәненең аскы ташы әһәмиятле табылдык була. Ул Тагар эпохасында ук шушындый тегермән булуын раслый. Бу табылдыкка кадәр

Көньяк Себердә андый кул тегермәне б.э.ның беренче меңьеллыгы уртасында гына таралган дигән фикер бар иде[4].

Салбык табылдыгы галимнәргә Себердә кул тегермәне куллану хакындагы мәгълүматны 800—900 елга алга күчерергә мөмкинлек бирә. Соңгырак тикшерүләр С. В. Киселев фикерләренең дөреслеген раслады. Тагар эпохасында (б.э.к. VII—III гасырлар) Минуса казанлыгындагы игенчелеккә һәм терлекчелеккә ирригацион игенчелек өстәлә.

Бер кеше яки бер гаилә өчен шундый зур курган төзү тирән социаль бүленешне раслый. Бу Енисей буе кабиләләренең иртә сыйнфый дәүләте булу турында Кытай хроникасы мәгълүматы белән раслана. Кытай тарихчылары бу дәүләтне «Динлин Го» — «Динлин дәүләте» дип атый. Л. Р. Кызласов Зур Салбык курганын иң куәтле динлин патшаларының берсенең һәм аның гаиләсенең таш-балчык пирамидасы дип раслый. Ләкин Динлин дәүләте ныгып һәм үсеп китә алмый. Моңа сөннәрнең басып алулары комачаулый.

Динлиннарның көньяк күршеләре Үзәк Азиянең төрки телле кабиләләре — гяньгуньнәр яки гэгуньнәр була. Галимнәр гяньгуньне (гэгунь) «кыргыз» терминының иң борынгы транскрипциясе дип исәплиләр. Гяньгуньнәрнең биләмәләре динлиннардан көньяктарак, Төньяк-Көнбатыш Монголиядә урнашкан[5]. Бу турыда «Себер тарихы» исемле китабында Һади Атласи да яза: «Борынгылыкның бик тирән заманнарында кыргызларның «Гаян-Гун» исемле мөстәкыйль падишаһлыклары булганлыгын безгә тарих күрсәтә... Бара торгач әлеге «Гаян-Гун» исеме югалып, алар «хагас» дип аталып йөртелә башлаган. Бу «хагас» исеме аларга кытайлар тарафыннан гына бирелгән исем булып, «кыргыз» исеме илә һаман аталган булырга тиеш»[6]. Б.э.к. 201 елда сөннәр идарәчесе Модэ шаньюй Динлин дәүләтен буйсындыра, үзләрен төньякка кысрыклый, алар урынына гяньгуньнәрне күчерә. Тагар мәдәнияте ияләре — динлиннар, гяньгуньнәр белән кушылып, Таштык мәдәниятенә нигез сала (б.э.к. I гасыр — б.э.V гасыр).

Динлиннар б.э.к. буйсындыру белән килешми һәм, б.э.к. 69 елда сөннәрнең көчсезләнүеннән файдаланып, аларга төньяктан һөҗүм итә. Көнчыгыштан сөннәргә ухуаннар һөҗүм итә, көнбатыштан үсүннәр кузгала. Алар бергәләп сөннәрне тар-мар итә һәм бик күп санда атлар һәм сарыклар ала[7].

Динлиннар б.э.к. 63—60 елларда өч ел тоташтан сөннәр җиренә һөҗүм итә, берничә мең кешене үтерә һәм әсир итә, бик күп ат һәм мөгезле терлек алып китә. Сөннәрне җиңү Минуса казанлыгына һәм Тывага яңа халык массалары, беренче чиратта, гяньгуньнәр килүгә ярдәм итә. Б.э.к. 55 елда сөн берлеге ике

кисәккә бүленә. Хуханье көньяк сөннәр башында, Чжичжи төньяк сөннәр башында була. Б.э.к. 49 елда Чжичжи динлиннарны һәм гяньгуньнәрне җиңә һәм буйсындыра[8]. Гяньгуньнәрнең динлиннар арасына үтеп керүе процессы б.э.к. I гасыр уртасында туктый.

Енисей кыргызларының VII гасырга кадәр булган тарихы турындагы язма чыганаклардан фәкать Кытай чыганаклары гына бар. Әмма Кытай чыганаклары кыргызлар тарихының Кытай белән нинди дә булса элемтәләр булган елларын гына яктырта. Бөек Төрки каһанлыгы төзелгәч, бу элемтәләр еш кына туктала, һәм бу елларда Кытай чыганаклары кыргызлар турында бернинди дә хәбәр бирми. Тик VII гасырда гына Енисейдагы һәм Орхондагы рун язмалары Енисей кыргызлары тарихын ачарга мөмкинлек бирә. VII—IX гасыр кыргызлары турында Югары Енисейда һәм Тывада табылган рун текстлары бай мәгълүмат бирә. В. В. Радлов бу язмаларның кыргызларныкы булуы турында: «Бу язмаларны калдырган халык күбесенчә кыргызлар (хакаслар), алар безнең эпохада да Тану-ола җирендә яшәде»,— дип белдерсә дә, бу язмалар тарихи планда җитәрлек өйрәнелмәгән[9].

Енисей кыргызлары дәүләте

Игенчелекнең, терлекчелекнең, бигрәк тә тау эшенең, металлургиянең һәм тимердән әйберләр ясауның үсүе кыргыз өстен катлавы кулында шактый күп байлык тупланууга һәм тирән социаль дифференциациягә китерә. Енисей кабиләләре арасындагы бу тирән эчке процесс VI гасыр уртасында дәүләт төзелүгә китерә. Минуса казанлыгында төзелгән дәүләт полиэтник булган. Анда, мөгаен, төрки тел өстенлек иткәндер, шулай да кабиләләрнең билгеле өлеше самодий телле булган.

Бөек Төрки каһанлыгын соңыннан «түркүт» термины алган Ашина ыругы, ә Минуса казанлыгындагы дәүләтне кыргыз (гяньгунь) ыругы төзи һәм җитәкли. Шуңа күрә Минуса казанлыгында төзелгән дәүләтне тарихи әдәбиятта «Енисей кыргызлары дәүләте» яки «Кыргыз каһанлыгы» дип атау кабул ителгән. Тарихи әдәбиятта бу дәүләтне «Кыргыз каһанлыгы», «Кыргыз дәүләте» дип атау да гадәткә кергән.

Кыргыз каһаннарының хакимияте Монголиягә һәм Шәркый Төркестанга җәелә. Бу дәүләтнең чикләре көнбатышта Абакан сырты һәм Кузнецк Алатавы буенча үтә, көньяктан — Көнбатыш Саян сырты буенча, көнчыгышта, мөгаен, көнчыгыш Саян сырты буенча үткәндер, ә төньякта аның биләмәләре тайгага кадәр һәм

Ангара елгасы тамагына кадәр җәелә. Енисей кыргызлары дәүләте төзелү Бөек Төрки каһанлыгы оешу белән бер вакытка туры килә. Бөек Төрки каһанлыгы төзелүенең беренче елларында ук басып алу сугышлары башлый, Сары диңгездән Кара диңгезгә кадәр булган территориядә яшәгән халыкларны һәм кабиләләрне буйсындыра. Бу дәүләт кыска гына вакыт эчендә территориясе буенча бик зур һәм көч ягыннан иң гайрәтле дәүләткә әверелә.

Енисей кыргызларының идарәчеләре, үзләренең хәлен аңлап, гайрәтле күршеләре белән тыныч мөнәсәбәтләр урнаштырып, үз бәйсезлекләрен сакларга омтыла. Бөек Төрки каһанлыгы төзелүнең беренче дистә елларында алар моңа ирешә.

Күлтәгин һәйкәле язмасында 552 еллар тирәсендә үлгән беренче төрки каһаны Бумынны искә алу мәҗлесендә башка халыклар арасында кыргызлар да булуы турында әйтелә. Бу язманың текстына караганда, төрки каһаннары алга таба Минуса казанлыгына талау һөҗүмнәре башлый. Тиздән Енисей кыргызлары дәүләте төркиләр тарафыннан буйсындырыла. Әмма кыргыз дәүләте билгеле бер бәйсезлеген саклап кала, кабилә башлыклары үз хакимиятен югалтмый[10].

VII гасырның 20 нче еллары ахырында, Кытай агрессиясе нәтиҗәсендә, Көнчыгыш Төрки каһанлыгы көчсезләнә һәм 630 елда Кытайга бәйле булып кала. Беренче Төрки каһанлыгы таркалганнан соң, төрле кабиләләр арасында көрәш көчәя. Әле 629 елда ук Көнбатыш Төрки каһанлыгына керә торган «сейянто» исемле төрки кабиләсе Үзәк Азиядә хакимиятне яулап ала һәм Кыргыз дәүләте аннан бәйле булып кала, ләкин бу хәл кыска вакытлы була. 647 ел тирәсендә көнчыгыш төркиләрнең каһаны Чеби Алтай-Саян таулыгында яшәүче халыклар белән дә идарә иткән, ләкин бу чорда аның хакимияте әле йомшак була, чөнки көнчыгыш төркиләр әле Кытай кулы астында тора.

Кыргыз идарәчеләре бәйсезлекләрен кайтару һәм саклауга омтыла. Шуңа күрә алар даими рәвештә күрше дәүләтләр белән халыкара эшчәнлекләрен үстерә[11]. 632 елда, кыргыз каһаны янына ике дәүләт арасында мөнәсәбәтләр урнаштыру өчен, Тан императоры илчесе Ван И-Хун килә. 643 елда Тан дәүләте башкаласына Кыргыз дәүләтенең илчесе җавап белән килә[12]. 648 елдан 748 елга кадәр Кыргыз дәүләте илчеләре Тан дәүләтенә 10 мәртәбә бүләкләр белән килә. Аларның төп максаты сәүдә элемтәләрен дәвам итү һәм дәүләтара мөнәсәбәтләрне тикшерү була. Кыргыз идарәчеләренең Тибетка килүе турында да мәгълүматлар бар[13].

Кыргыз дәүләте күрше дәүләтләр белән дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыра, бу эш Бөек Төрки каһанлыгының көчле чагында һәм

Уйгыр каһанлыгы чорында туктапып тора. Кыргызлар Кытай һ.б. дәүләтләр белән халыкара сәүдә алып бара, ул дәүләтнең территориясе аша Бөек ефәк юлының бер тармагы уза.

50 ел Кытай хакимлеге астында торганнан соң, төркиләр 679—682 елларда Кытайга каршы сугыш алып бара. Ихтимал, Енисей кыргызлары дәүләте дә бу чорда кытайларга билгеле бер бәйлелектә булгандыр. Төркиләр белән сугышта Тан империясенең җиңелүеннән кыргызлар да файдаланырга омтыла, Күлтәгин язмаларына караганда, моңа төркиләр дә игътибар итә. Мочжо каһан (692—716) кыргыз каһаны Барсбик белән элемтәдә була һәм аны вассалитетка аударырга тырыша. Шул максат белән ул аңа үзеннән алда булган Гудулу каһан (Эльтерес каһан) кызын кияүгә бирә. Мочжо шуның белән Икенче Төрки каһанлыгының төньяк чикләрен ныгытырга тели, ләкин соңыннан кыргыз каһаны аның төп дошманы булып китә. Алга таба көрәштә Барсбик үтерелә һәм бу вакыйга хөрмәтенә балбал куела. Бу борынгы кыргыз дәүләтенең зур җиңелүе була[14].

Кыргызлар Орхон төркиләрен төп дошманнары итеп санийлар һәм Бөек Төрки каһанлыгына каршы еш сугышалар[15].

710 елгы җиңелүдән соң кыргызлар, күрәсең, үз хәлләрен ныгыткан булырга тиеш. Күлтәгин һәйкәле тексты 731 елда Күлтәгинне искә алуга «кыргыз каһаныннан Чур-Тардуш Ынанчу килде» дип хәбәр итә[16]. Бу фактор кыргызларның үз хәлләрен яңадан ныгытуы һәм төрки идарәчеләренең алар белән исәпләшергә мәҗбүр булуы турында сөйли.

744 елда соңгы төрки каһаны Озмиш уйгырлар тарафыннан үтерелә һәм Икенче Төрки каһанлыгы яшәүдән туктый. Моннан файдаланып, кыргыз идарәчеләре үз дәүләт бәйсезлеген торгыза. Әмма 758 елда уйгырлар кыргызларның 50 меңлек гаскәрен тармар итә. Бу җиңелү кыргызлар өчен 710 елгыдан зуррак һәлакәт була. Кытай чыганаклары кыргызларның Кытай белән элемтәләре 85 елга туктап торуын раслый.

758 елда Кыргыз каһанлыгы Уйгыр каһанлыгы тарафыннан буйсындырылса да, уйгыр идарәчеләре биредә тулы хуҗа була алмаган. Кыргыз дәүләте үз автономиясен саклап калган, кабилә башында торган бәкләр үз мөстәкыйльлекләрен югалтмаган. кыргызлар мөстәкыйльлек өчен көрәшләрен дәвам итә. 800 елда Уйгыр дәүләтенең төньяк чикләре Саян сырты буенча үтә[17]. Кыргыз дәүләте каһаннары яңадан үз дәүләтләрен ныгыта. Уйгыр ханы Баои вакытында (808—821) кыргызларның зур районы Уйгыр каһанлыгы белән сугыша. 820 елдан башлап кыргыз идарәчесе Яглакар 20 ел буена уйгырлар белән сугышлар алып бара. Сугыш

840 елда кыргызларның соңгы уйгыр каһаны Чжан-Синне җиңүе белән тәмамлана[18].

Яглакар хан титулын торгыза, башкаланы Енисей ярларыннан Ду-маньның төньяк битенә күчерә[19]. Кыргызларның Үзәк Азиядә нәүбәттәге хакимлеге шулай башлана. Һәрвакыттагыча, ул озакка бармаган. Кыргыз дәүләте идарәчеләре, күрәсең, үзләренең төп бурычы итеп корал җитештерүне санаган, чөнки аларның тау эшенең, металлургиясенең һәм корал эшләвенең зур мөмкинлекләре булган. Аларның яхшы коралланган армиясе була, аның ярдәмендә алар бәйсезлек яулап ала, ләкин кыргыз идарәчеләре бәйсезлекне саклый алмый. Үзләре төрки телле булып та, алар үзләренең төрки телле күршеләре — Орхон төркиләре белән дә, уйгырлар белән дә тыныч яши алмаган.

XI гасыр чыганагы «Худуд әл-алам» хәбәр иткәнчә, кыргызлар «гаделсезлек, рәхимсезлек, сугышчанлык һәм низагларга осталык белән аерылып торалар; тирә-якларындагы барлык халыклар белән сугышалар һәм дошманлашып торалар»[20].

Уйгырларны җиңгәннән соң, кыргыз идарәчеләре Тываны, Алтайны яулап ала, уйгырларны эзәрлекләүне дәвам итә, аларның бер өлеше Үзәк Азия буенча тарала, бер өлеше Турфанга китә һәм Уйге каһан җитәкчелегендә Турфан дәүләте төзи[21].

Кыргызларның Уйгыр дәүләтен җимерүеннән һәм уйгырларның күбесенең Үзәк Азиядән китүеннән соң, Тан императорлары кыргызларның уйгырларга күптәнге дошманлыгыннан файдаланырга уйлый, һәм алар моңа ирешә дә. 842 елда кыргыз гаскәрләре Шәркый Төркестанга уйгырларга каршы походка чыга, Джунгариянең бер өлешен басып ала һәм Кашгарга кадәр җитә. Кыргызлар уйгырларның Урта Азия төркиләре белән дуслык мөнәсәбәтләрен өзәргә омтыла, ләкин бу барып чыкмый, кыргызлар уйгырларны буйсындыра алмый.

IX гасыр ахырына Енисей кыргызлары дәүләте көнбатышта Иртешнең урта агымыннан алып Көнчыгышта Байкалга һәм Селенгага кадәр булган зур территорияне били. Аның төньяк чикләре Ангара елгасы буйлап үткән[22]. Кыргызлар, үз дәүләт чикләрен киңәйтеп, Байкалның һәм Көнчыгыш Казакъстанның күчмә тормыш өчен уңайсыз, ләкин зур хуҗалык потенциалы булган районнарын үзләштерә. Археологлар кыргызларның яшәү урыннарын көнчыгышта хәзерге Чита янында, төньякта Төньяк һәм Көнбатыш Алтайда, көнбатышта Или елгасы буенда таба.

X гасыр башында Төньяк Кытайда монгол телле киданнарның (кара кытайларның) дәүләте төзелә, ул «Ляо» исеме белән билгеле (916—1125). 924 елда Ляо императоры Абаоцзи зур гаскәр белән

Үзәк Азиягә үтеп керә һәм кыргызларны Минуса үзәнлегенә кысрыклый. X гасыр уртасында кыргыз каһанының пайтәхете Тывадан Минуса казанлыгына күчерелә[23]. Киданнар Орхон елгасында туктала.

Башта киданнарның кыргызлар белән мөнәсәбәте тыныч була. Ләкин киданнарның һөҗүме барлык төркиләр өчен бәлагә әверелә. X—XI гасырлардагы киданнар һөҗүме төркиләрнең Кытай чикләреннән көнбатышка качуын китереп чыгара һәм монгол телле кабиләләргә Амур бассейныннан һәм Маньчжуриядән төркиләрнең элекке җирләренә юл ача[24]. Әмма әле шуннан соң да кыргызлар үзләренең Енисейдагы дәүләтен саклый.

Монголларга каршы көрәш

Чыңгыз ханның яулап алулары кыргызларга һәлакәт китерә. 1206 елда корылтайда Темучин Чыңгыз хан дип игълан ителгәннән соң, монголлар кыргызларга каршы яу белән киләләр. 1209 елга кадәр алар кыргызларның каршы торуын сындыра алмый. 1208 елда монголларның Харәземгә походы вакытында аларның тылында күтәрелеш башлана. Бу баш күтәрүне тәҗрибәле гаскәр башлыгы, Чыңгыз ханның олы улы Җучи гына бастыра ала. Кыргызларның 1254 елда башланган яңа баш күтәрүе монголларны аларга каршы 20 меңлек гаскәр җибәрергә мәҗбүр итә. Баш күтәрү бастырыла, ләкин кыргызлар тынычланмый. Алар монголларга зур куркыныч тудырып тора, һәм 1293 елда Хубилай хан кыргызларның бер өлешен Маньчжуриягә җибәрергә боерык бирә. Енисей кыргызларының VI гасыр уртасында төзелгән, күп җәфалар чиккән дәүләте, сигез гасырга якын вакыт яшәп, монголлар һөҗүме астында XIII гасыр ахырында җимерелә[25].

Енисей кыргызлары дәүләтенең иҗтимагый төзелеше

Кытай чыганаклары һәм рун язмалары кыргызларның иҗтимагый төзелеше турында шактый бай материал бирә. Ил башында бай аристократия торган, аларның терлек көтүләре, җирләре һәм коллары булган. Кыргыз рун язуларында аристократиянең халыкка хуҗа булуы хакында турыдан-туры сүз юк. Бу хәл әле халыкның феодаль бәйлелеккә кермәве турында сөйли. Халык кыргыз эле (иле) белән параллель куела. Язмаларда «эл»нең ике мәгънәсе бар:

1. Кыргыз аристократиясе.
2. Билгеле аристократларның, туганнарның локаль төркеме.

Язмаларда билгеле бер территорияне биләү турында күрсәтмә еш кабатлана: «Минем өстенлегем аркасында, мин бу ил белән идарә иттем»[26].

Төркиләрдән аермалы буларак, кыргыз җәмгыятендә каһаннар түгел, ә бәкләр төп көч булган. Енисей язмаларында хан турында искә алу юк, бәкләр еш искә алына. Бу хуҗалыкның ярым утрак булуыннан килеп чыга. Хуҗалык итүнең бу төрендә җирле элементләр зур көчкә ия була. Әмма кыргыз җәмгыятендә дә югары хакимият каһан кулында туплана, ләкин бәкләрнең зур бәйсезлеге саклана.

Бәкләр үз сыйныфлары буенча тиңдәшләрен «эр» дип атаган. Алардан түбәнрәк «будун», ягъни кара халык торган. Кыргыз җәмгыятендә будун — икътисади яктан бәккә бәйле ирекле халык ул. Будунның аерым әгъзалары «кадаш» дип аталган. Колларны да «кеше» дип атаганар. Җәмгыятьнең нигезе булып патриархаль гаилә торган.

Чыганаклар күрсәткәнчә, ил башын «Хырхыз хакан» дип атаганнар. Чиновниклар алты разрядка бүленгән, җиде министр булган, аларның һәрберсе үз гаскәре белән идарә иткән. Бөек Төрки каһанлыгындагы кебек, монда да тарханнар булган[27].

Кыргыз дәүләтендә хәрбиләштерелгән деспотик хакимият урнаша. Законнар бик катгый булган. Мәсәлән, караклыкта тотылган кешенең башын кисканнәр һәм аның этисе бу башны гомер буена муенына асып йөрергә тиеш булган.

Югары катлау вәкилләре шәһәрләрдә һәм кальгаларда яшәгән. Даими армия аларның төп терәге булган, гомуми мәҗбүри хәрби хезмәт хөкем сөргән. Армиянең төп көчен авыр атлы гаскәр тәшкил иткән[28].

Кыргыз дәүләтендә дәүләт һәм хосусый җир биләүчелеге яшәгән. Хакимлек итүче ыругның иген басулары, көтүлекләре, барлык тау, тайга киңлекләре, шулай ук халыклары ясак түли торган басып алынган җирләр дәүләт җирләренә кергән.

Кыргыз җәмгыятенең туганлык терминологиясе төркиләрнекеннән аерылмаган диярлек: канг — эти, катын — йорттагы хуҗа хатын, апа — бабай, укэ — апа, ачи — абый, ини — эне, кыз — кыз, огул — ул[29].

XI—XII гасырларда Енисей кыргызлары дәүләтендә феодаль таркаулык көчәя, үзара низаглар, кенәзлекләр арасында сугышлар башлана. Л. Р. Кызласов XII гасырда кыргыз җәмгыяте килеп чыгышлары һәм телләре буенча төрле, берләшә алмаган һәм бердәм халык булып оеша алмаган этник төркемнәрнең конгломератын тәшкил иткән дип фаразлый. Бу хәл дәүләтнең сәяси һәм икътисади берлеген таркаткан, һәм Кыргыз каһанлыгы ныграк оешкан дошманнарга каршы тора алмаган[30].

Кыргызларның хуҗалыгы

Енисей кыргызларының да хуҗалыгы комплекслы була. Әле Тагар мәдәнияте чорында ук Минуса казанлыгында игенчелек яки терлекчелек белән өстенлекле шөгыльләнү районнары билгеле була. Бу бүленеш башта географик үзенчәлекләрдән килеп чыга, ә соңыннан иҗтимагый вазгыятьтән һәм милеккә хуҗа булу, байлыкка ия булу хәленә бәйле рәвештә барлыкка килә. Таштык эпохасының кабилә башлыклары хәрәкәтчәнрәк яшәү рәвеше алып бара, аның көнкүреше кабиләнең гади кешесенекенә караганда ат белән күбрәк бәйләнгән була. Язма һәм археологик чыганаклар Енисей кыргызларының башка барлык халыклар һәм кабиләләр арасында нык үскән игенчелеге белән аерылып торуы турында хәбәр итә. Алар тары, арпа, бодай, Һималай бодае, киндер иккән.

«Таншу» исемле Кытай елъязмасы, кыргызлар ашлыкны кул тегермәннәре белән тарта, дип яза[31]. X гасыр гарәп авторы Әбу Дулаф кыргызлар тары, дөге, сыер, сарык, кәҗә ите, гомумән, дөя итеннән кала башка барлык төр ит белән туклана дигән мәгълүмат бирә. XII гасыр уртасында гарәп авторы Әл-Идриси кыргызларның су тегермәннәре турында язып калдырган[32].

Археологик тикшеренүләр шулай ук игенчелекнең кыргыз чорында элеккегә караганда күбрәк мәйданнарны биләп алуын күрсәтә, бу турыда казылмаларда табылган бронза һәм тимер уракларның күплеге, Кытайда эшләнгән сука калаклары һәм төрәннәре, шулай ук үзләрендә ясалган сукалар хәбәр итә. Таншу чыганагы мәгълүматларына караганда, хәтта кыргызларга күрше булган, төньяктарак яшәгән кабиләләр дә «иген кырын ат белән сөргән». Алтай төркиләре дә сөрүле игенчелекне белгән[33].

Катлаулы сугару системалары төзү юлы белән кырларны сугару кыргыз игенчелегенең үзенчәлеге булган. Игенчелекнең киңәюе сугару эшенең камилләшүенә һәм яраксыз дип саналган җирләрне файдалануга китерә. Төньяк Хакасиядә һәм Енисей буе далаларында борынгы сугару каналлары челтәрләре, катлаулы ирригацион корылмаларның калдыклары: буалар, дамбалар, елга үзәннәрен тоташтыручы һәм аларның агымын игенчеләргә кирәкле юнәлешкә көйләүче ясалма су үткәрү юллары табыла[34].

Утрак игенчеләр шулай ук терлекчелек белән дә шөгыльләнә. Алар, кышка печән әзерләп, терлекне абзарда асрау ысулын үзләштерә. Археологик материал, Кытай чыганаклары һәм борынгы кыргыз язмалары күрсәтүе буенча, кыргыз хуҗалыгында күчмә терлекчелек игенчелеккә караганда зуррак әһәмияткә ия була. Сугарулы игенчелек бик алга киткән һәм кыргыз чорында шактый

киңәйгән булса да, күбрәк халык күчмә терлекчелек белән көн күрә. Енисей буендагы каберташ язмалары байлар арасында игенчеләргә караганда терлекчеләрнең күбрәк булуын күрсәтә. Мәсәлән, Уюк-Туран язмасы алты мең атым белән «ләззәтләнеп туя алмадым» дип хәбәр итә. Борынгы кыргызлар мәетләрне башка күчмә халыклар кебек җирләгәннәр. Каберләргә ат та салынган. Терлекләр арасында мөгезле эре терлек һәм атлар асрала, ә кайберәүләрнең берничә мең башка җиткән ат көтүләре була. Сарык һәм кәҗә дә асраганнар. Игенчеләр арасында да байлар булган, әлбәттә. Ләкин алар аз санда гына булган[35].

Кытай чыганаклары бу хисапсыз терлекләрне кем каравы, бай җирбиләүчеләрнең җирләрен кем эшкәртүе турындагы сорауга җавап бирә. Кытай тарихи хроникасы бу эшләр белән хягаслар (кыргызлар) әсирлеккә алган тайга кабиләләре шөгыльләнә дип хәбәр итә[36]. Тагар чорында күзәтелгән коллык бетми, ә әһәмияте генә арта. Коллар хезмәте кыргыз өстен катлавы хуҗалыгында файдаланыла башлый.

Чыганакларда кыргызларның салым түләве турында мәгълүматлар юк, буйсындырылган кабиләләр ясаклы булып саналган, аларның салымнары турында язмалар аз түгел, мәсәлән: «Ясаклылар салымны кеш һәм тиен белән түли»[37]. Кайбер түләүләр буйсындырылган халык исеменнән булган. Мәсәлән, казылмаларда табылган алтын савытта шундый язма бар: «Алтын... ача бүләге», ягъни ача халкы бүләге. Икенче бер савытта башка язма: «Без бәк алтынын түләдек»[38].

Традицион шөгыльләрдән кыргызлар аучылык белән шөгыльләнә. Тояклы һәм мехлы җәнлекләр аулыйлар. Тояклы хайваннар кыргызларны ит һәм тире белән, мехлы җәнлекләр кием тегү һәм алмашу өчен мех белән тәэмин иткән. Чыганакларда балык тоту, аерым алганда чөгә балыгы тоту турында мәгълүматлар бар[39].

Кыргыз хуҗалыгында һөнәрчелекнең әһәмияте игенчелектән һәм терлекчелектән ким булмый. Алар арасында тимер һәм башка металларны табу һәм эшкәртү беренче урын алып тора. Кытай хроникасы язганча: «Анда алтын, тимер һәм кургаш бар»[40]. Металлургиянең үсеше кулланучыларның соравына бәйле була. Игенчеләргә сука, аның детальләре, урак, чалгы, ат дирбияләре кирәк була, ә әлеге эшләнмәләр нигездә тимердән ясалган. Сугыш коралы да бик күп эшләнгән. Кыргызлар тимер әйберләрне алмашу өчен дә ясаганнар.

Тимер эретү рудниклардан читтә башкарылган. Тимерчеләрнең торулыклары Енисей һәм аның кушылдыклары буендагы ком калкулыклары буйлап өзлексез чылбыр булып тезелеп киткән. Бу

тимерчеләрнең башка халыктан хәтта территориаль аерылуы турында сөйли. Бу инде һөнәрчелекнең авыл хуҗалыгыннан аерылуын һәм аерым урыннарда туплануын күрсәтә.

Кораллардан иң күп ясалган әйбер тимер ук очлары булган. Кылыч һәм хәнҗәрләр дә күп эшләнгән. Сөңгеләр аз кулланылган. Саклану кораллары: күкрәкне, тезне каплаучы калканнар, тәңкәле көбә күлмәкләр эшләү киң таралган.

Ювелирлык эше дә үскән булган. Бизәнү әйберләре, бигрәк тә ат дирбияләрен бизәү өчен кулланыла торганнары күп ясалган. Кыргыз җәмгыятендә чүлмәкчеләр, рәссамнар, ташка бизәк төшерүчеләр була.

Кыргызлар Кытай, Тибет, Урта Азия, Шәркый Төркестан һәм Ляо илләре белән сәүдә итә. Алар ефәк һәм йон тукымалар, фарфор һәм башка төрле савыт-саба сатып алган. Бу илләргә алар агач, тире, мех, тимер әйберләре саткан, ихтимал, алтын, көмеш әйберләр дә сатканнардыр.

Рухи мәдәният

Хуҗалыкның шактый югары дәрәҗәсе һәм дәүләт төзелеше Енисей кыргызларының мәдәни үсешенә ярдәм иткән. Аның нигезе төрки булган. Әйткәнебезчә, Иран-Европа ориентацияле кайбер галимнәр төркиләрдәге теге яки бу үсеш тамырларын күрше илләрдән — Иран, Кытай һәм башкалардан эзләү тенденциясен алга куялар. Енисей кыргызлары дәүләте халкы үзенчәлекле һәм мөстәкыйль рухи мәдәният булдыра. Күрше илләр белән үзара мәдәният йогынтысы кичереп яши.

Мәдәни үсешнең югары казанышы булып язу торган. Безгә билгеле булганча, Орхон алфавитының нигезендә арамей язуы торган. В. В. Радлов һәм П. Мелиоранский Енисей кыргызлары язуының Орхон язуына караганда борынгырак булуы турында фикер әйттеләр. С. Е. Малов та бу язуны Орхон язуыннан ике-өч гасырга борынгырак дип саный[41].

Енисей үзәнлегендә, Тывада һәм Хакасиядә 150 дән артык борынгы төрки язулы һәйкәл, ядкярләр табыла, болар барысы да диярлек Енисей кыргызларына нисбәтле. Аларның күпчелеге VIII—XII гасырларда кабилә түрәләренә куелган эпитафияләр. Енисей язмалары Орхон язмаларыннан кыскарак. Аларда кыргыз бәкләре мактала, үлемнәре зур кайгы итеп күрсәтелә. Ләкин аларда, Орхон язмаларыннан аермалы буларак, тарихи-сәяси мәгълүматлар бик аз. Алар Орхон язмалары белән бер телдә язылган. Димәк, борынгы төркиләр яшәгән гаять зур территориядә бердәм әдәби

төрки тел яшәгән. Мондый әдәби тел төрле төрки дәүләтләр составында яшәгән төрки кабиләләрнең тыгыз элемтәләре булуын раслый.

Енисей рун язмалары, аларның халыкка юнәлтелгән текстлары Кыргыз дәүләте халкы арасында уку-язуның киң таралуына шаһит булып тора. Көнкүреш әйберләрендәге язмалар да шул турыда сөйли.

Археологик казылмалар Кыргыз дәүләтендә эре шәһәр үзәкләре барлыкка килүне, храмнар, сарайлар, административ үзәкләр төзелүне күрсәтә. Төзү материалы яндырылмаган кирпеч һәм агач булган. Археологлар кыргызларның Уйбат елгасы дельтасына урнашкан башкаласын табып казый. Биналарның күбесе агачтан була, яндырылмаган кирпеч тә кулланылган.

Феодаллар үзләренә кальгалар, замоклар төзи. Үзәк һәм Көнбатыш Тывада кыргызлар берничә елга буенда таштан чик буе стеналары кора. Тывада 259 метрлы шундый стена хәрабәләре сакланган[42].

VI—VII гасырларда кыргызларда алтын яфраклар белән капланган, агачтан кисеп ясалган хайван фигуралары киң таралган. Бай үсемлек орнаменты төшерелгән ат дирбияләре зур кызыксыну уята. Тау кыяларындагы ауны сурәтләгән рельефлы сурәтләр аеруча үзенчәлекле[43].

Борынгы кыргызларның мәдәнияте һәм сәнгате Евразия дала халыкларының, беренче нәүбәттә төркиләрнең, рухи үсеше үрнәге булып тора. Шул ук вакытта кыргыз рәссамнары күршеләренең мәдәният үрнәкләрен иҗади файдалана, үз әсәрләрен күршеләр арасында тарата, шулай итеп, аларның мәдәнияте һәм сәнгате үсешенә дә йогынты ясый.

Борынгы кыргызларның дине җитәрлек өйрәнелмәгән, чыганаклар аларның ышанулары турында конкрет мәгълүмат бирми. Башка төркиләр кебек үк, алар да, мөгаен, Тәңре динен тоткандыр. Тан-шуга таянып, Н. Я. Бичурин кыргызлардагы шаманизм турында яза. Тан-шуда: «Шаманнарны «гам» дип атыйлар»,— дигән язу бар. В. В. Бартольд бу Кытай сүзе астында төрки сүзе «кам»ны шәйли[44]. Әмма «кам» сүзе белән төркиләр шаманны гына түгел, ә Тәңре дине тотучыларның дин башлыгын да атый. Л. Р. Кызласов кыргызлар арасында манихей диненең беркадәр таралуы турында яза, ләкин бу чыганаклар белән расланмый. С. В. Киселев кыргызларга ислам диненең керүе турында яза[45]. Ләкин бу шикле, чөнки кыргызларның көнбатыш күршеләре — кимәк, кыпчак, угыз, бәҗәнәк, карлук һ.б. кабиләләр, мөселман үзәкләренә якынрак урнашкан булсалар да, бу чорда әле Тәңре дине тота.

Шулай итеп, Бөек Төрки каһанлыгының көньяк төрки цивилизациясе белән параллель рәвештә, Минуса казанлыгында һәм Саян-Алтай таулыгының аңа чиктәш өлкәләрендә төньяк төрки телле кыргызлар мәдәнияте тарала. Алар Алтай төркиләре белән бер вакытта үз дәүләтен төзи. Енисей кыргызлары дәүләте тарихында күтәрелешләр дә, түбән тәгәрәүләр дә була, ләкин ул дәүләт Бөек Төрки каһанлыгына караганда да, Уйгыр каһанлыгына караганда да озаграк яши һәм Кимәк каһанлыгы чорында да яшәвен дәвам итә.

* * *

Енисей кыргызлары дәүләте 800 елга якын яши. Ул монголлар һөҗүменә беренчеләрдән дучар була һәм, озак каршы торуга карамастан, аларның берөзлексез һөҗүмнәреннән җимерелә. Төрки телле булсалар да, борынгы кыргызлар үз язмышларын бер генә борынгы төрки кабиләсе белән дә бәйләми. Бөек Төрки каһанлыгы, Уйгыр каһанлыгы, Кыргыз каһанлыгы һәм Кимәк каһанлыгы җисми һәм рухи мәдәниятендә уртаклык, гомумилек зур, ләкин үзенчәлек тә аз түгел. Кыргыз дәүләте башка төрки дәүләтләреннән үзенең ныграк үскән игенчелеге, металлургиясе һәм тимердән әйберләр ясавы белән аерылып торган. Орхон төркиләре, кимәкләр һәм Енисей кыргызлары мәдәниятенең уртаклыгы аларның рун алфавитын куллануында күренә. Борынгы төркиләрнең дине дә — монотеистик дингә якын торган Тәңре дине булган. Үз дәүләтләре җимерелү һәм традицион мәдәниятнең бераз артка китүе сәбәпле, төркиләргә күрше халыклардан шаманизм үтеп керә башлый.

Кыргызларга XIII гасырның беренче яртысында ясалган һөҗүм бик көчле була һәм Енисейдагы Кыргыз дәүләте беркайчан да торгызылмый.

XVIII гасыр башында Енисей кыргызларының күбесе Минуса казанлыгын калдырып китә, моның төп сәбәбе итеп кайбер галимнәр рус колонизациясенең рәхимсезлеген саный. Анда калганнары хәзерге хакаслар этногенезының төп компоненты булып китә. А. Н. Бернштам һәм башка кайбер галимнәр фикере буенча, күчеп киткән Енисей кыргызлары хәзерге Кыргызстан кыргызлары этногенезында катнаша, ләкин бу караш белән килешмәүчеләр дә бар.

[1] Каталог гор и морей.— М., 1977.— С. 128.
[2] *Кызласов Л. Р.* История Южной Сибири в средние века.—М., 1984.— С. 20.
[3] *Таскин В. С.* Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. I.— М., 1968.— С. 136.
[4] *Кызласов Л. Р.* Очерки по истории Сибири и Центральной Азии.— Изд. Краснояр. ун-та, 1992.— С. 41.
[5] *Кызласов Л. Р.* Таштыкская эпоха в истории Хакасо-Минусинской котловины.— М., 1960.— С. 161—162.
[6] *Атласи Һади.* Себер тарихы. Сөенбикә. Казан ханлыгы.— Казан, 1993.— 34 б.
[7] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М.; Л., 1950.— С. 82; *Таскин В. С.* Материалы по истории сюнну (по китайским источникам). Вып. II.— М., 1973.— С. 28.
[8] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 37, 124 б.
[9] *Rabloff W. W.* Die altturkischen Inschribten in der Mongolei. I und II Lief.— St. Pbg.,1894.— S. 300.
[10] *Малов С. Е.* Памятники древнетюркской письменности.— М.; Л., 1951.— С. 36.
[11] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 287 б.
[12] *Кюнер Н. В.* Китайские известия о народах Южной Сибири, Центральной Азии и Дальнего Востока.—М., 1961.— С. 56.
[13] *Кызласов Л. Р.* История Южной Сибири в средние века.— М., 1984.— С. 37—38.
[14] *Мелиоранский П.* Памятник в честь Кюль-тегина // Записки Восточного отделения Русского археологического общества. Т. XII.— СПб., 1899.— С. 70.
[15] *Кызласов Л. Р.* История Южной Сибири в средние века.— М., 1984.— С. 39.
[16] *Малов С. Е.* Памятники древнетюркской письменности Монголии и Киргизии.— М.; Л., 1959.— С. 20.
[17] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 448 б.; *Кюнер Н. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 57 б.
[18] *Бернштам А.* Историческое прошлое киргизского народа.— Фрунзе, 1942.— С. 11—13.
[19] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 450 б.
[20] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 355 б.
[21] *Якубовский А. Ю.* Арабские и персидские источники об уйгурском Турфанском княжестве в IX—X веках//Труды отдела Востока Государственного Эрмитажа.— Л., 1947.
[22] *Кюнер Н. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 57 б.
[23] *Бартольд В. В.* Сочинения. Т.VIII.— М., 1973.— С. 47—48.
[24] *Бартольд В. В.* Сочинения. Т.V.— М., 1968.— С. 122—129.

[25] *Киселев С. В.* Древняя история Южной Сибири.— М., 1951.— С. 594.

[26] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 573 б.

[27] *Кюнер Н. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 56 б.

[28] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 59—60, 353 б.

[29] *Бернштам А.* Күрсәтелгән хезмәт, 162 б.

[30] *Кызласов Л. Р.* Күрсәтелгән хезмәт, 135 б.

[31] *Васильев В. П.* Китайские надписи на орхонских памятниках в Кошо-Цайдаме и Карабалгасуне //Сб. трудов Орхонской экспедиции Российской Академии наук. Вып. III.— СПб., 1897.— С. 25.

[32] *Кызласов Л. Р.* История Южной Сибири в средние века.— М., 1984.— С. 103—104.

[33] *Кюнер Н. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 103 б.

[34] *Федоров В. И.* Древнее искусственное орошение в районе Минусинского понижения//Материалы и исследования по археологии СССР.— М., 1952.— № 22.

[35] *Бернштам А.* Социально-экономический строй орхоно-енисейских тюрок VI—VIII веков.— М.; Л., 1946.— С. 151.

[36] *Бичурин Н. Я.* Собрание сведений о народах, обитавших в Средней Азии в древние времена. Т. I.— М.; Л., 1950.— С. 448.

[37] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 448 б.

[38] *Киселев С. В.* Древняя история Южной Сибири.— М., 1951.— С. 573.

[39] *Кызласов Л. Р.* Күрсәтелгән хезмәт, 109 б.

[40] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 444 б.

[41] *Киселев С. В.* Древняя история Южной Сибири.— М., 1951.— С. 60.

[42] *Кызласов Л. Р.* История Южной Сибири в средние века.— М., 1984.— С. 144.

[43] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 632—634 б.

[44] *Бичурин Н. Я.* Күрсәтелгән хезмәт, 446 б.; *Бартольд В. В.* Киргизы.— Фрунзе, 1927.— С. 22.

[45] *Киселев С. В.* Күрсәтелгән хезмәт, 616 б.

ЙОМГАК

Шулай итеп, без Себердә һәм Үзәк Азиядә яшәгән борынгы төркиләрнең кыскача тарихы белән таныштык, Бөек далада бик борынгы заманнардан алып XIII гасыргача узган тарихи процессларны барлап чыктык.

Б.э.к. күп гасырлар элек Көньяк Себердә һәм Үзәк Азиядә төрки телле, самодий һәм палеоазиат һ.б. күчмә кабиләләр яши. 1 меңьеллыкның икенче яртысында төрки телле булмаган кабиләләр төрки телле сөннәр, түркүтләр, уйгырлар, кыпчаклар, угызлар һәм башка кабиләләр белән алмашына. Кытай идарәчеләре күчмәннәр яшәгән территориягә коллар армиясен тулыландыру регионы итеп карый. Тарихта билгеле булган беренче төрки дәүләтне динлиннар төзи, Кытай тарихи чыганакларында бу дәүләт «Динлин-Го» дип атала. Б.э.к. IV гасырда төзелгән Сөн дәүләте төрки телле һәм башка кайбер кабиләләрне берләштерә һәм колбиләүче Кытай агрессиясенә каршы көрәштә аларның терәге булып китә. Күп санлы Кытай коллары үзләренең колбиләүчеләргә каршы көрәшендә Сөн дәүләтенә таяна.

Б.э.к. III гасырда, Модэ шаньюй идарә итү чорында, Сөнну бөек төрки дәүләте булып китә. Аның чикләре Маньчжуриядән Согдианага кадәр сузыла. Сөнну дәүләтендә төрки дәүләтчелекнең нигезләре салына. Җәмгыятьтә дә, дәүләттә дә оешканлык, ныклы тәртип, шаньюйларның хакимияте көчле булу нәтиҗәсендә Сөнну бөек державага әверелә. Кытай императорлары Сөнну шаньюйларын үзләренә тиң итеп хисаплый. Ыруглык тәртипләренең озак яшәве, күрше халыклар белән сугышлар, дәүләтнең чикләрен нык киңәйтү, шаньюйларның хакимияте йомшару Сөнну дәүләтен һәлакәткә китерә. Кытайның хәрби һәм дипломатик агрессиясе дә Сөнну дәүләтенең һәлакәтендә зур факторларның берсе була.

Б.э.ның II гасыры уртасында Сөннүнең тулысынча җимерелүеннән соң, Ордоста һәм Җидесуда (Юебань) сөн дәүләтләре яшәүләрен дәвам итә әле. Б.э.ның II гасыры ахырында Көнчыгыш Европада Һун дәүләте төзелә, ул V гасырда куәтле дәүләткә әверелә һәм шул чорда ук таркала.

Бөек Төрки каһанлыгы Сөн дәүләтенең турыдан-туры варисы булмый, әмма аның дәүләт һәм иҗтимагый төзелеше төрки дәүләте традицияләрен үстерә. Бу феодаль мөнәсәбәтләрнең башлану һәм үсү чоры була. Бөек Төрки каһанлыгын иң оешкан һәм көчле кабилә — түркүтләр төзи һәм алар үз тирәсенә башка төрки кабиләләрне туплый. Бу фактор, шулай ук дәүләт белән идарә итүнең ныклы системасы һәм каһанның көчле хакимияте әлеге төрки дәүләтен Сары диңгездән Кара диңгезгә кадәр мәйданны биләгән галәмәт зур беренче Евразия империясе дәрәҗәсенә күтәрә. Бөек Төрки каһанлыгы шул заманның иң көчле, гайрәтле дәүләтләре дәрәҗәсенә ирешә. Төрки каһанлыгы җимерелгәннән соң төзелгән башка төрки дәүләтләр династияләр алмашуны хәтерләтә. Уйгыр дәүләте шулай ук Бөек Төрки каһанлыгында яшәгән иҗтимагый процессларның турыдан-туры дәвамчысы була.

Башка барлык төрки дәүләтләрдән дә озаграк яшәгән Кыргыз каһанлыгының юлы үзгәрәк була. Ул Бөек Төрки каһанлыгы белән дошманлашып яши, аның гаскәрләре Уйгыр каһанлыгын җимерә.

Борынгы төрки дәүләтләр күршедәге Кытай, Иран, Византия кебек бөек дәүләтләр белән дипломатик, хуҗалык, сәүдә һәм мәдәни элемтәләр урнаштыра һәм халыкара танылуга ирешә. Орхон-Енисей рун язуының киң таралуы, бераз соңрак барлыкка килгән уйгыр язуы борынгы төрки дәүләтләрдә мәдәниятнең югары үсешен күрсәтә. Орхон, Енисейдагы һәм Уйгыр дәүләтендә куелган ташъязмалар борынгы төркиләр тарихын мәңгеләштерә.

Бөек Төрки каһанлыгы эчендә Көнчыгыш Европаның төрки дәүләтләре — Хәзәр каһанлыгы һәм Кубрат ханның Бөек Болгар дәүләте барлыкка килә. Төрки дәүләтләр эстафетасын X гасырда Урта Иделдә төзелгән Идел Болгары дәүләте дәвам итә.

Барлык борынгы төрки дәүләтләр эчке яки тышкы сәбәпләр аркасында таркала. Кайвакытта дәүләт һәлакәте вакытында дәүләтне төзүче этник группа да югала. Мәсәлән, Бөек Төрки каһанлыгы таркалганнан соң, түркүтләр юкка чыга, Кимәк каһанлыгы һәлакәтеннән соң, тарихи аренадан кимәкләр китә. Аларга алмашка башка этнослар килә һәм дәүләтләр төзи. Ә төркиләр кала, үсә, этногенезның, яңа этнослар яки кабиләләр ясалуның тирән процесслары дәвам итә.

Шулай итеп, башта Ашина ыругы атамасы гына булган «түрк» сүзе югалмый, ул Европа һәм Азия буенча тарала. Киләчәктә бу этноним тел гаиләсенең атамасы булып китә.

Кимәк каһанлыгы таркалганнан соң, Үзәк Азия һәм Көньяк Себер төркиләре тарихында трагик чор башлана. Төркиләрне берләштерүче һәм яклаучы көчле дәүләт булмау сәбәпле, XI гасыр

уртасыннан башлап, ике гасыр дәвамында төркиләрне коллыкка алып китәләр, базарларда саталар. Нәтиҗәдә Көньяк Себердә төркиләр юкка чыга яза, алар, аерым утраулар булып, аз санда кала. Бу вакытта яшәгән Кыргыз каһанлыгы төркиләрне берләштерә дә, яклый да алмый.

Борынгы төркиләрнең кешелек тарихында урыны гаять зур була. Төрки мәдәнияте казанышларын күп халыклар кабул итә. Борынгы төрки мәдәнияте Идел Болгары дәүләте, Алтын Урда, Казан, Әстерхан, Кырым, Касыйм, Себер ханлыкларының, Казакъстанның һәм Урта Азиянең төрки дәүләтләренең, Кече Азиянең Сәлҗүк һәм Госманлы дәүләтләренең мәдәнияте һәм дәүләтчелеге нигез ташын тәшкил итүче факторларның берсенә әверелә.

Борынгы төрки дәүләтләр тарихын, җисми һәм рухи мәдәниятен бүгенге төрки халыкларның берсенә генә аерым нисбәтләп булмый, алар барлык төрки халыкларның тарихи мирасы булып тора. Төрки җисми һәм рухи мәдәнияте Кытай, Иран, Византия, славян мәдәниятләре белән бертигез дәрәҗәдә кешелек цивилизациясенә үз өлешен кертә.

Научно-популярное издание

НАШ СЛЕД В ИСТОРИИ

Файзрахманов Габдельбар Лутфиевич

ДРЕВНЕТЮРКСКИЕ ГОСУДАРСТВА СИБИРИ И ЦЕНТРАЛЬНОЙ АЗИИ

Казань. Издательство «Магариф». 2005

На татарском языке

Фәнни-популяр басма

БЕЗ ТАРИХТА ЭЗЛЕБЕЗ

Фәйзрахманов Габделбәр Лотфиевич

СЕБЕРДӘ ҺӘМ ҮЗӘК АЗИЯДӘ БОРЫНГЫ ТӨРКИ ДӘҮЛӘТЛӘР

Редакция мөдире *Л. Г. Шәрифуллина*
Редакторы *И. И. Кадыйрова*
Бизәлеш редакторы *Л. С. Золондинова*
Техник редакторы *Ә. С. Трофимова*
Компьютерда биткә салучысы *Г. Р. Галимҗанова*
Корректорлары *Г. Р. Ногманова, Р. Ә. Фәйзуллина*
Рәсемнәрне компьютерда эшкәртүчеләре *Л. Р. Вафина, Э. Ф. Нурмөхәмматова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 09.06.2005. Форматы 60×90 1/16.
Офсет кәгазе. «Сувенир» гарнитурасы. Офсет басма.
Басма табагы 12,0+форз.0,25. Нәшер-хисап табагы 12,02+форз.0,41.
Тиражы 3000 д. Заказ К 5/109.

«Мәгариф» нәшрияты. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
Тел./факс (8432) 92-57-48.
http://magarif. kazan.ru
E-mail: magarif@mail.ru

ООО ПИК "Дом Печати"
420111, РТ, г. Казань, ул. Баумана 19, оф. 104
тел.: (8432) 92-56-70, 92-44-36, 92-68-23